ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ДАҺБУ “Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжы”
Милли кадрлар әзерләү үзәге

# Шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның 70 яшьлек юбилеена багышланган “Әдәби туган як” республика фестивале конференциясенең материаллары

Минзәлә, 2017

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Гыйлаҗетдинова Гөлнур Мирзанур кызы. Эльмира Шәрифуллина иҗатында милли рухның чагылышы........................................................4

2. Хәйруллина Илгизә Мофаздал кызы, Талипова Гөлназ Фазыл кызы. Эльмира Шәрифуллина иҗатында хатын-кыз образы ..............................11

3. Шаһиева Нәсимә Миргарифҗан кызы. Эльмира Шәрифуллина иҗатында әдәп-әхлак мәсьәләсенең куелышы ..................................................20

4. Әхмәтшина Лариса Михаил кызы. Матур эшләр эшлик җирдә, якты эзебез калсын.......................................................................................26

5. Гайфуллина Фәридә Әлтаф кызы. Г. Ибраһимовның башлангыч чор әдәби тәнкыйть эшчәнлеге. ......................................................................28

6. Фәйзуллина Алсу Мостафа кызы. Галимҗан Ибраһимов хикәяләрендә фразеологизмнар.........................................................................................33

7. Хасаншин Ирек Фаям улы. Тарих, әдәбият олпары. ................................43

8. Хәйретдинова Зөлфия Рафик кызы. Якташыбыз авазы ..........................46

9. Шәйхетдинова Розалия Харис кызы. Милләтемнең энҗесе....................49

10.Газизова Лилия Нәҗип кызы. Г. Ахунов исемен мәңгеләштерү.............52

11. Муллашова Эльмира Рәис кызы. “Әдәби туган як- Чаллы шагыйрьләре, язучылары иҗатында”...........................................................................55

12. Минһаҗева Резилә Әбүзәр кызы. Кәрим Тинчурин прозасында модернизм күренешләре ..........................................................................58

13. Зиатдинова Лилия Ивановна. Изучение средств языковой выразительности на материале прозы Виктории Токаревой. ...................62

14. Зиннәтуллина Гөлнара Ханнан кызы. Ташлар телен белгән язучы-галим ...........................................................................................................65

15. Гафиятуллина Энҗе Хабибулла кызы. Эльмира Шарифуллина иҗатында әдәплелек, милли тәрбия һәм хөрмәт мәсьәләләре.................69

16. Сөнгатуллина Гөлшат Гыйльметдин кызы. Галимҗан Ибраһимов иҗатында татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары ...........................72

17.Газизова Эльмира Илгиз кызы. “Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасы”.............................................................................76

18.Абдуллина Гөлфия Хәбибулла кызы. Әлфия Ситдыйкова иҗатында туган җир темасы ........................................................................................ 79
19. Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы. Ике икең ундүрт ........................... 82
20. Гыйниятуллина Диләрә Ханнан кызы. Язмышларга буйсынмас Чулпан ........................................................................................................ 87
21.Биктаһирова Ләйсән Габбас кызы, Алиева Суфия Фатхулла кызы. Эльмира Шарифуллина– Моң иясе. ........................................................ 90
22. Яхина Ләйсән Равил кызы. Харрас Әюпов иҗатында яшәү фәлсәфәсе . 92
23.Вәлитова Әлфия Нурулла кызы. Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән ..... 94
24. Төхфәтуллина Ә.Г. Р.Рахман иҗатында фразеологик әйтелмәләр кулланылышы ........................................................................................ 98

# Эльмира Шәрифуллина иҗатында милли рухның чагылышы

*Гыйлаҗетдинова Гөлнур Мирзанур кызы,*
*Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжының*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Хәзерге татар поэзиясенә уйлану рухы, шәхеснең туктаусыз үзгәрә килгән дөньясына игътибар итү хас. Шагыйрьләрне безнең заманның “гасыр белән сәгать” арасындагы юлның кыскара баруы уйландыра. Бу кыскалык, ашыгу-кабалану кешелекнең гасырлар буена туплап-җыеп килгән рухи мирасын югалтуга этәрүенә алар күңелләре белән борчылалар, иҗатлары аша укучыны шушы кыйммәтләрне сакларга чакыралар. Боларга беренче чиратта милләт кайгысы керә. Чөнки теләсә-кайсы халыкның киләчәктәге яшәеше милли билгеләренең яшәвенә бәйле. Болар – тарих, тел, язу, гореф-гадәтләр, мәдәният, сәнгать, халык авыз иҗаты.

Милли рух Э Шәрифуллина иҗатында да кызыл җеп булып сузыла. Бер генә түгел, ә берничә.

**Беренчесе** – милли **гореф-гадәтләр**. Бала чактан канына сеңгән, күңеленә үтеп кергән милли йолалар шагыйрә иҗатында балачак хәтирәләре булып кына түгел, ә яшәү яме буларак чагылыш таба. Ул аларны эчке горурлык, аларның хәзер дә халык күңелендә онытылмыйча сакланып килүенә куаныч белән, милли сыйфатларын тирән ачып сурәтли.

Кешенең фани дөньяга аваз салуы йолаларның башлануына этәргеч булып тора. Бәби туту белән үтәлә торган иң беренче йола – аның кендеген кисү. Хәзерге заманда бала шифаханәләрдә туа. Андагы шәфкать туташы – баланың кендек әбисе булуы турында, мөгаен, бик сирәк кеше уйлана торгандыр. Без моңа тиешле бер гамәл,

акушерканың төп вазифасы итеп карыйбыз, аның нечкәлекләренә игътибар итеп тә бетермибез. Ә борынгы заманнардан алып, узган гасырның илленче елларына кадәр авыл җирлегендә бала гап-гади өй шартларында туган. Шифаханәнең махсус җиһазланган палатасын – йортның сәкесе, акушеркасын кендек әбиләр алыштырган. “Кендек әбекәем” шигырендә Э Шәрифуллина менә шул изге затларга мәдхия җырлый:

*...Бәби тоткан кендек әбекәем*
*Ераклашкан саен – янәшә.*
*Кендекләрне кистең,*
*Җиргә тектең –*
*Исәлеккә күчеп, мең яшә!*

Бала тугач үткәрелә торган икенче йола – бәби мунчасы. “Бәби мунчасы” шигырендәге кедек әби инде икенче мөһим бурычны башкара: баланың кендеген кисеп, аны туган җире белән бәйләгәч, ул шул нәнине дөньяга китергән ананы хөрмәтләүгә күчә:

*Буыннарны сылап, сөеп,*
*Сыйпап оеш каннарны.*
*Мунча кертәләр әбиләр*
*Җан тудырган җаннарны.*

Аннан соң кадер-хөрмәт тагын нарасыйга күчә:

*Мунча кертәләр әбиләр,*
*Укыйлар теләк-дога.*
*Шуңадырмы авыллардан*
*Рәхимле җаннар чыга.*

Бу соңгы юлларга никадәр эчке мәгънә салынган. Нәни бала кендек әби кулына килеп керү белән дога сүзләрен ишетә башлый. Кендек әбисе аны чынбарлыкның физик һәм рухи бәла-казаларыннан саклый. Чыннан да, бала тугач, әгәр бүтән ашыгыч эше булмаса, кендек әбиләр ана белән бала яныннан китмәгәннәр, аларны саклаганнар. Бәлки

бүгенге тормышта кешеләр арасындагы салкынлык, кырыслык, бер-береңнән читләшү, рәхимсезлек кебек хис-тойгылар – тугач та анасыннан аерып алып, биләүгә төреп, аннан читкә, икенче бер бүлмәгә илтеп салуның нәтиҗәседер. Минемчә, шагыйрәнең фикере шуңа кайтып кала.

Тәпи йөри башлаган бала халкының милли гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен күреп, шуларда үзе дә катнашып үсә. “Карга боткасы”, “Каз өмәсе” кебек шигырьләр әнә шул балачак истәлекләре белән күңелдә уелып калган бәйрәмнәр турында. Хәзерге чорның табыннары ни дәрәҗәдә мул булмасын, бала чакта авыз иткән карга боткасы иң тәмле ризык булып хәтергә сеңеп калган. “Карга боткасы” шигырендәге Нурмый әби образы – чорларны тоташтыручы буын. Ул үзе җыеп алып төшкән балаларга яңа шытып чыккан үләнне күрсәтеп: “*Дошманыңа хәтта күрсәтмәсен безнең күргәнне*,” – дип сөйли. Билгеле, сугыштан соң туган балалар өчен яңа шыткан үлән табигать бүләге буларак кына кабул ителгән, ә аның әманәт булуын бала үсеп олыгайгач кына аңлый:

*Әманәтләр әйтер өчен генә*
*Пешергәндер, бәлки, ул аны.*
*Икмәк кискән саен хәтерлимен*
*Онытылып барган йоланы.*

Димәк, әби карга боткасын гореф-гадәтләрне саклау, балаларга халык тәрбиясен бирү өчен генә түгел, ә яшь буынга ризык кадерен белү, булганга шөкер итә белү, канәгать була алу кебек төшенчәләрне җиткерү өчен дә үткәргән. Шуңа күрә шагыйрә әсәр ахырына укучыны уйландырырлык риторик сорау куя:

*...Тормышлар мул хәзер,*
*Табыннар мул.*
*Ә нәрсә соң яшәү томкасы?*
*Каян гына искә төштең әле,*
*Онытылган карга боткасы?!*

“Каз өмәсе” шигырендә татар халкының тагын бер матур йола-бәйрәме сурәтләнә. Элек-электән өмәгә җыю күркәм гадәт булып саналган, аңа чакыру алу кызлар арасында зур мәртәбә булып саналган: “*Өмәләрдә эш күрсәтеп, Ярлар табып калыгыз*”. Өмәгә килгән кызларны өлкәннәр җентекләп күзәткәннәр, аларның өлгерлегенә, чиста-пөхтәлегенә, булдыклылыгына шундый өмәләрдә бәя бирелгән. Билгеле, “*Каз йолка белмәгән кызны Егет солтаны сөймәс*”. Кызның эш рәте белү-белмәвен егеткә өмәгә йомыш белән кереп чыккан анасы, өмәдә катнашкан апа-сеңлесе җиткергән. Кичке уен – уңган кыз белән егет  солтанының очрашу урыны булган:

*Бии-уйный сылу кызлар,*

*Чыңлый чулпы, төймәсе.*

*Борынгыдан калган гадәт –*

*Татарның каз өмәсе.*

Э Шәрифуллина әсәрләрендә милли рухны бирүче **икенче** җеп – татар мохитын тасвирлаучы **йорт җиһазлары**. Шуларның аеруча яратып сурәтләнгәне – сәке. Хәзерге заманда бер генә авыл өендә дә сәкене очрату мөмкин түгел, минемчә. Ялгыз яшәүче әби өендә дә чагыштырмача заманча җиһазлар. Сәке – шагыйрәнең балачагы. Ә балачак – беркайчан да онытылмый, җуелмый торган истәлек. Шуңа күрә сәкенең һәр почмагы аңа бүгенгедәй яхшы таныш. Ул – *өстәл дә, караватта, сандык та, әби-бабай намаз укый торган менбәр* дә. Астына *каз оясы, утын сыйган, өстенә мендәр-ястык өелгән*. Баланың күп гомере шунда узган, шуңа күрә ул аның өчен – “*йорт җиренең төп җиһазы*”, “*Җир һәм Җиһан егәре*”.

Истәлекле җиһазларның тагын берсе – чиккән сөлге. Аның белән татар хатын-кызлары өйләрен бизәгәннәр, кунакка, ашка килгән кадерле кунакларының алдына җәйгәннәр, бәйрәмнәрдә бүләк итеп биргәннәр. Чиккән сөлгедәге төсләр – *хатын-кызның күз нуры*, бизәкләр – аның *кул җылысы* һәм, билгеле, киләчәк буынга *истәлеге*.

**Өченче** төркемне – **милли ризыклар** тәшкил итә. “Тормыш яме”, “Чөгендерле катык” шигырьләрендә шуларның берничәсенә мисал табарга мөмкин. Чөгендерле катыкны татар хатын-кыз нинди дә булса бәйрәм уңае белән әзерләгән. Яраткан оныгының кунакка килүе – әбигә иң олы бәйрәмнәрдән дә мәртәбәлерәк. Ул яшь кызлар кебек йөгереп йөри, бит очлары алсуланып тора, атлап йөрүләре дә җилт-җилт кенә:

*Кыстый-кыстый сыйлый әбекәем.*

*Кунак килүенә шатлана.*

*Куе сөттән чөгендерле катык –*

*Элек дәверләрдән хаклана!*

“Тормыш яме” шигырендә лирик героиня күз алдына чын татар хатыны булып килеп баса. Беренчедән аның аш-су әзерләүгә керешүе шул хакта сөйли: башында *ак яулык*, билләрендә *ак алъяпкыч* һәм иң мөһиме – *телендә бисмилла*. Пешергән ризыгы да – әллә нинди экзотик тәгамнәр түгел, ә *токмачлы аш, кыйгачлап киселгән кош теле, каз итеннән кайнар, шулпалы бәлеш*. Ризыкларын да ул кешедән кача-поса, берүзе генә ашарга дип түгел, бөтенләй башка максат белән пешерә:

*...Чөкердәшеп, чәйләп утырыйк соң,*

*Күршеләрем дәшим, туктале.*

*Бер сөйләрлек булсын:*

*Аш-суының*

*Теш төбендә тәме калды дип.*

*Кардәш-ыру,*

*Дус-иш белән яшәү –*

*Дөньябызның яме,*

*Гаме бит!*

**Дүртенче** кызыл җеп – татар халкының атаклы **зыялылары**, милләт сакчылары. Андыйларның булуы, үзләренең эш-гамәлләре белән татар халкының җирдә яшәве турында дөньяга белгертеп торулары

белән Э Шәрифуллина чын күңелдән горурлана. “Шагыйрь чишмәсе” поэмасы әнә шундый әсәрләрнең берсе.

Поэма искиткеч тирән мәгьнәгә ия. Аның һәр строфасы милли рухны чагылдыра, татар халкының уй-хыялларын гәүдәләндерә. Поэма 17 бүлектән тора. Һәр бүлеккә шагыйрә Габдулла Тукайның бер әсәреннән эпиграф алып, шуның чынбарлык белән ни дәрәҗәдә тәңгәл килүен тикшерә. Туган авылнда аның балалары, түрләре, табыннары. Туган авыл чишмәсен – кайчандыр никрут булып кайтып, үз куллары белән чистартып киткән чишмәсе, авылдашлары яңа бура иңдереп Тукай чишмәсе дип саклыйлар. “*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым*” дисә дә шагыйрь, аның әйткән сүзләре “Кызартмады, каралтмады милли йөзне, Агартты тик, Пакьләде ул , әйе, безне!”. “Җисме үләр, исме терек бу хәзрәтне Мәшхәргәчә телләр сөйләр, язар каләм”, -дип язган шагыйрь. Халык үзен сөйгәнне онытмый: Шиһап Мәрҗәнине генә түгел, Бигивне дә, Исхакыйны да, Әмирханны да онытмый. Чөнки аларны оныттырмыйча саклаучы хис остасы, әйдәүчесе – Тукае бар. Милли рух чишмәсе саекмый, ул баеп тора дип әйтергә тели Э Шәрифуллина бу әсәрендә.

Кыскасы, Эльмира Шәрифуллина үз иҗаты белән киләчәк буынга милли бизәкләребезне, гореф-гадәтләребезне, гомумән, милли рухыбызны илтеп җиткерүне максат итеп куйган милләтпәрвәр шагыйрә ул.

**Кулланылган матур әдәбият исемлеге**


1. Шәрифуллина Э. Гөлләр елы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1988,— 104 б.— 5000.
2. Шәрифуллина Э.Зәңгәр эңгер: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.— 112 б.
3. Шәрифуллина Э. Иң матур әни: Шигырьләр, әкият-хикәятләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1999.— 40 б.— 5000.
4. Шәрифуллина Э. Мизгел: Истәлек-уйланулар. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1986.— 96 б.— 6500.
5. Шәрифуллина Э. Таң чыгы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1998.— 96 б.— 2000.

6. Шәрифуллина Э. Уйлы еллар: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 2003.—287б.—2000.
7. Шәрифуллина Э. Яңгыр җиле: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1984.— 78 б.— 1600.

# Эльмира Шәрифуллина иҗатында хатын-кыз образы

*Хәйруллина Илгизә Мофаздал кызы,*

*Талипова Гөлназ Фазыл кызы,*

*Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжының*

*татар теле һәм әдәбияты укытучылары*

Эльмира Шәрифуллинаның образлар галереясе бик бай. Бу байлык әсәрләренең тематик яктан күпкырлы булуы белән дә, тормыш чынбарлыгын тулырак чагылдырырга омтылуы белән дә бәйле. Шулай да алар арасыннан шагыйрә иҗатында күзгә бәрелеп торганнарына, аның әсәрләрендә бик еш очрый торганнарына аерым тукталып үтү кирәк. Шуларның шагыйрә иҗатында иң киң яктыртылганы – **Хатын-кыз образы.** Э. Шәрифуллина бу образны төрле яклап ача. Без шуларның берничәсен карап китик.

**Ана образы.** Аналар турында шигырьләр күп языла, ләкин Эльмира аналарның бөеклеген, изгелеген үзенчә ача. Гади итеп, шул ук вакытта кайнар хис белән, үтемле шигъри чаралар белән тасвирлый.

*Алиһә дә, ханбикә дә түгел,*

*Син гап-гади татар килене, —*

дип башлана бер шигырь. Әнә шул гади генә татар килене, итәк тулы баласы белән, икмәк үстерә, ил турында кайгырта, ирек яулап, ут-сулар кичеп кайткан иргә терәк булып, тугры гомер итә, мәхәббәтен мәңге саклый белә. Шагыйрә әйткәнчә, аның мәхәббәте, аның сөюе илне көчле итә.

“Син беләсең булыр” дигән шигырьдә лирик герой бәхеткә зур өметләр белән, матурлыкка туймас күзләре аша елмаеп, тормышка аяк атлаганда, якты хыяллары белән егылып төшкәч: “*Әйтче, әнкәй, син беләсең булыр, кайгыларның бармы бетәсе?..”* - дип, ана җилкәсенә башын сала. Аналарның үз баласы турында барысын да белүен, тоюын,

бик нечкә сиземләп, хәтта алдан күрүен сурәтли шагыйрә. Аналарны ул яңа биеклеккә күтәреп, “кояш игезәге” дип атый. Аналарның гүзәллеген, батырлыгын дәвам итүче – балалар. Нәселнең дәвамы булырга тиешлеген раслап, шагыйрә:

*Бер өлгесе итеп матурлыкның,*
*Күңелендәге ана горурлыгын*
*Илтә барыйм җиде буынга!* -

ди. Бүген нәсел-нәсәбен корытучы, баласын ташлаучы тотнаксыз “аналар”, юлдан язган хатыннар ешрак очрый барган көннәрдә, илебездә әниле килеш ятимнәр арткан елларда, ана горурлыгын байрак итеп күтәрергә кирәк. Эльмира шигырьләренең чын кыйммәте менә шуңа күрә дә зур.

Газиз балаларын фашизм тырнагыннан ничек коткарырга белми газапланган ана хисләрен шагыйрә үтемле итеп ачып бирә.

*Ташка әйләнсәм, таш бәгырем*
*сызлар,*
*Йөрәгемдә бала ярасы... .*
*Күкрәгемне көнгә ачып куям,*
*Гыйбрәт итеп йөрәк ярамны,* -

дип, фашизм тоткынлыгында газаплап үтерелгән ана монологы аша сугышның коточкыч зур җинаять икәнен тагын бер кабат безнең аңыбызга җиткерә. Мондый шигырьләрендә шагыйрә җанны уятып, күңелне кузгатып, чаң каккандай бөтен кешелеккә дәшә.

Заман рухының Ана дигән бөек булырга тиешле шәхесне төрле сынауларга куюы турында Эльмира Шәрифуллина проза әсәре аша да укучысына җиткерергә теләвен әйтеп китми булмый. Монда сүз “Җанлыдан җан яралган” дигән тагын бер җыйнак повесть турында бара. Әсәрдә үпме гасырлар үтеп тә актуальлеген югалтмаган мәхәббәт кебек үк мәңгелек проблема алынган. Ана булу бәхете хатын-кызга табигать биргән олы бүләк кенә түгел, илгә лаеклы балалар тәрбияләп

үстерү - аның изге бурычы да. Кызганычка каршы, хатын-кызларыбызның кайберләре шушы олы бурычларын фидакарьләрчә үтәп җиткерә алмый. Кыенлыклар алдында куркуданмы, әллә чиктән ашкан оятсызлык ар-касындамы, дөньяга тудырган сабыйларын язмыш иркенә ташлаучылар да бар.

Шәхси тормышындагы фаҗига белән бәйле **Тол хатын образы** шагыйрә иҗатында тагын бүтән характарда ачыла: бу – сугыш афәте тудырган бәхетсез тол хатын образы. Сугыш китергән афәтләрнең дәвамы -ил тулы тол хатыннар. Толлык, ялгызлык, ятимлек - барысы да диярлек сугыш нәтиҗәләре. Эльмира Шәрифуллинаның иҗатында тол хатыннар, ялгызлык турында шигырьләр байтак, һәм алар күңелгә көчле тәэсир итәрлек шигъри алымнар белән язылган. Беренче карашка гади генә кебек, әмма күз алдында тулы бер күренеш, чын тормыш.

*Өйдән - өйгә, җаннан - җанга*
*Шатлык керер чагында,*
*Япа-ялгыз, нәүмиз булып*
*Утырабыз табында...* -

ди шагыйрә “Күрше хакы” дигән шигырендә. Дәһшәтле сугыш күпме асыл ир-егетләрнең гомерен өзде. Әле бүген дә, тыныч еллар дигән көннәрдә дә күпме һәлакәт, күпме югалту, күпме корбаннар... Хатын-кызлар ялгыз, тол калу һаман дәвам итә... Бу – социаль кайгы. Шагыйрә ул кайгыны ил белән кичерә. Шагыйрә һич тынгылык белми. Бу хәлдән котылырга чара эзли, әмма ләкин ул чара юк.

*Ярларны сулар кага,*
*Ялгызлар суга бага,*
*Ялгызлыктан качар идем,*
*Суларда ага-ага,* -

ди лирик герой.

Бу инде чын тормыш. Монда ялган, фальш юк. “Без - бәхетле илнең бәхетле кешеләре” дип купшы лозунглар кычкыру заманы үтте.

Шигъриятгә ачы, ләкин чын тормышны чагылдырыр көн житте, Эльмира шуның көчле генә үрнәкләрен бирә. Адәм баласың табигать шулай яраткан: дөньяда тол, ялгыз булмаска кирәк, парлы яшәргә кирәк, ә пар буласы җан иясе юк... Кешенең яры булмагач, бәхете түгәрәк түгел. Ул үз мәхәббәтен эзли:

*Куырылып янасын да белә,*

*Күтәрелә әнә кояшка.*

*Эх мәхәббәт, гади тереклектән*

*Һәрчак өстен була бер башка.*

Күңел кояшка күтәрелә, янасын белсә дә үз мәхәббәтенә ашкына. Шагыйрә толлар, ялгызлар турындагы шигырьләрен мәхәббәт лирикасына сала, мәхәббәт лирикасы белән үрелдереп, бу теманы тагын да көчле тойгылар дулкынында айкый. Аның лирик герое – **гашыйк кыз образы** – әле, шашкын мәхәббәт хисләре кичереп, шуның утында яна, әле уңышсыз мәхәббәтенең салкын сагыш дәрьясында йөзә.

*Бүген мине Ул озатты,*

*Бит очларымнан үпте.*

*Беренче сөюем гүя*

*Мең төстә йолдыз чәчте.*

Тәүге мәхәббәт хисләрен кичерүче садә күңелле, самими кыз өчен сөйгәненең озата килүе, аның да бит очыннан самими үбеп алуы теләсә нинди шашкын назлаулардан күпкә өстен. Чөнки ул – беренче мәхәббәт назы, сөю-сөелүнең әүвәлге адымы.

Гашыйк кызның мәхәббәте бердәнберенә - **"Син" образына** төбәлгән:

*Син – бар, син – бер, син – бердәнбер –*

*Көн дә телдә, хәрәкәттә.*

*Мәхәббәтнең олылыгы*

*Әйләнмәсен һәлакәткә.*

("Бердәнберем")

Син образы, билгеле, шагыйрәнең тормыш иптәше Фаил Шәфигуллин образы белән тәңгәлләштерелә. Шигырьләренә күз салу белән, Э Шәрифуллинаның ирен көчле мәхәббәт белән яратуын тоярга була. Яратмаган кешең турында түбәндәге юлларны язып булмый:

*Син бары тик ярат кына мине,*

*Мин бары тик сиңа табыныйм.*

(“Син минем белән серле”)

*Кочакны тутырып*

*Бирдең, һай, ләззәтне,*

*Бүген мин кояшлы,*

*Бүген мин җәннәтле.*

(“Әллә төн матур”)

Язмышында очраган фаҗига Фаил Шәфигуллинны, иҗаты гөрләп чәчәк аткан чорда арабыздан алып китте. Күпләр яраткан язучыларыннан мәхрүм калуларын сизеп әрнесәләр, бу кайгы Э Шәрифуллина җилкәсенә икеләтә-өчләтә авыррак булып төште: ул иҗатының илһамчысын, сөйгән ирен, балаларының атасын, тормыш терәген югалтты. Ире үлгәннән соң күргән михнәтләрен горур **ялгыз хатын** аһ-зар итеп сөйләп йөрми, әрнү-газапларын эченә йотып, шигырь итеп ак кәгазьгә күчерә:

*Кояшым да юк, аем да,*

*Юк йолдызлы күгем дә.*

*Бөтенесен урладыгыз*

*Аны күмгән көнемдә...*

(“Югалттым бөтенесен”)

*Юк-бар белән мавыгу калаларда,*

*Шомлы хәбәр кайта далалардан,*

*Күзен йома шулчак кабереңнә.*

*Җәбер күргән саен башкалардан,*

*Золым килгән саен “яхшы”лардан,*

*Арта бара синең кадерең.*

(“Үзеңне алдап”)

Гашыйк кыз образы ялгыз хатын образы белән алышынса да, тормыш гел кайгы-хәсрәттән генә тормый бит. Ялгыз хатынның яралы күңелен дәваларга ул аз-азлап булса да үзенең сөенечләрен дә биреп җибәрә. Иң зур сөенеч – бала. Ялгыз хатын образы шулай итеп күңеле наз белән тулы **Әби образы** белән алышына. Моңа кадәр моң белән сугарылган шигырьләргә яңа хис – баланың баласын ярату хисе килеп керә. Бу хис шул дәрәҗәдә көчле: моңа кадәр шагыйрәнең әсәрләрендә бөркелеп торган салкынлыкны бер селтәнүдә юк итә:

*Кемнең матур улы бу,*

*Кемнең матур кулы бу?*

*Кемнең елтыр күзләре,*

*Кемнең челтер сүзләре?*

(“Балам баласы”)

Күрәсезме: бу юлларда никадәр ярату хисе чагыла! Әбинең күзенә шушы сабыйдан, аның нәни кулларыннан, елтыр күзләреннән башка берни дә күренми, челтер сүзләреннән башка бер тавыш та ишетелми. Тормыш кендеге белән шул нарасыйга береккән. Хәтта нәни бала тудырган мәшәкатьләр дә үзе бер манзара:

*Тыпыр-тыпыр табаны,*

*Түгелә бара салганы.*

*Өстәл асты җим сипкәндәй,*

*Тавыкларга калганы.*

(“Балам баласы”)

Ниһаять, мәхәббәтнең ачысын да, төчесен дә татыган гашыйк кыз, күп михнәтләр күргән ялгыз хатын үзен иң бәхетле кеше итеп тоя:

*Җитү кыз идем...*

*Ана булдым.*

*Кызым туды...*

*Әби булдым бүгеннән.*

*Бар йолдызлар кояш булып*

*Балкый кебек күгемнән...*

*Бер оныгым биргән бәхет –*

*Мең кояш назына тиң!*

(“Оныгым биргән бәхет”)

Бу хезмәттә Э Шәрифуллина иҗаты шигърият белән бәйләп тикшерелсә дә, югарыда әйтелгәннәр белән бәйләп, аның күптән түгел басылып чыккан “Мизгел” китабына тукталмый мөмкин түгел. Бу әсәрне укыгач, шундый бер чагыштыру күз алдына килә: Оренбург шәленең яхшылыгын белү өчен балдак аша чыгарып карыйлар икән. Фаил Шәфигуллинның кыска, ләкин олы гамь белән үткән тормышы алтын балдак кебек кечкенә генә бер истәлек-повесть кысасына сыеп беткән.

Кеше гомере галәм үлчәвендә үзе бер мизгел, ә мәхәббәт һәм татулык белән тулы гаиләдә ялгыз калган хатын өчен ул яшәгән кебек тә булмагандыр. Күңелендәгесен укучыга җиткерү өчен, автор газиз кешесе белән сөйләшү формасын алган. Әсәрнең эчтәлегенә, рухына тәңгәл килгән уңышлы форма. Ләкин гел хәсрәтле уйлар гына да түгел авторның башында. Яхшы кешенең якты тормышы да уйларның матурын, үзеннән калган гаиләсенә көч бирердәен, караңгы минутларны яктыртып торырдаен уйлата.

Кеше гомеренең озынлыгы кылган эше белән үлчәнә. Күз ачып йомарга да өлгермәстәй бер мизгел, ә үзеңнән соң яхшы ат калдыру өчен күпме фидакарьлек кирәк. Без дә Фаил Шәфигуллинны дөнья күргән, диңгезләр кичкән һөнәр иясе, заводта алдынгы эшче, редакциядә талант-

лы журналист, иҗат офыклары киңәйгәннән-киңәя барган әдип итеп күрәбез. Без аны тугрылыклы ир, кайгыртучан ата, эшчән кеше, олы җанлы дус, таләпчән язучы буларак таныйбыз. Җылы хисләр белән тудырылган әдәби портрет аша Фаилне шаян холыклы, туры сүзле, җырчы чишмәләрне, кара борынлы урам этләрен, ак маңгайлы бүреләрне үлеп яраткан нечкә күңелле кеше дип беләбез.

Кунак сые, хуш исле авыл мунчасы, дуслары белән җыелып утырган кичәләр кебек тормыш ләззәтләреннән дә баш тартмаган дәртле, сәламәт, яшь кеше булып күз алдында кала ул.

Автор ихтыяры белән язучының эш бүлмәсенә керәбез, ул укыган китапларны, ул ясаган рәсемнәрне күрәбез. Күләме зур булмаса да, повестьта илебезнең иминлеге, бала тәрбиясе, табигатьне саклау, мораль сафлык һ.б. мәсьәләләр турында күпләрне уйландырырлык җитди сүз бара.

Материалның күплеге кайбер язучыларны схемачылыкка алып китә торган була, вакыйгаларның өстән-өстән сөйләнүе аркасында тормыш чынлыгы бирелеп бетми, олы фикер югалып кала. Шунысы сөенечле, Эльмира Шәрифуллина материалының колы булып калмаган, җаен китереп, чама белән ул аны үз ихтыярына буйсындыра. Авторның көчле мәхәббәте, олы хисе, ихлас күңелдән сөйләве дә укучыны әсир итә. Язучының таланты гаилә эпизодларын теркәп кенә барудан коткарган. Фаил генә түгел, әсәрнең икенче герое - автор үзе дә эрудицияле, белемле, дөнья гаме белән яшәүче замандашыбыз булып гәүдәләнә.

“Синең хакта җыр язасым килә, Фаил. Эшчән, тырыш кеше булуың турында, синең гаҗәп тә сәер һәм гаҗәп тә гадәти кеше булуың хакында. Без яшәгән елларның дүрт фасылы, син колачлаган диңгезләрнең аяусыз дулкыннары, судан утка, уттан суга салып шөбһәләндергән мәрхәмәтсез соңгы төн турында. Юк, җырның сүзләре авыр кичерешле түгел, җиңел һәм дәртле, көләч һәм якты булырга тиеш. Анда, һичшиксез, син яраткан арыш шавы, муллык вәгъдә иткән яңгыр җиле,

безнең сөю бакчасында борын горткән балаларыбыз булырга, анда безнең тормышыбызның иң гүзәл мизгелләре теркәлергә тиеш...” - дип яза автор.

Ләкин андый җыр язылган лабаса инде! “Мизгел” повестен укыган кеше аны нәкъ шундый назлы җырдай кабул итә. Тик формасы, кысасы гына икенче төрле, **проза белән язылган җыр**.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Эльмира Шәрифуллина әсәрләрендә күзгә күренеп торган образлар – безнең чынбарлыгыбыз. Алар һәммәсе дә теләсә-кайсыбызга кечкенәдән яхшы таныш. Шуңа күрә шагыйрәнең шигырьләре укучы күңеленә тиз барып ирешә, анда үз урынын таба.

**Кулланылган матур әдәбият исемлеге**


1. Шәрифуллина Э. Гөлләр елы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1988,— 104 б.— 5000.
2. Шәрифуллина Э.Зәңгәр эңгер: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.— 112 б.
3. Шәрифуллина Э. Иң матур әни: Шигырьләр, әкият-хикәятләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1999.— 40 б.— 5000.
4. Шәрифуллина Э. Мизгел: Истәлек-уйланулар. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1986.— 96 б.— 6500.
5. Шәрифуллина Э. Таң чыгы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1998.— 96 б.— 2000.
6. Шәрифуллина Э. Уйлы еллар: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 2003.—287б.—2000.
7. Шәрифуллина Э. Яңгыр җиле: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1984.— 78 б.— 1600.

# Эльмира Шәрифуллина иҗатында әдәп-әхлак мәсьәләсенең куелышы

*Шаһиева Нәсимә Миргарифҗан кызы кызы,*
*Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогия колледжының*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Эльмира Шәрифуллинаның "Гөлләр юлы" дип исемләнгән шигырь җыентыгы "Хәерле иртә!" дигән шигырь белән ачыла:

*Хәерле иртә, туган җирем,*
*Илем-көнем, балаларым!*
*Уяныгыз,*
*Ямыйсы бар*
*Бу дөньяның яраларын!..*
*Офыкларда, болытларда*
*Кара тап юкмы?*
*Сабыйларның өсте бөтен,*
*Тамагы тукмы?..*

Үзе тормышның ачысын-төчесен татыган, шатлыкны да, кайгыны да кичергән Эльмира Шәрифуллинага ана хисләре, бала тәрбияләү мәсьәләләре бик якын. Аның иҗатында аналар, балалар турында бик матур, тирән мәгънәле шигырьләр бар.

*Рәнҗетмик әнкәйләрне,*
*Алар дигәнчә булсын.*
*Безнең ярдәм, җылы сүздән*
*Йөзләренә нур тулсын.*

("Рәнҗетмик әнкәйләрне")

*Бар яшәүнең сере синдә булган,*
*Бар гөлләрнең нуры – күзеңдә.*
*Яшәвемнең бөтен мәгънәсе дә*

*Булган икән “кызым” сүзендә.*

(“Күзкәйләрең нурлы чәчәк булып...”)

Яисә “Сабый көлгәндә” шигырен карыйк. Шагыйрә сабыйны дөнья кендеге итеп тасвирлавы белән һич тә ялгышмый. Халык элек-электән әйткән бит: бала булган җирдә гайбәт булмас, балалы өйдә бур тормас. Чыннан да, әгәр олылыр җыелган җирдә бер генә нәни кеше булса да, сүз күбесенчә шул бала тирәсендә була яки олылар үз сүзләрен сабый колагына ятышсыз яңгыраячак сүзләрдән сакланып сөйлиләр. Бала – гаилә тоткасы, шатлык-куаныч та, кайгы-хәсрәт килгәндә юаныч та. Сабыйның көлүе исә тормышның – бөтен, гаиләнең – нык, илнең имин булуы турында сөйли:

*Сабый бала көлгән мәлдә*
*Сихәт дәрман йөгерәдер*
*Җанга, тәнгә...*
*Гашыйк җаннар, мәҗнүн парлар*
*Назлы хәлдә...*
*Нигез, җирлек салынадыр*
*Мәгънә, мәнгә..*
*Бөтен дөнья әйләнәдер*
*Тоташ ямьгә!*

Э.Шәрифуллина аналар, балалар турындагы шигырьләрен тынычлыкны яклау темасы белән үрә. Әйе, ана, бала, тынычлык – бербөтен һәм аерылгысыз.

*Ниләр әйтеп,*
*Ниләр теләп*
*Юатыйм соң сине, Ана?*
*Чигә чеңли –*
*Чечня чаңы –*
*Дин кардәшем утта яна...*

*Газиз Ана,*
*Моңлы Ана*
*Күзләрендә сагыш яна.*

("Кемгә якты, кемгә...")

Баласын тартып алган сугыш уты ялкыны – Ана күзләрендә. Бу шигырь күңелне тетрәтерлек киеренке тойгылар белән, шагыйрә үзе әйткәнчә, «телем-телем туралган җан» белән язылган. Укучы күз алдына җанлы кешеләр булып килеп баса торган, чын шигъри чаралар белән сәнгатьчә эшләнгән аналар, балалар – сугыш җәфаларын, газапларын күп кичергән, фашизмның корбаннары булган күп миллионнар шагыйрә йөрәге аша уза.

Тынычлык – тормышның терәге. Кеше күңеленә иминлекне сакларга омтылу орлыклары бала сабый чакта ук салынырга тиеш. "Оясында ни күрсә, очканында шул булыр" ди халык. Э Шәрифуллина шигъриятендә дә бала тәрбияләү проблемалары мөһим мәсьәлә булып кала. Алар аеруча шагыйрәнең балаларга багышлап язылган әсәрләрендә ачык күренә.

Шагыйрәнең "Иң матур әни" җыентыгына кергән шигырьләре баланы дөнья белән таныштыруны максат итеп куялар. "Елмаегыз, көлегез", "Яз җыям", "Килегез, кунак булырсыз", "Нәни музыкант" шигырьләре шуңа мисл булып тора. Ләкин игътибарны аның башка әсәрләре җәлеп итә. Шуларан чыгып, Э. Шәрифуллинаның бу өлкәдәге иҗатына педагогик карашларның төс булуын билгеләп үтми мөмкин түгел. Автор, бала психологиясен тоеп, ул булып яисә нинди дә булса табигать күренеше сыйфатында балага тәрбия бирә.

Мисалга "Әгәр әни булсам..." шигырен алып карыйк. Соңгы елларда кыз балаларны тәрбияләүдә зур җитешсезлекләр күзгә бәрелә: кызлар намуслы, әхлаклы, саф булырга тиеш дигән борынгыдан килгән карашлар күз алдында эреп юкка чыгалар. Мәктәп яшендәге кызларның

әхлаксызлыгы, аларны бизи торган тыйнаклык, мөлаемлылык, сафлык кебек сыйфатларның җуела баруы, 16-17 яшьтә, ана булырга теләү максаты белән түгел, ә тотнаксызлыгы аркасында бала табуы – җәмгыятьнең иң зур проблемасы. Теләсә кайсы кыз – киләчәктә булачак ана. Ул – алдагы буынны җиһанга тудыручы. Ә нинди бала үстереп тәрбияләү аның үзеннән тора. Югарыда атап кителгән шигырь, минемчә, – теләсә кайсы кызның тормыш программасы булырлык әсәр. Ана булырга хыялланучы кыз бала үз-үзенә нинди җаваплылык алуын яхшы аңлый: ул кызларын тегәргә, чигәргә, юарга өйрәтергә тиеш. Тик иң мөһиме әле бу гына түгел:

*Сөембикәдәй*

*Сылу, сөйкемле,*

*Туган халкыма*

*Сүзе үтемле,*

*Олы йөрәкле*

*Ана иттереп,*

*Бирер идем күп*

*Кызлар үстереп,*

*Әгәр дә мәгәр*

*Мин әни булсам!..*

Гаилә иминлеге – аның терәге нык булуда. Ә теләсә-кайсы гаиләдә терәк – ата кеше. Үз бурычын дөрес аңлаган аталы гаиләләр таркалмый. Гаилә кору егет белән кызның үз иңнәренә билгеле бер күләмдә һәм дәрәҗәдә җаваплылык алу дигән сүз ул. Ананың бурычларын карап киттек инде. Шагыйрә ата вазифаларына да битараф түгел. Ул аны читләтеп үз укучысына җиткерә. Мисалга “Ата каз” шигырен алыйк. Беренче карашка, бала гап-гади йорт кошы – каз турында шигырь укый:

*Күргәнегез бармы сезнең*

*Ата каз биегәнен?*

*Нәни бибиләре чыккач,*

*Кычкырган, сөенгәнен?*
*Ул каңгылдап, әнкә казны*
*Яратып сөйләшкәнен.*
*Сары йомгак бәбкәләргә,*
*Җан-җан, дип эндәшкәнен.*
*Җаннарым, дип эндәшсә дә.*
*Юаш икән бу, димә.*
*Ата каз янында сак бул,*
*Бәбкә янына килмә!*

Тик бу алай түгел. Ата каз образы аша автор әти кешенең нинди булырга тиешлеген искәртә: балаларының анасын яратучы, балалары өчен җан атучы, гаиләсен бәла-казалардан саклаучы зат ул әти кеше!

"Абыйга ярамый" шигырен алсак, анда да Э. Шәрифуллина җәмгыятебезнең күптәннән килә торган чиренә туктала. Бу – бала тәрбияләүдә очрый торган тагын бер җитешсезлек – олы һәм кече баланы тәрбияләүгә карата ата-ана мөнәсәбәте. Шигырьдәге Сәйдәш – зур абый, ә Сәгыйть – аның энесе. Гаиләдәге кече бала – иң иркә бала булучан: "*Әйтәм, дип, әтигә, Куркыта абыйсын*"; ясаган рәсемнәре чынбарлыкка туры килеп бетми: "*Колыны – мөгезле, Мәчесе – мыексыз*"; кыланмышы да тәртип-әхлак нормаларына туры килеп бетми: "*Егылса, еласа, аунаса, тормаса, Әйтмичә китсә дә, Этенә типсә дә, Алмашып кисә дә Сандалын Сөнгатьнең – Ярый шул Сәгыйтькә*".

Ата-ананың күзе сукыр, алай гына да түгел, алар үзләре дә сизмичә ике бала арасына киртә коралар: "*Ярамый Сәйдәшкә, Барса да киңәшкә Янына Сәгыйтьнең*". Кече энесенең җитешсез якларын әлегә үзе читкә тибәрелгән олы бала гына күрә. Әгәр тәрбия эшләре шул рәвешчә барса, тиздән ата-ана үзе дә күрә башлаячак, тик соң булмасын дип кисәтә үз укучысын шагыйрә.

Югарыда телгә алган өч шигырь үрнәгендә генә дә гаилә турында бик матур тәрбияви чара үткәрергә мөмкин булыр иде. Чөнки галимнәр ни генә әйтсәләр дә, тәрбия беренче чиратта гаиләдә башлана.

**Кулланылган матур әдәбият исемлеге**


1. Шәрифуллина Э. Гөлләр елы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1988,— 104 б.— 5000.
2. Шәрифуллина Э.Зәңгәр эңгер: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.— 112 б.
3. Шәрифуллина Э. Иң матур әни: Шигырьләр, әкият-хикәятләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1999.— 40 б.— 5000.
4. Шәрифуллина Э. Мизгел: Истәлек-уйланулар. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1986.— 96 б.— 6500.
5. Шәрифуллина Э. Таң чыгы: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1998.— 96 б.— 2000.
6. Шәрифуллина Э. Уйлы еллар: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 2003.—287б.—2000.
7. Шәрифуллина Э. Яңгыр җиле: Шигырьләр. / Э. Шәрифуллина — Казан, 1984.— 78 б.— 1600.

# Матур эшләр эшлик җирдә, якты эзебез калсын.

**(***Шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның*

*иң соңгы җыентыкларының берсенә күзәтү)*

*Әхмәтшина Л.М.*

*Минзәлә шәһәре 3 нче мәктәбе*

Танылган әагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эльмира Шәрифуллинаның шигърияттә үз тавышы, үз йөзе, үз темасы бар. Аның йөгерек каләме милләтне милләт иткән изге гөреф-гадәтләрне, йолаларны җырга әвереллерә.

2014 нче елда Татарстан китап нәшриятендә чыккан, китап тышлыгында бары авторның исем-фамилиясе генә торган җыентыкта балалар өчен шигырьләр, җырлар, сценарийлар,әкиятләр, хикәяләр, табышмаклар тупланган. Җыентыктагы һәр бүлеккә күзәтү ясыйбыз:

1.Кояшлы табын.

2. Белем юлы.

3. Җырлы бәйрәм.

4. Иң матур әни.

5.Баллы бавырсак.

6. Илем минем.

Балаларга аңлаешлы, җиңел тел белән язылган шигырьләр, хикәяләр аша укучы тирә-юньне танып белергә өйрәнә.

6. Әбәк (табышмаклар, уен өчен шигырьләр, үртәвечләзр, әйтемнәр, тизәйткечләр).

7. Мәкәрҗә кунаклары (шигъри әкиятләр, мәсәлләр)

8. Карга боткасы (сценарийлар)

9. Зирәк кәҗә (нәни пьесалар, мюзикллар)

10. ТӘрҗемәләр.

Маҗаралы вакыйгаларга корылган әкиятләр үсемлекләр, хайваннар дөньясы белән таныштыра. Кызыклы табышмаклар балаларның уйлау, фикерләү сәләтен үстерә. Китапка кергән сценарийлар нәни укучыларга табигать, бәйрәмнәр, язучылар иҗаты, тарихи шәхесләр турында бай мәгълүмат бирә. Аларны балалар бакчаларында, мәктәпләрдә бәйрәмнәр, кичәләр уздырганда файдаланырга мөмкин.

Китап мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга, ата-аналарга, укытучыларга, тәрбиячеләргә, татар балалар әдәбияты белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

## Г.Ибраһимовның башлангыч чор әдәби тәнкыйть эшчәнлеге.

Татар әдәбиятының һәр чорында тәнкыйть фикере булган. Ә менә XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте, иҗтимагый фикернең бер төре буларак, нык үсеп киткән. Бу юнәлештә Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Камаллар актив эшләгәннәр. Бигрәк тә 10нчы елларда нәшер ителгән "Шура", "Аң", "Мәктәп" журналларында матур әдәбият, әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә зур урын бирелгән. Тәнкыйди фикер камилләшкән, тәнкыйтьчеләрнең профессиональ осталыгы да үсә барган. Җ.Вәлиди, Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирханнар реалистик юнәлештә эш алып барганнар, әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә мөһим социаль, милли мәсьәләләр күтәргәннәр. Әдәби тәнкыйтьнең реалистик юнәлеше белән янәшәдә, сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре калыплашкан. Романтик тәнкыйть татар әдипләренең, галимнәренең гыйльми-нәзари эзләнүләре, төрле теоретик концепцияләрнең, Рус-Европа әдәбият белемендә формалашкан әдәби мәктәпләрнең тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Романтик тәнкыйтьнең теоретик нигезе, фәнни концепциясе, бигрәк тә, Г.Ибраһимов хезмәтләрендә эшләнгән. Г.Ибраһимовның бишенче томында тупланган язмалар шул хакта сөйли. Әлеге язмаларда яшь тәнкыйтьче үз чорында иҗат иткән әдипләргә, аларның әсәрләренә үз мөнәсәбәтен белдерә барган; үзендә милли әдәбият һәм сәнгать язмышы өчен зур җаваплылык тоеп, әдәби иҗат һәм эстетиканың катлаулы мәсьәләләрен күтәреп чыгарган.

10нчы елларда язылган "Әдәбият мәсьәләләре", "Татар матбугаты", "Яңа әсәрләр" "Татар шагыйрьләре", "Тәрҗемә һәм аның шартлары" исемле хезмәтләргә тукталып үтәм.

"Әдәбият мәсьәләләре" исемле мәкалә өч бүлектән тора. Беренчесе "Тәгъриф"(билгеләмә) дип атала һәм анда автор "әдәбият" төшенчәсенә аңлатма бирергә омтыла. Фәнни, фәлсәфи, әдәби әсәрләрнең барысы да

әдәбиятка керә, ди. Әдәбиятның төп үзенчәлеген тормышның төрле күренешләрен чагылдыруда, хис һәм хыялга тәэсир итүендә дип күрсәтә.

Икенче бүлек “Халык мосаннәфате” дип аталып, анда әдип халык авыз иҗаты мәсьәләләренә туктала. Халык авыз иҗатының ничек тууы, халык арасында ничек таралуы турында сөйли. Аларны җыю, туплау кирәклекне искәртә. Әдәби һәм тарихи мирас булган халык авыз иҗаты яшәргә, буыннан - буынга тапшырылырга тиеш, ди. Татарларда бу эшнең торышы бик түбән булуын билгеләп үтә. Бары бер әдипне генә бу эштә үрнәк итеп куя. “Бу турыда һәркемнән артык мәшһүр шагыйребез Тукаевка бурычлыбыз. Ул үзенең матур вә шагыйрәнә җөмләләре илә шул гавәм әкиятләрен тасвир итеп, һәркем тарафыннан сөелеп укылырлык бер хәлгә куйды. Мәсәлән, аның күптәннән чыккан “Шүрәле”се, “Су анасы” буның иң гүзәл нәмүнәләреннәннәндер(үрнәкләреннәндер)”, - ди. [4, 28б.]

“Шигырь» дип аталган өченче бүлектә тәнкыйтьче шигърияттнең гомуми хәле өчен борчыла. Шул чорда иҗат иткән З.Бәшири, М.Укмасый, М.Гафури, Н.Думави, С.Рәмиев әсәрләрен анализлап, җитешсезлекләрен күрсәтә. Төп кимчелек дип, шигырьләрнең тирәнлеге сай булуны, тематик киңлек җитмәүне саный. Ә Г.Тукай әсәрләреннән ул канәгать булуын белдерә.

“Татар матбугаты” мәкаләсендә Г.Ибраһимов унынчы елларда татар матбугаты эшенең торышы турында яза. Бу чорда газета-журналларның күпләп чыгарылуын, аларның сыйфатсыз язмалар белән тулуын күрсәтә. Теләсә кем шигырь язды, теләсә кем хикәя бастырды, ди автор. Моны ул тәнкыйтьнең көчсез булуыннан күрә. “Наширләр дә, тәнкыйть куәте сай булганга, баш максат парә(акча) булганга, килгәнне алдылар, басып тараттылар. Шулай итеп, татар көтепханәсе канунсыз, юлсыз, мәгънәсез язылган әсәр белән тулды. Ләкин зарар юк. Бу дәвер безнең өчен тәҗрибә вә гыйбрәт дәвере иде. Һәр милләт башыннан үткәргән “каләм сынау дәверен” без дә үткәрдек. Һәркем бер тәҗрибә, дәрес алды,”- ди.[4, 6б.] Соңрак инде шагыйрь исемен йөрткән күпләрнең каләм мәйданыннан

төшеп калуын күрсәтә. Ә Г.Тукай иҗатына югары бәя бирә. Татар шагыйрьләре арасында аның иң зурысы булуын әйтә: “Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле вә галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗәдә ки: татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр”, - дип яза. [4, 6б.]

1913нче елда дөнья күргән “Татар шагыйрьләре” хезмәтенең I-II бүлекләрендә Г.Ибраһимов С.Рәмиев һәм Дәрдемәнд әсәрләренә җентекле анализ ясый. Алар иҗатындагы уңай һәм кимчелекле якларны ачып бирә.

Шагыйрьләр арасында бик аз язганы, әмма иң талантлысы дип, С.Рәмиевне күрсәтә. “Аның барлык шигырьләрен игътибар, дикъкать илә укып чыгу – аның бөтен рухын, барлык куәтен күз алдыңа ача да куя... Аның һәрбер сүзе йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап, рухының төбеннән, эчке нокталарыннан ялкынланып килеп чыга.”[4, 77б.] Иң яхшылары дип, “Авыл”, “Таң вакыты”, “Дөньяга”, “Ул”, “Пигамбәр” кебек шигырьләрен билгели.

Г.Ибраһимов Дәрдемәндне С.Рәмиев белән янәшә куя. “Татар телен сөеп, аның эчендә аз булса да, матур яза, нәзек хис итә, хыял вә тойгыларын яңа галәмнән алып, аны нәфис өслүбтә әйтә.” [4, 97б.] Шагыйрьнең әсәрләрендә аз сүз белән дә күп мәгънә белдерелүен, гарәп-фарсы сүзләренең дә аның шигырьләрендә ярашлы кереп утыруын, әдипнең сурәтләү чараларыннан оста файдалануын күрсәтә. Дәрдемәнд шигырьләрен анализлап, аның күңел төшенкелегенә, өметсезлеккә бирелгән кеше булуын

III бүлектә Г.Ибраһимов Г.Тукай әсәрләренә туктала. Яшь тәнкыйтьче шагыйрьнең башлангыч чорга караган әсәрләренең телен, стилен тискәре бәяли. Табигатьне тасвирлый алмауда, мәхәббәт шигырьләре яза белмәүдә гаепли. Ә алда инде әдип теленең сафлануын, чит тел сүзләреннән арынуын күрсәтә. Тәрҗемә эшендәге осталыгына игътибар итә. Тукай иҗатындагы тематик байлыкны, көчле сатираны билгеләп үтә. Тукай иҗатының халыкчанлыгын ачып бирә. “Шул заманда халык ни уйлый, ни

хис кыйла – Тукаевта да шул”, - дип, Тукай поэзиясенең бу күркәм сыйфатын кимчелек итеп күрсәтә. “Халык үзендәге тәэссератны(тойгы), әфкяр(фикер) вә хиссиятне Тукаевта таба. Бу куәт вә кабилият(сәләтлелек) ноктасыннан артык мактаулы эш түгел, ләкин халык каршында күтәрелү, илтифатка керү, дикъкатькә алыну өчен моннан да уңайлы талант юктыр. Һәм Габдулла әфәнденең “шагыйрь Тукаев” урынын тота алуының бөтен сере дә шундадыр”, - ди, ягъни аны халык мәнфәгатен кайгыртуда гаепли. [4, 142б.],

Бу тәнкыйть әсәренә чаклы язган мәкаләләрендә Г.Тукай иҗатына автор тарафыннан югары бәя бирелә. Нигә аның карашлары кискен борылыш алды икән? Бу сорауга әдәбият галиме М.Хәсәнов фикерләренә иярәсе килә: “Ибраһимовның ул еллар тәнкыйть практикасындагы романтик берьяклылык, “саф сәнгать” йогынтысына бирелүенең нәтиҗәсе”.[4, 534б.]

“Тәрҗемә һәм аның шартлары” исемле язмада әдип тагын бер мөһим мәсьәләне алга куя. Ул – тәрҗемә эше. “Чит телләрдән үз теленә мөнасиб(файдалы) әсәрләрне тәрҗемә кыйлмак һәр милләтнең әдәбиятында мөһим бер урын тотадыр. Безнең кеби гыйлем вә тәмәддενгә (культуралылыкка) яңа керә башлаган бер милләтнең үз әдәбиятын баетуына, гыйлем вә фән илә ашналануына(якынаюына) хезмәт җәһәтеннән караганда, тәрҗемәчелек дәхи артык әһәмият, хәтта зарурат(зарурлык) мәртәбәсен алганлыгы мәгълүмдер”, - дип, тәрҗемә эшенең кирәклеген искәртә.[4,38б.] Әмма теләсә нинди әсәрне тәрҗемә итәргә ярамый, татарларның фикер үсешенә туры килгәнен, ярашлысын гына сайларга кирәк. Тәрҗемәче дә әсәрнең идеясен укучыга җиткерерлек дәрәҗәдә оста һәм сәләтле булырга, ике телне дә камил белергә тиеш, ди.

Г.Ибраһимов тәрҗемә итүнең ике төрен күрсәтә: сүзгә-сүз тәрҗемә ясау һәм эчтәлекне бирү. Әдәби әсәрләрне (хикәя, романнарны) тәрҗемә итүчеләргә икенче юлны тәкъдим итә, чөнки әсәрнең бер өлешен, яисә төрле урыннарын чүпләп тәрҗемә итү отышлы түгел. Ә менә гыйльми, фәнни, иҗтимагый мәсьәләләрне яктырткан әсәрләрдә укучыга төп фикерне

җиткерү шарт, хезмәтнең төп мәгънәсен бирү файдалы, дип күрсәтә. Фән турында иң гомуми төшенчәләрнең генә зарурлыгын әйтә.

Әлеге хезмәтләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә була: 10 нчы елларда Г. Ибраһимов тарафыннан шигърият хакында, аның асылы һәм үзенчәлеге турында мөһим күзәтүләр ясалган. Шигъри талант һәм поэтик иҗат процессы турында игътибарга лаеклы оригиналь фикерләр әйтелгән. Яшь тәнкыйтьче XX гасыр әдипләре: Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд һ.б. иҗатына игътибар иткән, аларның әсәрләренә анализ ясап, бәхәсле һәм каршылыклы булса да, үз фикерләрен белдергән. Халыкны аңлы, белемле итүдә, милли культураны алга җибәрүдә тәрҗемә эшенең дә кирәклеген искәрткән. Кыскасы, Г.Ибраһимов унынчы елларда ук үзен тирән белемле, киң эрудицияле, принципиаль тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече булуын күрсәткән һәм аның хезмәтләре әле бүген дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаган.

## Кулланылган әдәбият


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Гыйләҗев Т. Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.
3. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман. – Казан: Татар. кит.нәшр.,2000.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 т.: 5т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. - Казан: Татар.кит.нәшр.,1978.
5. Миңнегулов Х. Й. Гасырлар арасында уйланулар. – Казан: Татар кит.нәшр., 2010.

# Галимҗан Ибраһимов хикәяләрендә фразеологизмнар

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы*
*«Арча 7номерлы урта гомуми белем мәктәбе»*
*муниципаль бюджет белем учреждениесеенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
***Файзуллина Алсу Мостафа кызы***

## Кереш

*“Бер генә күреп, бер генә сәгать сөйләшеп,*
*гомергә хәтердә кала торган кеше сирәк очрыйдыр.*
*Шундыйларның берсе минем өчен татар халкының*
*бөек язучысы Г.Ибраһимов булды.”*
*С.Ариш*

Галимҗан Ибраһимов! Бу әдипне белмәгән, аның әсәрләрен укып ләззәтләнмәгән берәр кеше бармы икән?! Мөгаен, юктыр.

Яраткан язучысы хакында берәүдән: “Ни өчен яратасың аны?-дип сорасалар, мөгаен ул да бу сорауга өздереп кенә җавап бирә алмас иде. Әлеге фәнни эшемне язарга утыргач,мин дә үземә шул сорауны бирдем. Юк, мин дә ни өчен яратканлыгымны тулысынча әйтеп бетерә алмыйм шул: бәлки Галимҗан Ибраһимовның кабатланмас иҗади стиле өчендер, бәлки үз чорын шундый тирәнлек белән күрсәтә алганы өчендер...

Мин аның берничә хикәясе белән таныш. Ләкин шулардан минем йөрәгемә аеручa якын. Бу – «Яз башы», «Карт ялчы», «Табигать балалары»

Аларда бер үк чорда, бер үк төбәктә яшәгән геройлар , образлар тасвирлана һәм алар һәммәсе уртак максат, уртак авырлыклар, уртак сагыш белән яшиләр.

Кешеләр үз язмышларына үзләре хуҗа булсалар да, сугыш аларның тормышларын бер “казанга салып” уртак сагышлар алып килә. Шуның өстенә һәрбер шәхеснең үз фаҗигасе, үз хәсрәте өстәлә.

Ә хәзер Г.Ибраһимовның портретына игътибар итик. Портрет аша

язучының характер үзенчәлекләрен билгели алабыз. Кырыс акыллы йөз, кискен сораулар белән төбәп караучы күзләр, күпне күргән, кичергән булуы турында сөйләүче йөз чалымнары, олылык, олпатлылык, азамат ирләрчә мәһабәтлелек, ныклык.

Мин истәлекләрдән, портреттан чыгып, язучы турында кыскача мәгълүмат ясадым. Әдипкә биргән характеристика дөресме икән? Шуны ачыклау йөзеннән мин сезгә аның тормыш юлын сөйләп үтәм.

Г.Ибраһимовның сабый чагы Башкортстан җирендә, табигатьнең күркәм байлыгы белән бизәлгән Солтанморат авылында уза. 1887 елның 12 мартында элекке мөгаллим мулла гаиләсендә туа. Галимҗан башта үзенең туган авылы Солтанморатта укый, 3 класслы башлангыч рус мәктәбенә дә йөри. Бер елны Гыйрфан абзый Шакирҗан белән Галимҗанны Оренбургка алып китә. Анда баргач, Галимҗанны кадим мәдрәсәгә – Вәли мулла мәдрәсәсенә урнаштыра. Галимҗан әти-әнисен, бик сагынып, иң җылы хисләр белән искә ала.

Әти-әнисе турында болай ди: «... Әти безне бик иркәли иде дип әйтә алмыйм. Андый кеше түгел иде. Шулай да ул безне кеше итәргә бик тырышты. Заманы өчен үз даирәсендә алдынгы кеше иде. Шуңа күрә указын кайтарып, муллалыгын ташлады, гомеренең соңгы көннәренә чаклы гади крестьян булып үткәрде. Башта ул минем язучы булып китүемә шактый кырын карады.... Минем беренче әдәби адымнарыма кырын каравы аның язучылык эшенә ихтирамы булмаганлыктан түгел, ә минем, үз эшемне тиешенчә булдыра алмыйча, тормышта үзенең урынын, сәләтен таба алмаган кеше булып калуымнан куркуы булгандыр дип уйлыйм. Ул исән чакта минем кайбер хикәяләрем басылып чыкты. Боларны күреп шатланды гына. Минем тормыш юлыма, җәмгыятьтәге урыныма ышана иде...»

«Әнием бик миһербанлы, эшчән, кунакчыл иде. Без аны бик ярата идек. Ләкин бик кызганыч, иртә үлеп китте...»

Солтанморат авылы тирәсендәге матур табигать күренешләре аның күңеленә тирән тәэсир ясый:анда очсыз-кырыйсыз тигезлеккә ямь биреп, җәйрәп яткан көзгедәй күлләр, боргаланып аккан елгалар, авыл кырыннан ук

башланып киткән иген басулары, яшел тугайлар, ә авылның икенче ягында биек-биек таулар, калын урманнар, Галимҗанга әкияттәге сыман сихри, җырдагыдай серле күренәләр. Чөнки Галимҗан әйләнә-тирәне күзәтүче, табигатьтәге һәр үзгәрешне сизгер тоючы, туган якларының очсыз-кырыйсыз табигать байлыкларына карап тәэсирләнүче, шигърияткә омтылучы малай була. М.Ибраһимов та болай искә ала:

«Бу җирләрнең сихри матурлыгы Галимҗанны нечкә күңелле әдип итеп тәрбияләп үстермәдеме икән?» Мөгаен, бу сүзләрдә хаклык бардыр. Аның табигать турындагы язган әсәрләре әлеге сүзләрне раслыйлар. Аның әсәрләрендә кояш нурының җылысы да, талгын искән йомшак җил дә, боргаланып аккан чишмә тавышы да ишетелә. Гүзәл табигать кочагында үткән балачакның күңел түрендә уелып калган истәлекләре соңыннан язучының әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Бала чакта Галимҗанның тормышы башка крестьян малайлары тормышыннан берни белән дә аерылмый. Җәйге төннәрдә малайлар белән бергәләп, яланга яисә урманга ат сакларга китә, җиләккә йөри, елгада һәм кондызлы күлдә балык каптыра. Кыскасы, Г.Ибраһимов – табигатькә гашыйк кеше була.

Үземнең кереш сүземне Галимҗан Ибраһимовның тормыш иптәше Гөлсем Мөхәммәдова сүзләре белән йомгаклыйсым килә: «Галимҗан – бала җанлы кеше иде...Моңа инаныр өчен аның әсәрләрен укып карау да җитә.Аларны бөек язучы һәм бала җанлы кеше язган.Ә бөек язучы – үз күңелендәге балалыкны җуймаган кеше ул».

## Төп өлеш

### Фразеологизмнар-телебезнең җәүһәрләре.

Тел – кешелек җәмгыятендәге гаҗәеп үзенчәлекле , катлаулы һәм гаять әһәмиятле күренеш. Аның кайсы гына өлкәсен алып карасаң да, анда кызыклы, мөһим фактларга тап буласың, әллә никадәр яңалыклар ачасың. Дөньяны танып-белү кебек үк,телне өйрәтүнең дә ахыры-чиге юк, күрәсең.

Фразеологизмнарның мәгънәләре дә, формалары да күп төрле.Иң башта

алар билгеле бер төшенчә белдерә торган тотрыклы сүзтезмәләр (ачык йөзле, баш бәясе, ис китү, җилкәдән төшмәү һ.б.) һәм дидактик мәгънә белдерә торган, хөкем йөртүгә, фикерләүгә корылган тотрыклы җөмләләр(эшләмәгән ашамый, без капчыкта ятмый, тырышкан табар, ташка кадак кагар һ. б.ш) дигән төрләргә бүленәләр. Аларның беренчеләрен фразеологик берәмлекләр дип,икенчеләрен киң пландагы фразеологик әйтелмәләргә керә торган мәкальләр дип атарга мөмкин. Монда шуны да әйтик, мәкальләрне фразелогизмнар исәбенә кертү- кертмәү мәсьәләсендә тел галимнәре арасында бердәм фикер юк: берәүләр-кертү ягында, икенчеләре-каршы. Мондый фикер башкалыгына китерә торган сәбәпләр дә бар. Шуның берсе-иң мөһим дип түбәндәге фактны күрсәтергә кирәк. Тотрыклы сүзтезмәләр сөйләмгә, сүзләр кебек үк, бербөтен һәм әзер тел материалы буларак керәләр.Аларның кайберләрендәге күчерелмә мәгънә аерым сүз белән белдерә ала аның күңеле-эчкерсез саф; баш ию-буйсыну; күз яну-кызыгу һ.б.).Шуңа күрә дә фразеологик тезмәләрне сүзләр рәтендә һәм лексиканың бер тармагы итеп карыйлар. Мәкальләрне исә мәгънә ягыннан да, формасы белән дә сүзләргә тиңләп һәм лексик берәмлек итеп карап булмый.

Фразеологик сүзтезмәләр, тотрыклы берәмлек буларак, сөйләмгә әзер, бөтен килеш керәләр дидек. Әмма аларны сүзләр белән бер ясаллыкта карарга ярамый, чөнки алар лексик-грамматик мәгънә һәм структура ягыннан сүзләрдән, шул исәптән тезмә сүзләрдән дә аерылалар.

Тезмә сүзләр, нигездә, исемнәргә һәм фикерләргә карый һәм күбесенчә ике сүздән тора (җир җиләге, мәче борчагы, уйлап табу) өчәр һәм аннан да күбрәк сүздән торганнары сирәк очрый. Фразеологик тезмәләрнең мәкаль әйтемнәр, канатлы сүзләр, афоризмнар белән дә уртак сыйфатлары бар. Мәсәлән, аларның барысына да тотрыклы, береккән булу, күчерелмә мәгънәдә кулланылу, образлылык-сурәтлелек хас.

Фразеологизмнарның бизәк сыйфатларын аерым мисалларда карап китик.

**Берне биш итү** (арттырып, күпертеп сөйләү) дигән фразеологизмда биш сүзе шулай ук аллитерация төзү, бер төрле авазларга башланган сүзләр булсын

өчен кулланылган.

Халкыбыз тарафыннан күп йөз еллар буенча иҗат ителеп килгән тел җәүһәрләре булган фразеологик әйтелмәләрдә тирән мәгънә, фикер, коллектив акыл һәм тәҗрибә сәнгатьле һәм сурәтле итеп матур бизәкләр ярдәмендә белдерелгән.

Фразеологизмнар барлык телләрдә дә бар. Ике яки берничә телдәге әнә шундый тотрыклы сүз тезмәләрен чагыштырып өйрәнү аларның табигатен тагын да тулырак ачарга, төрле телләрдәге фразеологизмнарның үзара нисбәтен, гомуми һәм үзенчәлекле якларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Әйтергә кирәк, байтак телләр өчен уртак булган бер үк мәгънәдәге фразеологик әйтелмәләр дә очрый. Аларның күбесе кешеләрнең дуслыкка турылыклы булу, тату яшәү, гаделлек, тырышлык, кыюлык һәм б.ш. кебек сыйфатларын белдерәләр.

Тагын шунысы да кызык: төрле телләрдә гомуми күчерелмә мәгънәләре генә түгел, аерым сүзләрнең туры мәгънәләре, афоризмлылыгы, образлылыны һәм эмоциональ –экспрессивлылыгы да туры килә торган фразеологик әйтелмәләр дә шактый күп. Мәсәлән, татар һәм рус телләрендәге **баш вату - ломать голову, күзгә күз - с глазу на глаз**, кебек әйтемнәр дә әнә шундыйлар.

Әйтемнәргә йомгак ясап, шуны өстәргә кирәк, сөйләмне эмоциональ,тәэсирле , бизәкле итә торган фразеологик сүзтезмәләрне, аерым сүзләргә тиңләп,лексиканың бер өлеше дип карау чынбарлыкка туры килеп бетми. Алар, гомуми күчерелмә мәгънәдәге сүзтезмәләр буларак, мәкаль-әйтемнәр, канатлы әйтелмәләр, афоризмнар белән бергә телнең үзенә бертөрле катламын тәшкил итәләр. Шуңа күрә аларның барысын бергә фразелогизмнар яки фразеологик әйтелмәләр дигән гомуми исем белән атау максатка ярашлы булыр иде.

### Галимҗан Ибраһимов хикәяләрендә фразеологизмнар

Фразеологик әйтелмәләр-халык иҗаты. Аларда халыкның тапкырлыгы чагыла. Алар кыска һәм оста әйтеләләр,гадәттә уткен һәм образлы сүзләрдән торалар. Шунлыктан әдәби әсәрләрдә төп сурәтләү чараларыннан исәпләнәләр.

Ә хәзер карап үтик: Галимҗан Ибраһимов ninди фразеологизмнар кертте икән үз әсәрләренә.

Язучы-шагыйрь теленең халыкчанлыгын, милли үзенчәлеген, сыгылмалылыгын, гади һәм табигыйлеген татар халкының фразеологик берәмлекләреннән башка күз алдына китереп булмый. Мәшһүр әдип Галимҗан Ибраһимов та татар теленең сүзлек хәзинәсе булган фразеологик фондтан уңышлы файдалана. Алың сүз белән сурәт ясау остасы икәне һәркемгә мәгълүм. Әсәрләрендә кулланылган һәр сурәтләү чарасы аерым өйрәнүгә лаек. С.Ш.Поварисов, И.Б.Бәширова, Ф.М.Газизов, М.Ә.Сәгыйтов кебек галимнәрнең хезмәтләре Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең телен һәм стиль үзенчәлекләрен өйрәнүнең бер мисалы булып тора.

Мин дә Г.Ибраһимовның хикәяләрендә кулланылган фразеологик, әйтелмәләрне тикшерүне максат итеп куйдым. Аның прозасында кулланылган фразеологик әйтелмәләрне өч төргә бүлеп карадым:

1) традицион фразеологик әйтелмәләр:

2) трансформацияләнгән яки үзгәртелгән фразеологик әйтелмәләр;

3) индивидуаль фразеологик әйтелмәләр.

1. Традицион сурәтләү чаралары гасырлардан-гасырларга әсәрләрдән-әсәрларгә күчеп килә. Г.Ибраһимовның «Яз башы», «Карт ялчы», «Табигать балалары», «Карак мулла», «Диңгездә» кебек хикәяләрендәге традицион фразеологик әйтелмәләргә күз салсак, язучының фразеологик әйтелмәләр белән оста эш йөртүен һәм алдагы буын язучыларына өлге-үрнәк күрсәтүен күрәбез. Аның «Яз башы» дигән хикәясендә, мәсәлән, традицион фразеологик әйтелмәләр шактый күп кулланылган. Бу хикәядә баш герой Салихның, озак вакытлар әнисе белән аерылып торганнан соң, яңадан очрашу халәте болай сурәтләнә: «Боларның нидән вә ни өчен килгәнен мием белмәсә дә, *эчем сизә* иде. Йөрәкнең әллә кай җирләреннән кайнап чыккан бу яшьләргә эремәскә *көчем җитмәде,* белмим, нидәндер *күңелем йомшарды».* Мисалдан күренүенчә, язучы *эч сизү, көч җитмәү, күңел йомшару* дигән традицион фразеологик берәмлекләр белән эш итә.

«Һәр нәрсәм, һәр теләгем камил, артык һичбер нәрсә кирәк түгел иде. Мин әнинең бердәнбер баласы һәм юлдашы булганга, ул мине, халыкча әйткәндә, *өрмәгән җиргә утыртмый* — шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем» дигән өзеккә игътибар итик. Биредә әдип *өрмәгән җиргә утыртмый* дигән традицион фразеологик берәмлек куллана. Язучы традицион фразеологик әйтелмәләрне ана белән бала мәхәббәте илаһилыгын чагылдыру, хис-тойгыны көчәйтү максатыннан кулланган. Тагын бер үзенчәлекле мисал алыйк: «Озак һәм тәмле чәй эчтек. Әни искиткеч *ваклык белән* минем мәктәптәге тормышны сораша башлады. Минем укуым, иптәшләрем, имтиханнарым, хәлфәнең минем турында әйткән сүзләре *инәсеннән җебенәчә* сөйләшелде, *кат-кат кичелде». Ваклык белән сорашу* — ананың бала йөрәгенә үтеп керергә теләвен аңлата, ә инде *инәсеннән җебенәчә сөйләшү* дигән традицион фразеологик әйтелмә бу теләкнең куәтен көчәйтә. Шул ук вакытта баланың анага булган мәхәббәте дә ачыклана бара.

«Карт ялчы» хикәясендә капитализм җәмгыяте шартларында «бәндәгә бәндә» булып яшәүче крестьян тормышының газаплы тормышы *тәңкәне ко-рыту, җанга тию* традицион фразеологик әйтелмәләре аша гәүдәләнә. «Ялгызак крестьяннарның урган игеннәрен җыйнап алырга да мөмкинлекләре булмаган, юл пычрак, тайгак, күперләр бозык, юл саен диярлек камыт бавы, тәҗе өзелеп, арба авып *тәңкәне корыта,* тау як көлтәсе бигрәк тә җанга тия».

Автор кулланган традицион фразеологик әйтелмәләр әсәрнең идея-эчтәлегенә, ул чагылдырган чорга, язучының эстетик идеалына, аң-белем дәрәҗәсенә, романтик рухка бәйле.

2. Матур әдәбиятта фразеологик әйтелмәләрне үзгәртеп куллану еш очрый. Билгеле, ул телнен эчке законнарына каршы килмәскә, стилистик чатаклыклар барлыкка килмәскә тиеш. Чөнки үзгәртү, сүз уйнату тышкы эффектлылык өчен генә түгел. ә сюжет-композиция, идея-эчтәлек, геройларның эчке дөньясын ачып бирүгә ярашлы рәвештә кулланыла. Әлбәттә, фразеологик әйтелмәләрне тел, стиль ягыннан чыгып үзгәртү язучыдан зур осталык, саклык сорый. Г.Ибраһимов «катып калган» формаларны үзгәртә белгән.

Бер мисал карыйк: «Авыр тынлыкта, аның хәлсез, зәгыйфь тавышы *бәгырьләрне телеп салды».* «Бәгырь» сүзе төрле фразеологик әйтелмәләр ясау өчен электән үк кулланылып килә. Аның нигезендә *бәгырь ите, бәгырь җимеше, бәгырь кисәге* кебек фразеологик әйтелмәләр барлыкка килгән. Бу мисалда *бәгырь* сүзенең мәгънәсе киңәю җирлегендә *бәгырьне телеп салу* фразеологик берәмлеге ясала. Бу *бәгырьне өзү* дигән фразеологик әйтелмәдән үзгәртеп ясала. *Өзү* генә дисә, кешеләргә ул кадәр үк тәэсир итмәс иде. *Телеп салды* дигәч, сүзләрнең сәнгатьлелек куәте тагы да көчәеп китә. Димәк, фразеологик әйтелмәләр составындагы компонентларны үзгәртү телгә, стильгә, идея-эчтәлеккә бәйле.

Г.Ибраһимов фразеологизмнарны индивидуаль якын килеп үзгәртү процессында аларның мәгънәсе һәм төзелешенең төп билгеләрен саклап, я бер сүзне синонимы белән алыштыра, я сүзләр санын үзгәртә.

Халыкның явыз көчләргә каршы бергәләшеп көрәшү кирәклегенә ишарә иткән «Карак мулла» хикәясеннән бер мисал: «Бу канлы вакыйганы мулладан дип нык ышанучылар булганга, күптән бирле *эчләрендә кайнап килгән* «теге фараз» ихтыярсыз тышка атылып чыкты, һәм бер картның башлап телгә атуы берлән, бөтен тирә-як беравыздан кушылып, тиз арада «карак мулланың бу яктан читкә сөрелүен теләп», тау чаклы имзалар җыелды». Авыл халкының кичерешләренә зур  киеренкелек һәм сәнгатьлелек бирү өчен, эчкә *җыелып килү* берәмлеген үзгәртә: *җыелып килү* сүзен ситилистик яктан көчлерәк булган *кайнап килү* сүзе белән алыштыра.

Язучының конкрет сөйләм ситуациясендә урынлы саналган, стилистик яктан үзен аклаган сүзләрне сайлап алып, фразеологик берәмлекнең лексик-грамматик төзелешен үзгәртүе укучыга чынбарлыкны реаль күзалларга мөмкинлеге бирә.

3. Язучылар халык тарафыннан иҗат ителгән традицион фразеологик әйтелмәләр, тел-сурәтләү чаралары белән генә чикләнми, әсәрнең идея-эчтәлегеннән чыгып, телнең эчке үсеш кануннарына каршы килмәслек итеп, яңадан-яңаларын уйлап табалар.

Мәсәлән «Көтүчеләр» хикәясеннән бер өзек: «Ләкин актык көчең белән уяныргa тырышасың, *суланган йоннан тигәнәкне тартып алгандай* бер газап белән, *куәтле йокыдан үзеңне суырып аласың* да ава-түнә ишек төбенә барасың...» Көтүченең авыр хәлен чагылдырырдай фразеологик әйтелмәләр юк түгел. Ләкин алар язучыны канәгатьләндерми, күрәсең. Ул үзенекен иҗат итә: *йокыдан үзеңне суырып алу* — һичшиксез, халыкны кына караганда көчлерәк тә,тәэсирлерәк тә. Ә менә *суланган ионнан тигәнәк тартып алу* дигәннең стиль куәте, сәнгатьлелек функциясе тагын да куәтлерәк.

Күзәтүләр шуны күрсәтә: Г.Ибраһимов үзе иҗат иткән фразеологик әйтелмәләр бик күп.Мәсәлән, *түбәсенә менеп бугазлау, миенә кан белән язу, пычкы белән рәнҗетелмәү, чулпының зиннәт бирүе, мигә утлы кадак булып кадалу, мәхәббәт дулкыннарыннан исергән башны кая куярга белмәү, баш белән капчыкка тыгылып йөрү, гомеренең иң ачы зәһәре булып мигә керү, вакыт йолку, халык дулкыны демонстрацияләр ташкыны астында калу, атаң тапкан малны кызыл авызларга ашату, күзеннән астыртын зәһәр әсәре таралу, хәрам дуңгызлары булу, катлаулы сүзнең өске ягында йөзү, ил алдында сую, дуңгыздан бер кыл йолку, канат кисек булу, аһ-зарын агыза гына бирү, ике куәт арасында кысылу, йокыдан үзеңне суырып алу, суланган йоннан тигәнәк тартып алу, башына асылынып йөрү, арка тиреләрен яру* һ.б. — болар барысы да әдипнең үз иҗат казанышы.

Фразеологик материалны анализлау шуны күрсәтте: Г.Ибраһимовның хикәяләрендә традицион, трансформацияләнгән һәм индивидуаль фра-зеологик әйтелмәләр бергә үрелеп бара. Ул чын язучы буларак, фрразеологик әйтелмәләрне, сайлап алып, аларны үзгәртеп яки үзгәртмичә, яки яңаларын иҗат итеп, максатка ярашлы рәвештә, мәгънәгә һәм эчтәлеккә туры китереп куллана.

## Йомгаклау

Галимҗан Ибраһимовның хикәяләрен уку, аларның өстендә эшләү дәверендә мин барысын да үз йөрәгем, үз уйларым аша кичердем. Әсәрләрнең тел байлыгына сокландым мин. Фразеологизмнарны эзләү, аларның

мәгънәләрен ачыклау – минем өчен кызыксындырырлык хезмәт булды. Фразеологизмнар турында мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем:

1.Татар теленең фразеологик фонды бай һәм күпкырлы. Ул сөйләмне баетуда, аны үтемлерәк, көчлерәк һәм үткенрәк итүдә, әдәби әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда зур роль уйный.

2.Фразеологик әйтелмәләр язучы телендә алтын фонд булып санала.Фразеологик әйтелмәләр язучыга геройның портретын тасвирлау, эчке дөньясын ачу, вакыйга – күренешләрне чагылдыруга ярдәм итә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә.

3.Телнең фразеологик байлыгын, аның төзелешен, мәгънәсен яхшы белү тәрҗемә эшендә дә бик кирәк. Галимҗан Ибраһимовның хикәяләрендә фразеологизмнар кертүе – аның образларын ачарга, аларның характерларын күрергә ярдәм итә. Әсәрнең теленең гадилеге, халыкчанлыгы, кызыклы булуы һәрбер укучыга мәгълүмдер.

Минем максатым –әсәрдәге фразеологизмнарны табу иде. Мин үзем таба алган фразеологизмнарның мәгънәләрен ачыкладым. Галимҗан Ибраһимов иҗатының шундый гади, халыкчан телдә булуы, аны үлемсез итә. Аның әсәрләре буыннан – буынга күчеп укылыр һәм укучылар күңеленә якты эз салудан туктамас.

## Кулланылган әдәбият

1. Ибраһимов Г.Г. Хикәяләр, повесть, роман. Төз. Р.Акъегет / Г.Г. Ибраһимов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 463 б.

2. «Мәгърифәт»газетасы,Ф.Исламов, 8 март, 2007 ел.

3. «Мәгърифәт»газетасы, Н.Акмал,13 март, 2007 ел.

4. «Мәгариф»журналы, В.Хаков «Г.Ибраһимов», 1997, №3, 15-16 битләр.

5. «Азат хатын» журналы, Г.Әдһамова, 1987 , 11-12 битләр.

# Тарих, әдәбият олпары.

*Хасаншин Ирек Фаям улы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*ДАҺБУ “Түбән Кама күп профильле көллият”*

Бу дөньяда күп эшләр башкарган иҗат әһелләрен санап китсәң, алар бик күп. Шуларның берсе һичшиксез - Мөсәгыйт Хәбибуллин булыр. Ул күренекле язучы, тарихчы, журналист, педагог, техник-инженер, шофер һәм башка һөнәр иясе...

Безнең халыкта: “Ир-атка 70 төрле һөнәр аз”, - дигән сүзләр йөри. Бу сүзләр аңа хас. Кем соң, ул, Хәбибуллин? Гади генә мөлаем йөзле кешедә тирән акыл, гыйлемлелек, сабырлык, тыйнаклык, иҗади эзләнүләр чагыла.Үз иҗатында кызыклы эволюция кичергән һәм хәзер татар прозасының әйдәп баручы затларыннан берсенә әверелгән Мөсәгыйт Мәдәррис улы Хәбибуллин 1927 нче елның 25 нче декабрендә Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында туа. Туган ягында башлангыч белем алганнан соң, Татарстанның Баулы районына күчеп килеп, җидееллык мәктәптә укый. Бөек Ватан сугышы башлангач, колхозда эшли. 1944 нче елда Чиләбе өлкәсенә китә, анда һөнәр мәктәбен тәмамлап, 1946-1953 нче елларда Магнитогорск, аннары Башкортстандагы Октябрьский шәһәрендә эшен дәвам итә. 1953 нче елда туган авылына әйләнеп кайтып, анда инженер-механик вазифасын башкара. 1958 нче елда Баулы эшчеләр поселогына күчеп килеп, “Баулы-нефть” транспорт конторосында машина йөртүче, автомеханик, ә 1961-1962 нче елларда районда чыккан “Байрак” газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. Мөсәгыйт Хәбибуллин Азнакайдагы “Маяк” газетасы редакциясенең бүлек мөдире дәрәҗәсенә җитә. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, аннан соң Таҗикстанда урта мәктәптә тарих фәнен укыта.

1971 елда ул Казанга күчеп килә һәм байтак еллар Татарстан Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе вазифасын башкара.

Бик яшьли үз көнен үзе күрә башлаган Мөсәгыйт Хәбибуллин әдәби иҗатка шактый бай тормыш тәҗрибәсе туплап керешә. Шушы ук тәҗрибә байтак дәрәҗәдә аның иҗади эзләнүләренең юнәлешен һәм эволюциясен дә билгели. Баштарак ул яшьлек дәрте белән замандашлары, бигрәк тә яшьләр тормышын чагылдырган хикәяләрен яза, ә 1969 нчы елда аның беренче күләмле әсәре – “Унсигезенче яз” повесте дөнья күрә. Яңа гына унсигезенче язын каршылап урта мәктәпне тәмамлаган яшь кыз Әнрүсәнең артистка булу хыялын тормышка ашырудагы беренче адымнарын, реаль чынбарлык тудырган каршылыклы уй-кичерешләрен лирик пафос белән чагылдыруы аркасында, әлеге әсәр укучылар һәм тәнкыйтьче тарафыннан җылы кабул ителә һәм авторны тагын да активрак иҗатка рухландыра. Тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе арта бару шәхесебез әсәрләрендә заман тормышының җитдирәк һәм катлаулырак мәсьәләрен яктыртуга этәрә. Шул нигездә аның “Икмәк кадере”, “Тау белән тау очрашмаса да”, “Хәтер ярлары” повестьлары һәм “Чоңгыллар” романы дөнья күрә.

Әммә иҗади эзләнүләрен дәвам итеп, әдип алга таба тарихи темага мөрәҗәгать итә, үзенең әдәбияттагы чын урынын да шушы өлкәдә таба. Мөсәгыйт Хәбибуллинның бу темага килүе, бер яктан, аның татар тарихы белән күптәннән кызыксынуы, икенче яктан, илдәге мәгълүм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр аркасында әлеге тарихны өйрәнү мөмкинлеге туу белән бәйләнгән иде. Тарихи романчы итеп танылткан һәм киң яңгыраш алган беренче әсәре - “Кубрат хан” романы. Моңа кадәр безгә бик аз билгеле дәүләт - безнең эраның VII гасыр урталарында Таман ярымутравында яшәгән Бөек Болгар ханлыгы турында әдәбиятта беренче булып сүз әйтергә алынып, әдип халкыбыз тарихының легендар дәверләрен сәнгатьче гәүдәләндерүгә лаеклы өлеш кертте. Биредә әдәби осталык белән бергә, авторның тормыш материалын шактый җыйганы һәм өйрәнгәне дә мөһим роль уйный. Дөрестән дә, роман Мөсәгыйт Хәбибуллинның байтак еллардан бирле татар тарихы белән актив

кызыксынуы, бу очракта әлеге дәүләткә караган материалларны бөртекләп җыюы һәм үзләштерүе нәтиҗәсе булып тора. Әлбәттә, биредә автор фантазиясенең дә роле бар.

Мөсәгыйт Хәбибуллин алга таба да милли тарихыбызның күләгәдә калган дәверләренә мөрәҗәгать итә һәм “Илчегә үлем юк”, ”Шайтан каласы”, ”Сөембикә ханбикәсе һәм Иван Грозный”, “Хан оныгы Хансөяр”, ”Аллаһы бүләге”, “Батый хан һәм Ләйлә”, ”Атилла” кебек әсәрләрен яза. Соңгы романнар арасында “Атилла” милли яктан аеруча әһәмияткә ия. Чөнки анда автор бөтен кешелек тарихындагы иң данлыклы шәхесләренең берсе булган Атилланың безнең ерак бабабыз икәнлеген, аның ничек җир йөзендәге иң куәтле дәүләтләрнең берсен төзүен сүрәтли.

Мөсәгыйт Хәбибуллин безнең әдәбиятебездә аерым урын алып тора. Ул милләтебезнең тарихын тирәннән өйрәнгән, олы шәхесләребезнең берсе. Гомумән алганда, халкыбыз тарихының моңа кадәр аз билгеле борынгы сәхифәләрен сүрәтләп, авторның тарихи романнары киң милли һәм сәяси яңгыраш алдылар. Мондый әсәрләр балаларда аерым кызыксыну хисе уята. Алар дәрестә актив теләп җавап бирәләр.

Тарихны белмәгәннең үткәнне, киләчәге юк. Аның әсәрләрен өйрәнгәндә дәрес-диспут үткәрергә була, сәхнәләштереп тә күрсәтергә була.

Мин горурланам шундый шәхесләребез белән!

Кулланган әдәбият

1.Мусин Ф.М., Татар әдәбияты, 11 нче сыйныф өчен дәреслек, “Мәгариф” нәшрияты, 2006 ел;

2. Юзиев Н. Олы ачышмы, әллә...// Ватаным Татарстан, 1993 ел, №5.

# Якташыбыз авазы

*Хәйретдинова Зөлфия Рафик кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*ДАҺБУ “Түбән Кама күп профильле көллият”*

Һәр төбәкнең үз йолдызы бар, иҗади эшемне дә шундый йолдызларның берсенә багышлыйм. Ул - татар язучысы, Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Русиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Русия Гуманитар Фәннәр Академиясенең шәрәфле академигы Разил Исмәгыйль улы Вәлиев. Бүгенге көндә Түбән Кама шәһәренең генә түгел, ә Татарстанның күренекле шәхесе. Менә нинди ул безнең якташыбыз!

Минем максатым Татарстанның Түбән Кама (элекке Ширәмәт) районы Ташлык авылы, сигез балалы ишле гаиләдә олы малай булган, бәләкәй чагыннан ук йорт тирәсендәге эшкә катнашып, ир-ат һөнәренә өйрәнеп үскән шәхеснең язмышы һәм иҗаты белән таныштыру. Хезмәт сөюче егетебез башка авыл егетләре кебек үк, дәү әтисе белән берлектә, тегермән тартыра, яргыч ярырга өйрәнә, җәйге каникул вакытларында ул шофер ярдәмчесе сыйфатында эшли, комбайнчы ярдәмчесе булып иген ура, кулына чалгы тотып, болында ирләр белән беррәттән печән чаба. Гади авыл егете. Юкка гына татар халкында: “Егет кешегә җитмеш төрле һөнәрдә аз”,- димиләр.

Хезмәт белән берлектә белемен күтәрү өстендә дә эш алып бара. Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, Разил Вәлиев күршедәге Шәңгәлче сигезьеллык мәктәбендә укуын дәвам иттерә. Түбән Кама шәһәренең әле яңа гына ачылган беренче урта мәктәбенә укырга керә. 1965 елда мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт университетының журналистика факультетының ике курсын тәмамлагач, Мәскәүнең М. Горький исемендәге Әдәбият институтында белем ала.

Якташыбызның иҗат юлына килгәндә, аның беренче шигырьләре мәктәп елларында ук район газетасында, аннан соң республика күләмендә чыга торган газета-журналларда басыла. Шулай итеп шигыри тәлгәшләр мөстәкыйль җыентыкларны хасил итә. Шундыйлардан: «Хыялый Мияубикә», «Без – кояш балалары», «Ядкарь», «Бер алманы бишкә бүләек», «Шигырь китапханәсе» һ.б. Туган җир, аның күрке булган табигать, халык, милләт язмышы турында борчылулы фикер-тойгылар шигъри иҗатының төп идея эчтәлеген тәшкил итә. Мәхәббәт һәм яшьлек темасы да шагыйрьнең иҗатында төп урыннарның берсен били. Аның традицион халык җырлары рухында язылган бик күп шигырьләре музыкага салынган һәм халык көйләренә җырланып йөри.

Язучы буларак, Разил Вәлиев проза һәм драматургия жанрларында да актив иҗат итә. «Эт кояшы», «Яшисе килә», «Иске сәгать дөрес йөри» дигән повестьлары, «Мирас» романы, театр сәхнәләрендә уңыш белән барган «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!», «И машина, машина, җитте минем башыма», «Куркыныч уен», «Мәңгелек иман» кебек комедия һәм драмалары тормышта үз юлыңны табарга өйрәтә, заман яшьләре арасындагы мораль-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Чәчмә әсәрләрендәге кеше образлары психологик планда тасвирлануы белән үзенчәлекле, әдипнең геройлары, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «үз күңелләрендә, үз эчләрендә казыналар, тормыш мәгънәсен аңларга тырышалар, җәмгыятьтә, дөньяда үз урыннарын табарга омтылалар, шуның өчен көрәшәләр». Аның әдәби тәрҗемә һәм публицистика өлкәсендәге иҗади эшчәнлеге дә игътибарга лаеклы. Ләкин кайсы гына жанрда эшләсә дә, ул иң элек шагыйрь булып кала.

Татарстанның һәм Рәсәйнең халык җырчысы Илһам Шакировта Разил Вәлиев иҗатына игътибар итмичә калмый. Ул аның турында болай ди: “ Разил — моңлы, җырлы, уйлы егет. Көне-төне шигырь-җыр, повесть-пьеса гына язып утырса да, ул халкыбыз өчен бик зур эш эшләр иде. Ләкин, кыю шәхесләр һәрчак фидакарь көрәшче дә була. Разилне мин халык язмышы өчен янып яшәүче иң фидакарь язучыларыбызның, көрәшче егетләребезнең берсе дип саныйм». Әйе, безнең якташыбыз күренекле шагыйрь, язучы гына түгел, ә

танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе. 1990 елдан бирле ул – Татарстанның халык депутаты, Бөтендөнья язучылар ассоциациясенең Татар ПЕН-үзәге вице-президенты.

Әтисеннән абруйлы шәхеслелек күчсә, әнисеннән оста куллык һәм әдәбиятка мәхәббәт. Чөнки, әнисе ипи салганда, Разилне мич башына утыртып, романнарны кычкырып укыттыра торган булган. Ә, хәзер үзе үрнәк гаилә башлыгы, ышанычлы тормыш иптәше, эти һәм дәү эти. Гаиләсе зур: тормыш иптәше – танылган табибә Алия ханым, кызлары Сөембикә, оныклары Камилә белән Җәмилә һәм оныкчыклары Әмир. Әгәр дә Разил Вәлиевның нәсел агачы-шәҗәрәсен төзесәк тамырлары җәелгән, нык имән агачын тасвирлар иде. Хезмәтне сөйгән кеше генә гаиләсе өчен янып яшидер, кызы тугач гаилә мәшәкатьләре арта. Тулай торактан чыгып китеп, Мәскәүдән 15 чакрым ераклыктагы Перловское дигән станциядән ярым җимерек бер иске дачага гаиләсен алып килә. Эшне карага - акка аеру юк, көндезен укыса, төнлә «Москвич» машиналары ясый торган заводта, аннан макарон фабрикасында хезмәт итә. Менә шулай якташыбыз түбәннән югарыга күтәрелә.

Безнең төбәктән чыккан чыккан шәхесләр югалып калмыйлар, алга омтылалар, биек үрләрне яулыйлар!

Программа буенча якташларыбыз иҗатына аерым сәгать бирелә. Укучыларыбызны шәхесләребезнең тормыш юллары, иҗатлары белән таныштырабыз. Бу шәхесләр укучыларгада тәэсир итмичә калмый, алардан үрнәк алып төрле бәйгеләрдә катнашып уңышларга ирешәләр. Быел Разил Валивның тууына 70 еллык юбилие уңаеннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт министрлыгы һәм “Идел” яшьләр үзәге "Дулкыннар" Республика бәйгесен төрле номинацияләрдә үткәрде. Рәсем номинациясе буенча 2 нче дәрәҗәне яуладык.

Якташларыбыз белән горурланабыз!

# Миллəтемнең энҗесе

*Чистай күппрофильле көллиятенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Шәйхетдинова Розалия Харис кызы*

"Хәтер-хатирә – безне беркем дә куып чыгарга алмаслык бердәнбер җәннәт".

Ж. П. Рихтер

Бу хәтер дигәнең үтә дә четерекле, үтә дә сәер икән. Әле кичә генә кебек булган вакыйгалар сиздерми-нитми тарихка әйләнә.

Кояш Закир кызы Тимбикова 1937 елның 16 ноябрдә Чистай районы Наратлы Елга авылында дөньяга килә. Укытучылар булганга, аның әти-әнисе Закир абый белән Сания апа гаиләсе гел күченеп йөри торган булган. Ике еллап Ислəй авылында эшләп алгач, 1943 елны Закир абыйны Иске Роман җидееллык мәктәбенә директор итеп билгелиләр. Сания апа татар теле һәм әдәбиятын укыта башлый, ә ул үзе физика һәм математикадан дәресләр бирә. Алты яше дә тулмаган кечкенә Кояш Иске Роман мәктәбенең 1нче сыйныфына укырга керә. Аны тәмамлагач, биш чакрымдагы Каргалы урта мәктәбенә укырга йөри. Мәктәпне уңышлы гына тәмамлаган Кояш, Казан дәүләт университетына татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Зиһенле, тырыш, белем алуга һәвәс чибәр кызны университет мөгаллимнәре дә Сәләтле, эш сөючән кыз остазларның ышанычның аклар өчен көчен кызганмый, авырлыклар алдында каушап калмый: эзләнә, таба, яза.

БАМ төзеп яталармы, КамАЗ салалармы- тездән югары резин итекләрен киеп, самолетка билет алып, "татар батырларын" эзләп чыгып чаба. "КамАЗ төзүчесе" билгесенә ия була. Очерк-мәкалә кысаларына сыймаганы, хикәя булып ак кагазь битенә түгелә. Түгелми, җыела. Беренче хикәяләре Татарстан китап нәшрияты чыгарган "Талсымлы таяк" җыентыгында дөнья күрә.

"Зәңгәр күк", "Якты йолдыз", "Күңелле тап төшмәсен", "Кайгы белән шатлык янәшә", "Тәңкәле тау" һәм башка бик куп китаплары басылып чыга. Аның аерым

әсәрләре башкорт, әзербәйҗан, үзбәк, каракалпак, казак, рус, белорус, латыш телләрендә дә басылган. Ул җырларга шигырләр дә иҗат итә: “Кышларга да бергә керсәк иде”, “Авылдашлар”, “Синсез язалар миңа кирәк түгел”, “Җибәрмә син мине”, “Яңа чишмә” җырлары безнең күңелдә якты хатирә булып мәңге сакланыр.

Ул язган повесть һәм романнар, хикәяләр һәм очерклар дәртле, рухландыргыч, тормышчан булулары белән халыкка якын.

Соңгы елларда аның йөрәген күпме борчулар телгәләгәнен, мөгаен,Кояш апа үзе генә белгәндер.Берүзе,өлкән яшькә җитеп,урын өстендә яткан әнисен,сәер холыклы,авыру ире Рейнны соңгы юлга озатуы,янә килеп үз өстенә хәрәкәтсез яткан авыру абыйсын карауны алуы,бер үк вакытта алны –ялны белми иҗат эше белән шөгыльләнүенә ничек чыдасын ул йөрәк? Ничек заман чиренә бирелеп сыгылып төшмәскә? Чыдый алмаган шул,өзелгән.Соңгы сәгатьләре сукканда нәрсәләр эшләгән,нинди уйлар белән янган ул?

Иске Роман авылы халкы үз якташлары Кояш Тимбикова белән горурланып яши. 2004 нче елның 7 гыйнваренда якты дөньядан китсә дә,аның якты истәлекләре безнең күңелләрдә мәңге сакланыр. Мәктәп бинасында кечкенә генә музей оештыру күренекле язучы иҗатына карата көчле мәхәббәтне раслау булып тора.Музей ачу тантанасы авторның 70 еллыгына туры китерелде. 2005 нче елның февраль аенда Кояш Тимбикова вафатына бер ел тулуга багышланган кичәдә язучының бертуган апасы Чәчәк Хәйруллинаның кызы Наилә ханым беренче экспонат итеп аның шәлъяулыгын бүләк итте.Шул ук музейда аның шәхси әйберләре,кыйммәтле кулъязмалары саклана.Экспонатларның күбесе бүләк ителгән.Аны киң күңелле ,мәрхәмәтле кеше буларак хәтерлиләр.Үзенең 60 яшьлек юбилеен ул Чистай шәһәренең Үзәк китапханәсендә билгеләп уза. Шул очрашуда Саймә Гатина Кояш ханымга аеруча игътибар итә:”Ул миллилекне саклауны өстен күргән,күрәмсең, башында бик матур чигелгән энҗе калфак,аркасына нәфис ,юка ак челтәр шәл япкан.Чын мәгънәсендә татар зыялысы!”.Бер тамчы су кебек үз язмаларында заманны чагылдыра ала торган менә дигән публицист,армый –талмый иҗат итүче язучы,шагыйрә,Татарстан

журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты була.

Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Кояш Тимбикованың сулышын без әсәрләре,геройлары аша даими диярлек сизеп,тоеп торабыз.2007 нче елның гыйнвар аенда Чистай шәһәрендә тәүге тапкыр аның исемендәге премия лауреатларын бүләкләү тантанасы булды.Һәр елны Кояш Тимбикова исемендәге премиягә Чистай шәһәрендә яшәп һәм иҗат итүче "Энҗеләр" һәм "Ступени" әдәби түгәрәге әгъзалары –татар һәм рус телендә язучылары ия була.Премиянең беренче лауреаты –язучы һәм җирле юморист шагыйрь һәм җырчы Николай Нарсеев.Чистай шәһәренең бер урамына Кояш Тимбикова исеме бирелсә бик яхшы булыр иде..Шундый мәшһүр якташыбызны онытырга безнең һич тә хакыбыз юк.Йомгаклау сүземне Кояш апа Тимбиковага багышлап язган шигъри юлларым белән тәмамлыйсым килә.

Татар халкы диеп,җан аттың син,
Язмыш сынаганда сынмадың.
Иңнәренә ак шәлеңне яптың,
Башларыңда нәфис калфагың.
Иҗат диңгезендә йөздең һәрчак,
Шигырь-хикәяләр тудырдың.
Күңелләрдә сүнмәс якты өмет,
Җылы хәтирәләр калдырдың.

Файдаланган әдәбият:

1."Ватаным Татарстан" 2007 ел.
2."Казан утлары" 1987 ел.
3".Сөембикә" 2007 ел.
4."Чистай хәбәрләре" 2007 ел.

# Г.Ахунов исемен мәңгеләштерү.

*Газизова Лилия Нәҗип кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*«Бөгелмә аграр көллияте» дәүләт автоном*
*һөнәри белем бирү учреждениесе.*

Татар әдәбиятында милләтебезнең бай тарихын чагылдырган язучылар бик күп. Мине талантлы әдип, әдәбият һәм сәнгать әһелләренең барысын да үз иткән, алар турында эчкерсез кайгыртып яшәгән, әдәбият дөньясында күпләргә ихлас күңелдән зур ярдәм күрсәткән, яшь язучыларның шактыен кулларыннан җитәкләп әдәби-иҗат мәйданына алып килгән, киң күңелле, олы йөрәкле, көләч йөзле, шаян сүзле, җор күңелле һәм бер үк вакытта гадилек һәм бөеклеккә ия шәхес Гариф Ахунов иҗаты үзенә җәлеп итте.

Гариф Ахунов исемен мәңгеләштерү максатыннан, Арча муниципаль районы администрациясе Гариф Ахунов исемендәге әдәбият премиясе булдырды. “Шагыйрь җаны... Ап-ак җирлектәге чиста, моңлы, җырлы җан. Аның йөрәк тибеше дә, сулыш алулары да кендек каны тамган туган җирендә, туган халкы белән бергә“ дип язган бер каләм иясе. Арчаның үзәк мәйданында, язучылар аллеясендә аңа брозадан  бюст куелган. Башкалабыз һәм шәһәренең бер урамы һәм паркы аның исемен йөртә. Язучы 10 ел торган Әлмәт шәһәренең Радищев урамы 20 нче йортына хәтер тактасы урнаштырылган. Шундый ук мемориаль такта Казанда да урнаштырылган. Казанбаш урта мәктәбендә Гариф аганың исемен мәңгеләштерү уңаеннан аның исемендәге музей эшләп килә.Арча районы халкы Гариф Ахунов белән горурлана. Бу төбәк Гариф Ахуновны: “Бөек якташыбыз!” – дип саный һәм аның мирасына тугрылыгын кадерләп саклый. Моның шулай булуына без тагын бер кат инандык. Гариф Ахунов туган Кечкенә Өчиле авылы урнашкан урында “Ахун чишмәсе” ачылды. Күренекле әдибебез Фоат Галимуллин истәлекләрендә язылганча, Гариф абыйның чишмәләргә мөнәсәбәте күпкә тирәнрәк һәм мәгънәлерәк булган.

Чишмәгә ул тереклекне тәэмин итүче, яшәешнең мәңгелек хәрәкәтен күрсәтүче табигать могҗизасы итеп караган. Каләмдәшләрен авыл нигезендәге әлеге чишмә янына алып бара торган булган. Гариф абый чишмә алдына тезләнеп, чал башын иеп, тәме бала чагыннан ук яхшы таныш суын эчте. Иң мөкатдәс вазыйфаны башкарган кебек итеп, саф суны учлары белән алып, битен юды. – “Яшибез әле, туганнар, болай булгач”, – диде.

Гариф Ахунов татар әдәбиятында лаеклы үз урынын күптән раслады. Аның әсәрләре бүтән тарафларга, урыс теле ярдәмендә бүтән илләргә, бүтән телләргә барып җитте. Хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуаш, якут һ.б. телләрдә басыла, «Хәзинә» романы казакъча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителә.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен Гариф Ахунов 1975 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1981 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә, 1972 елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ә 1993 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы дигән мактаулы исем йөртә.

Аның әдәби мирасында Казанда Татар академия театры, К.Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театры, Әлмәт татар драма театры, Минзәлә драма театрлары сәхнәләрендә тамашачының игътибарын җәлеп иткән пьесалары да бар: «Чулпы җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Акчарлаклар» һ.б.

Татар кино сәнгатен үстерүдә аның да өлеше бар. Свердловск киностудиясендә аның “Хәзинә” романы буенча нәфис фильм төшерелде. Шулай ук Казан телевидение студиясе аның “Идел кызы” әсәре буенча фильм-спектакль әзерләде.

Гариф Ахунов – безгә үлемсез мирас калдырган шәхес. Заманында ул: “Мирас калдыра алган кеше бәхетле. Мирас ул – адәм баласының киләчәк

буынга васыяте”, – дигән . Әмма мирасны саклау эшен балаларың, оныкларың дәвам итмәсә, барыбер дә ниндидер бушлык булыр иде. Бу җәһәттән Гариф аганың кызы Наилә ханымның эшләрен санап бетергесез. Киңәшле эш таркалмас, диләр бит. Үткәрелгән чаралар: семинар, конференцияләр, укытучылар, укучылар белән очрашу, истәлекле көннәрдә кабергә зиярат кылу кебек якты гамәлләр, китаплар бастыру һ.б эшләре башкарыла.Шул рәвешле хатирәләр яңартылып торганга, «шагыйрьнең учагы дөрли дә дөрли».

Гариф Ахунов арабыздан китсә дә, аның мәңге үлмәс әсәрләре, үрнәк булырлык холкы, кешелеклелеге күңелебезне гел җылытып тора.

**Әдәбият.**

1. Гайфуллина Ф. Гариф Ахунов прозасы. Казан, 2003. 127 б.

2. Ахунова белән әңгәмә // Идел. — 2006. — № 9. — 64-67 б.

## « Әдәби туган як- Чаллы шагыйрьләре, язучылары ижатында”

Муллашова Эльмира Рәис кызы,
Яр Чаллы шәһәре 112 нче
«Бизәкләр» балалар бакчасы
татар теленә өйрәтүче тәрбияче

Диңгез иңләп акчарлаклар
Шаярыр дулкын куып;
Яңа утлар балкый илдә
Чаллы сәламе булып.

Р.Хисамиев

Яр Чаллы шәһәре күренекле кешеләргә бик бай. Яшь булуына карамастан, шәһәребездә язучылар бик күп. Туган якның матур табигате шагыйрьләребезне яңадан –яңа шигырьләр, әсәрләр ижат итәргә дәртләндереп тора. Дәверләр үтә, ә шулай да туган якка булган мәхәббәт шигырьләре, әсәрләре буыннарны тоташтыра, бәйли. Үзебезнең төбәктә яшәп ижат итүче әдипләр белән танышу туган якның әдәби байлыгы белән якынайта.

1969 елда КАМАЗ төзелеше башлангач, Чаллыга бунтарь Фаяз Дунай, балалар шагыйре Мәхмүт Газизов килеп җитә. Фәннур Сафин, Рәшит Бәшәр, Факил Сафин, Нияз Вәли, Равил Вәлиев, Шәүкәт Гаделша, Нәсимә Садыйкова, Әлфия Ситдыйкова кебек кешеләр әле редакциягә, әле тулай торакларның “кызыл почмаклары”на, ә соңрак “Энергетик” мәдәният сараена “Ләйсән” берләшмәсе утырышларына йөри башлыйлар.

1980 елда шушы берләшмә нигезендә Чаллы Язучылар оешмасы хасил була. Шәһәребездә уңышлы гына ижат итүче ләйсәнлеләрнең исемнәре арта бара: Нурислам Гафиятов, Фәнис Нуретдинов, Рушания Гыйләҗева, Фәридә Шакирова, Рәкит Әбделманов, Рәзинә Сәетгәрәева, Нурия Гыйлметдинова, Зифа Кадыйрова һәм башкалар.

Балаларны иҗатка, китап укуга җәлеп итү максатыннан, мин иҗади-эзләнүчән проект төзергә булдым. Проект 1 елга исәпләнгән.

Проект «Туган як язучылары, шагыйрьләре иҗаты” дип атала.

Актуальлеге:

Уземнең эзләнүләр нәтиҗәсендә шундый фикергә килдем: әдәбиятка, халкыңның мәдәниятына тяну безнең татар милләтен саклап калырга ярдәм итә. Балалар үзләренең киләчәген, бүгенгесен белергә тиешләр. Шундый гыйбарә бар: “Кеше бәхетле булсын өчен, аның тамырлары һәм канатлары булырга тиеш.”. Ә нәрсә дигән сүз соң ул? Минем улавымча, узеңнең халкыңның үткәне туган ягыңа мәхәббәт бу- тамырлар. Ә канатлар- китаплар, чөнки китап уку кешене канатландырып җибәрә.

Максат: Балаларны Чаллы төбәге әдипләре һәм аларның әсәрләре белән таныштыру аша балаларда милли җанлы, туган җиренә хөрмәт белән караучы шәхес тәрбияләү.

Бурычлар:

Буыннар бәйләнешен ныгыту;

Иҗади –эзләнүчән шәхес тәрбияләү;

Китаплар укуга кызыксыну уяту;

Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү;

Әдипләр иҗаты аша туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.

## Проект этаплары.

| № | Этапның исеме | Үткәреләчәк чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Әзерлек этабы | 1. Эшчәнлекне планлаштыру.<br>2.Куйган максатка ирешү юлларын эзләү.<br>3. Мәгълүмат туплау.<br>4. Тәрбиячеләр, ата-аналар белән киңәшмә үткәрү. |
| 2 | Проектның үтәлу этабы | • Туган як язучылары, шагыйрьләре иҗаты белән танышу. Шигырьләрен ятлап, конкурсларда катнашу.<br>• Күренекле әдипләр белән очрашу<br>• Татар балалар китапханәсенә сәяхәт; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - Айгөл Әхмәтгалиеваның “Мактанчык аю” әкиятен сәхнәләштереп күрсәтү.<br>• Гаилә белән өйдә Чаллы язучылары, шагыйрьләренең китапларын уку, презентация, яклау.<br>• “Чаллы шәһәрендә иҗат итүче балалар язучылары һәм шагыйрьләре” альбомы булдыру.<br>• Әти- әни белән бергә “Минем яраткан шагыйрем” дип аталган лэпбук ясау. |
| 3 | Йомгаклау | Ата- аналар, тәрбиячеләр белән берлектә<br>“ Ата- аналар клубы”н оештыру. |

Яр Чаллы шәһәренең 112 нчы “Бизәкләр” балалар бакчасы 2017 елда ата-аналар клубын ача. Бу очрашуларда тәрбиячеләр, ата-аналар һәм балалар тыгыз элемтәдә үзебезнең туган илебезнең, туган җиребезнең, туган авылыбызның тарихын белеп, онытмау, яшь буынга тапшыру өстендә эш алып барыла.

Туган телне саклау һәм үстерү – көнүзәк мәсьәлә, чөнки телнең яшәеше, үсеше халыкның аны көндәлек тормышта ни дәрәҗәдә куллануына бәйле.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Милли үзаңны үстерүгә, халкыбызның рухи чишмәсен баетуга, тарихи ядкарьләребезне барлап, аларны түкми-чәчми киләчәк буынга тапшыруга юнәлтелгән бу иҗади-эзләнүчән проектның әһәмияте, чыннан да, зур.

Чаллы язучылары белән таныштырып, алар иҗат иткән әсәрләрне сәхнәләштереп, шигырьләр укып, ата-аналарга балалар белән һәръяклап эшләвебезне күрсәтәбез. Өйдә дә ата-аналар безнең мисалда балалары белән китап укып, татар телендә сөйләшеп, гореф-гадәтләрне онытмау өстендә эшләсәләр, безнең алып барган эшебезнең дәвамы булыр дигән өмет белән калабыз.

Әдәбият.

Әхммәтгалиева Айгөл Габдулловна “Болытта җилләк үсә”, нәни хикәяләр, әкиятләр; Казанн “МӘГАРИФ” НӘШРИЯТЫ 2008.

Хәмидуллина Роза Галимулловна, Ситдикова Әлфия Мирзануровна “Ләйсән” – моңлы бишегебез; Яр Чаллы 2009.
Хәмидуллина Роза Галимулловна, Ситдикова Әлфия Мирзануровна “Әдәби Чаллы”, әдәби –нәфис басма; Казан 2014.

## Кәрим Тинчурин прозасында модернизм күренешләре

*Минһаҗева Резилә Әбүзәр кызы,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*ДАҺБУ «Яр Чаллы педагогия көллияте»*

Быел сентябрь аенда татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган, үзенең мәктәбен оештырган талантлы драматург, язучы, сәнгать белгече, артист, режиссер, шәхес культы корбаны Кәрим Тинчуринның (1987-1938) тууына 130 ел тулды.

Үзенең утыз елга якын иҗат дәверендә ул каләмен проза жанрында да унышлы сынаган. Әмма, аның проза үрнәкләре – хикәяләре, новеллалары совет чоры әдәбияты галимнәре игътибарыннан читтә кала килде. Хәзерге чорда аның башлангыч чорында язылган хикәяләре күпмедер дәрәҗәдә Фәрит Бәшир тарафыннан өйрәнелсә [1], вакытсыз өзелгән иҗатының соңгы җәүһәре «Мәрҗәннәр» (1935-1937) новеллалар циклы буенча филология фәннәре кандидаты, бүген «Идел» журналының баш мөхәррире Радик Сабиров фәнни мәкалә язып чыга [3].

«Әдәби туган як» дип аталган республика фәнни-гамәли конференциясенә 2017 нчы елның юбиляр шәхесе Кәрим Тинчуринның аз өйрәнелгән прозасына мөрәҗәгать итеп, үзебезнең фәнни эзләнүләребез белән таныштыруны максат итеп куйдык.

Белүебезчә, Кәрим Тинчурин әдәби иҗатка XX йөз башының унынчы елларында, татар әдәбияты зур сыйфат үзгәрешләре белән үзенең Алтын чорын кичергән вакытта аяк баса. Моңарчы шәрык әдәбияты белән туендырылып киленгән татар әдәбияты тизләтелгән адымнар белән Ауропа, рус мәдәнияте

һәм әдәбиятларына да йөз белән борыла. Бу дәвердә Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәби традицияләренең бербөтен кушылуы нәтиҗәсендә яңа иҗат ысуллары, әдәби жанрлар мәйданга чыга. Реализмның мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди агымнарын үзләштерү белән бергә Аурора тибындагы романтизм пәйда була [2, 214 б]. Күп кенә әдипләр иҗатында импрессионизм, экзистенциализм, символизм, акмеизм, натурализм кебек дөньяга яңача караш, сәнгатьчә фикерләү алымнарын һәм модерн күренешләрен очрата алабыз. Кәрим Тинчуринның «Искәндәр» (1915), «Хәкимҗан агай» (1916) «Кара көннәрдә» (1918) хикәяләрен уку, өлешчә анализлау безне К.Тинчуринның модернизм юнәлешен, аңа хас билге-сыйфатларны бик теләп иҗади кабул итүен күрсәтте.

«Искәндәр» (1915) исемле хикәядә ике гашыйк Искәндәр белән Гөлфәрвазның рухи кичерешләре мәхәббәт белән бәйле. Әсәр тукымасында без романтик әдәбиятка хас бар атрибутика белән очрашабыз. Иң әүвәл: гашыйкларның һәр очрашуы табигать кочагында – бакчада бирелгән. Бакча – романтик әдәбиятта иң популяр һәм функциональ эчтәлеккә ия мотив. Андагы гүзәл, сихри пейзаж, кошлар сайраулары, музыка моңы, архитектур төзелмәләр, затлы хуш исләр аңкуы – барысы да үзенә бер әкияти-сәнгати дөнья хасил итә. Романтизм бакчаларына хас булганча, Искәндәргә этисе Шаһмармирзаның үзе кебек үк карт, мәһабәт бакчасында һәрнәрсә таныш: мәхәббәт серләрен саклаучы карт юкә, дошманны хәтерләткән корыган каен агачы, гөлләр белән бизәлгән терраса, куе сирень куагы, сөекле гөлләренә догалар укып су сибүче бакчачы Хәйрүш агай... Икенче бакча – Гөлфәрвазлар бакчасы. Ул да герцоглар замокларына охшаш, матур урында, матур стильдә салынган Ильясовларның йортын чолгап алган. Әсәрдә символик бакча образы геройларның сөю хисләрен, мәхәббәтләрен сурәтләүгә ярдәм иткән. Романтик бакча К.Тинчуринда җанлы итеп, гашыйк каһарманнарның дусты, сердәшчесе, хәтта яклаучысы итеп сурәтләнгән: «Июнь кояшының эссе шәүләләре Искәндәр белән Гөлфәрвазны карт бакчаның куе куакларының күләгәсе астындагы куе үләннәр арасына качырганнар иде» [4, 284]. Әмма яшьләр шулай, бакча күләгәсендә киләчәктәге тормышлары хакында киңәшеп, көзгә, туйдан соң,

Мәскәүгә барырга уйлап, киләчәккә планнар корып торганда, хезмәтчесе Искәндәргә шомлы телеграммма китерә: Германия сугыш игълан иткән, мобилизация [4, 285 б]. Күрәбез, бакча туктаусыз вакыт әйләнешенә, гүзәл яшьлек чорының кыскалыгына да ишарә ясаучы символ. Әсәрдә бакча образының ел фасылына нисбәтле бирелүе дә аерым мәгънәгә ия: гашыйкларның бәхетле мизгелләре язгы һәм җәйге бакча фонында бирелсә, Искәндәрнең үлеме турындагы сагышлы хәбәрне безгә көзге, «үлеп беткән» бакча җиткерә. Шулай итеп, К. Тинчуринның романтик бакча образына зур игътибар бирүе анын романтик эстетика кануннарын яхшы белгәнен дәлилли.

Искәндәр» хикәясендә гашыйк парларның мәхәббәтләрен чәлпәрәмә китергән, яшь Искәндәрнең тормышын котылгысыз үлем белән очлап куйган беренче империалистик сугыш белән алга таба К.Тинчуринның «Хәкимҗан агай» хикәясендә очрашабыз. Монда сугышны ләгънәтләү, гаделсез үлемгә каршы чыгу мотивы аеруча калкулаштырылып күрсәтелгән. Сугыш үзенә берьюлы Хәкимҗан агайны һәм аның улы Шакирҗанны корбан итеп ала. Автор сугышның коточкыч фаҗигасен тасвирлап бирү өчен Ауропа һәм Америка әдәбиятларыннан, аның төп теоретигы Э.Золядан кергән натуралистларча сәнгати фикерләүгә дикъкать иткән. Беләбез: натуралистлар чынбарлыкны тормышта ничек бар, шул рәвешле, бернинди сурәтләү чаралары белән баетмыйча язуны алга сөрәләр. Ул эчтәлеге белән ике төрле: тормыш күренешләрен фотограф кебек түкми-чәчми сурәтләп бирү һәм биологик-физиологик мотивларга өстенлек бирү. Хикәядә бу үтә дә дулкынландыргыч һәм куркыныч итеп, Хәкимҗан аганың сугыш мәсхәрәләгән улы Шакирҗан мәете белән очрашу күрешендә чагылыш тапкан. К. Тинчуринның натурализмның ике төре: натурализм-биологизм һәм натуралзм-фотографизмга мөрәҗәгать иткәнлеге күренә: «Тетелгән баш сөягенең кисәкләре, канга аралашып сыек камыр хәленә килгән миләр аның сакалына, мыекларына, тырнакларына, ниһаять, җиң очларына кадәр сыландылар» [ 4, 294 б.].

Кечкенә кеше темасын үзәккә алган «Кара көннәрдә» хикәясендә дә автор ачлык афәтен, социаль коллык психологиясен чагылдырганда, натуралистик

сурәтләрне мул кулланган. Ачлыктан тәмам гаҗиз булган Хәйрулла агай, улы Мөхәмәтханны бик тырышып, зур танышлык белән Зәйнулла байга кибетче ярдәмчесе итеп алдыра. Малайның анда күргән газаплары, ата-анасын сагынулары «гомергә сатып алган коллык» төрмә белән тиңләштерелгән. Әдип егетнең кичерешләрен яктыртканда сызлану фәлсәфәсенә (экзистенциализм), экспрессионизм, символизм күренешләренә иркен мөрәҗәгать иткәнлеге күренә.

Кыскасы, К.Тинчуринның прозасы гаять дәрәҗәдә кызыклы. Алар авторның сәнгати фикерләвендәге эзләнүләрен генә ачып калмыйлар, укучыны тормыш мәгънәсе хакында фәлсәфи уйланырга да чакыралар.

### Әдәбият


1. Бәшир Ф. Контрастлар художнигы / Ф.Бәшәр // Сөйлә, каләм! – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 66-71 б; Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Фикер. 2002. – 287 б.
2. Закирҗанов Ә.М. Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 287 б.
3. Сабиров Р.Р. К.Тинчуринның «Мәрҗәннәр» әсәрендә шәхес һәм дәвер каршылыгы // Фәнни язмалар-2007. – Казан: КДУ, – 2008 – Б. 234-239
4. Тинчурин К. Драмалар, комедияләр, хикәяләр; төз.Ф.Бәширов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. – 351 б.

# **Изучение средств языковой выразительности на материале прозы Виктории Токаревой.**

*Зиатдинова Лилия Ивановна,*
*преподаватель русского языка и литературы*
*ГАПОУ «Набережночелнинский педагогический колледж»*

20 ноября 2017 года отпраздновала свой 80 день рождения русская писательница Виктория Самойловна Токарева. Её творческая литературная биография началась ещё в детском возрасте. Печататься Виктория Токарева начала в 1964 году, но поистине всенародную любовь и признание ей принесли совместные работы в кинематографии с Георгием Данелия. Всем нам знакомы такие фильмы как «Джентльмены удачи», «Мимино», «Шла собака по роялю» и другие.

Мне как преподавателю русского языка и литературы творчество Виктории Токаревой интересно с точки зрения исследования языковых средств выразительности в её произведениях.

Литературная деятельность В.Токаревой неоднократно становилась объектом научных исследований. Так, можно отметить исследование Н.М. Калашниковой, которая изучает идиостиль писательницы и афористичность как одно из ее свойств. В то же время исследователи подчеркивают, что многие черты, в том числе вопросы о закономерностях использования некоторых троп и фигур писателя - метафор, сравнений, парцелляций - еще до конца не изучен [3, с.20]. Так, например, сравнение является наиболее излюбленным приемом писательницы. При помощи сравнений В.Токарева описывает героев, персонажей. В.Токарева часто обращается к анималистическим сравнениям. Так, внешность людей сравнивается с образами животных, птиц. Например:

*Люди горбились, как пингвины.*

*Ее ладонь была крупной, округлой, как у медведицы.*

Среди других металогических приемов автор использует эпитеты. Чаще всего привлекают внимание оригинальные, авторские эпитеты. Например: *Казалось, что чужое биополе царапает его кожу. Может, душа этого парня плавает бесхозно*.

Иногда, используя эпитеты, В.Токарева иронизирует над обществом и над русским менталитетом вообще. *Например: И когда употребляли безликий мат, было совершенно ясно, что они хотят сказать. Костя заметил, что в мате – очень сильная энергетика, поэтому им так широко пользуются. Как водкой. В водке тоже сильная энергетика*.

Обращает на себя внимание и тот факт, что В.Токарева обильно использует прецедентные имена. Например, при описании своего начальника, герой одного из произведений говорит о его незаурядном уме и таланте с восхищением:

*– Ему ничего не стоит выдумывать новый самолет и открыть новый закон. При этом он не кричит «эврика!», как Архимед, а просто откидывается на спину рабочего кресла и делает пружинящие разводы руками в стороны.*

Произведения В.Токаревой не изобилуют вычурными метафорами, эпитетами. Ее описания точны, кратки. Метафоры подчеркивают особо важные переживания, качества героев. Например, важность мечты и
смысла жизни героя передается при помощи метафоры *хрустальный*, эпитета *любой*: «*У меня есть хрустальная мечта в жизни: я мечтаю, чтобы в один прекрасный солнечный день любого времени года Копылов заметил бы меня, подошел и протянул ру*ку».

Умело использует писательница и повторы. Приведем пример самого простого вида повтора. Вот так описывает прогулку В.Токарева: *Было пустынно. Деревья под снегом казались добрыми. Добрые деревья и добрые дома. Медленнее, чем обычно, шло такси. Была гололедица, и ездить следовало осторожнее, но мне думалось, машина идет медленно оттого, что за рулем добрый шофер*. Современная русская проза представлена многими именами: Т.Толстой, Л.Улицкой, В.Пелевиным, Б.Акуниным, В.Токаревой и других.

Признавая их жанровое своеобразие, читатели и критики неоднозначны в своем отношении к ним. Тенденция к межтекстовому взаимодействию с классикой в иных случаях воспринимается, как неумение создать свое, оригинальное, а маргинальность речи – чудовищной последовательностью отсутствия эстетического вкуса [2, с.608].

Писательницей активно используются средства языковой выразительности русского языка. Произведения В.Токаревой охватывают вечную и тем более актуальную в наше время проблему – противостояние материального и человеческого, и средства выразительности помогают писательнице лучше раскрыть темы произведений.

Средства языковой выразительности многообразны. Особое место среди них занимают так называемые средства художественной изобразительности (художественно-изобразительные средства: звукопись, метафоры, олицетворения, гиперболы и т.д.), основанные на использовании специальных приемов и способов сочетания звуков, слов, словосочетаний, предложений. Однако выразительность текста создается не только с помощью использования специальных художественно-изобразительных средств. Значительные выразительные ресурсы заключены в лексике и фразеологии языка, а также в его грамматическом строе и фонетических особенностях. Именно поэтому можно говорить о выразительных средствах языка на всех его уровнях: фонетики, лексики и фразеологии, морфологии и словообразования, синтаксиса.

Актуальность рассмотренного вопроса, на мой взгляд, обусловливается тем, что для учителя-словесника основной задачей становится организация процесса обучения грамматике, с учётом эстетических возможностей изучаемых языковых явлений, способствующих развитию у обучающихся чувства слова, формированию у них потребности в совершенствовании собственной речи.

# Ташлар телен белгән язучы-галим

*Зиннәтуллина Гөлнара Ханнан кызы,*
*Балтач муниципаль районы МБГБУ*
*“Куныр урта мәктәбе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Исән булса, аңа 14 март көнне 80 яшь тулган булыр иде. Үзенең ярты гасыр гомерен татар тарихын өйрәнүгә багышлаган легендар якташыбыз, кызганычка, ике ел элек бакыйлыкка күчте. Галим, археолог, тарих фәннәре докторы, язучы , публицист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Һади Атласи исемендәге премиянең беренче лауреаты, ТР Министрлар Кабинеты каршындагы тарихи “Мирас” комиссиясенең күп еллар дәвамында рәисе, берничә гыйльми совет әгъзасы, “Татар археологиясе” журналына нигез салучы, 300 гә якын басма хезмәт, шул исәптән 30 дан артык китап (фәнни монографияләр, Фәнни-популяр китаплар), урта мәктәп, лицейлар һәм гимназияләр өчен дәреслек, уку һәм күргәзмә әсбаплар авторы... – Равил Габдрахман улы Фәхретдиновның фәнни эшчәнлеген, шәхес буларак, яшәү рәвешен ачык күрсәтә торган бу исемлекне әле шактый дәвам итәргә була. Ул колачлаган тикшеренү -өйрәнү эшләренең күләмен күзаллау өчен аның Татарстан, Идел буе, гомумән, Урта Евразия җирлегенең, бөтен татар халкының урта гасырлар археологиясе һәм тарихын, моңа кадәр күрелмәгән киңлектә өйрәнүен әйтү дә җитәдер. Бетмәс энергиясенә, тырышлыгына коллегалары- ил күләмендә танылган тарихчылар үзләре дә тикмәгә генә сокланмый шул!

Равил абыйның биографиясенә күз салу белән аның яшьтән үк шундый күпкырлы, энергияле, максатчан булуын күрәсең. Кариле авылында туган, Балтачта үскән, балачагы, үсмер, егет чагы шунда үткән. Урта мәктәпне тәмамлагач, район физкультура һәм спорт комитеты рәисе булып эшләгән.

1958—1963 елларда Р. Фәхретдинов — Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультеты студенты. Уку елларында, җәмәгать, үзешчән

сәнгать һәм мәдәни эшләрдә активлык күрсәтү белән бергә, фәннәрне өйрәнүгә гаять күп вакыт бирә, ел саен Татарстан оештырган археологик экспедицияләргә чыгып йөри. Ленин стипендиясе алып укып, институтны югары дәрәҗәле диплом белән тәмамлагач, яшь белгечне Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты каршындагы аспирантурага кабул итәләр. Анда ул өч ел дәвамында (1963—1966) Идел буе Болгар-станының археологик истәлекләрен җентекләп өйрәнеп, шул темага кандидатлык диссертациясе яза һәм 1968 елда М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү университеты гыйльми советында аны уңышлы яклап кайта. 1990 елда ул шул ук университетның гыйльми советында докторлык диссертациясен яза.

1966—1996 елларда Р. Фәхретдинов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әүвәл кече фәнни хезмәткәр, аннан өлкән фәнни хезмәткәр һәм әйдәп баручы фәнни хезмәткәр булып эшли. 1996 елда институт икегә аерылып, Татарстан Фәннәр академиясе карамагында Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге мөстәкыйль Тарих институты оешкач, Р. Фәхретдинов баш фәнни хезмәткәр сыйфатында гыйльми эшчәнлеген институтта дәвам итә. Равил Фәхретдинов — урта гасыр Идел буе һәм гомумән Урта Евразия (Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Кырым һәм башка татар ханлыклары, тагын да элгәреләрдән Төрки каһанлыгы, Дәште Кыпчак) тарихы һәм археологиясе буенча абруйлы белгечләрнең берсе. Ул — бу темаларга багышланган өч йөзгә якын төрле басма хезмәтләр: мәкаләләр, монографияләр, дәреслекләр, уку әсбаплары, борынгы чор археологик истәлек тупланмалары, карта-схемалар, альбомнар һәм фәнни-популяр китаплар авторы. Аның күп кенә гыйльми хезмәтләре үзәк матбугатта (шул җөмләдән — өч монография), унлап хезмәте чит илләрдә (Канада, Төркия, Венгрия) басылган. 1959—1972 еллар дәвамында Татарстанда һәм аңа чиктәш территорияләрдә (Чувашия, Ульянов, Самара, Түбән Новгород өлкәләрендә) тоташ археологик эзләнүләр алып барып, төрле археологик чорларга һәм культураларга караган мең дә ике йөздән артык яңа табылган истәлекләрне барлап тикшерә һәм урта гасыр Идел буе территориясенең билгеле булган барлык истәлекләре теркәлгән

гомумархеологик картасын төзи. Бу хезмәте өчен ул 1975 елда ВДНХның медале белән бүләкләнә. Тарихчы-археолог тарафыннан төзелгән әлеге археологик истәлекләр тупланмасы соңыннан «Татарстан АССРның археологик картасы» дигән алтытомлык коллектив хезмәт нигезенә җирлек булып ята. 1972—1992 елларда Р. Фәхретдинов, Иске Казан территориясендә археологик казу эшләренә җитәкчелек итеп, монографик хезмәте өчен бай фактик материал туплый, табышлары, ачышлары турында республика һәм үзәк матбугатта дистәләрчә мәкаләләр язып чыга. Соңгы елларда Р. Фәхретдинов татар тарихына нисбәтле борынгы эпиграфик истәлекләрне эзләү, ерак тарихи чорлардан эзләре калган шәһәрлекләрне, авыллыкларны, һөҗүмнән саклану корылмаларын, бина калдыкларын, борынгы төзелеш үрнәкләрен өйрәнү-барлау максаты белән Казан арты, Кама-Чулман аръягы, Урта Идел төбәкләренә еш кына махсус экспедицияләр оештырды. Узган гасырның туксанынчы елларында иҗтимагый-сәяси һәм идеологик үзгәрешләрдән соң гомуми белем бирү мәктәпләре өчен тарих буенча яңа дәреслекләр язу ихтыяҗы тугач, иң беренче булып бу эшкә Р. Фәхретдинов алынды. Аның татар һәм рус телләрендә берничә тапкыр басылып чыккан «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» («История татарского народа и Татарстана») дигән дәреслек китабы, Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланып, урта мәктәпләр программасына төп уку дәреслеге буларак тәкъдим ителде.

Соңгы вакытта галим татар халкының VI—XX йөзләр арасында Урта Евразиянең гаять зур территориясендә — көнчыгышта Орхон буйларыннан алып көнбатышта Дунай елгасының түбән агымына кадәр, төньякта Казан-Нократ киңлекләреннән Төньяк Кавказ далалары һәм Әстерханга кадәр җәелгән киң мәйданда сакланып калган тарихи-мәдәни-матди истәлекләр мирасын җентекләп барлау, тәртипкә салу һәм теркәү эше белән шөгыльләнде. Бер үк вакытта ул менә ун елга якын инде җәмәгать тәртибендә, үз нәширлегендә һәм мөхәррирлегендә, барлык чыгымнар турында кайгыртуны үз өстенә алып, зур тырышлык һәм үҗәтлек белән «Татарская археология» дигән уникаль журнал

чыгарды. Моннан тыш, табигать Равил Фәхретдиновка иҗат эшенең башка юнәлешләренә караган сәләтләрне дә мул биргән. Ул — татар әдәби теленең бөтен нечкәлекләрен тоеп яза белә торган каләм остасы да, халык авыз иҗаты, музыка, җыр сәнгате турында төпле фикер йөртергә, кызыклы күзәтүләр һәм гомумиләштерүләр ясарга сәләтле сәнгатькяр дә, хәтта халык җырларын гаҗәеп моңлы, үзенчәлекле тавыш белән башкаручы җырчы-гармунчы да. Аның матур, образлы тел белән тарих, археология фәне турында, урта гасыр болгар-татар шәһәрләре, ал арның архитектура үзенчәлекләре, табылдык көнкүреш һәм сәнгать әйберләре, Сөембикә, Аксак Тимер, Туктамыш хан, Идегәй кебек легендар шәхесләр турында язган популяр жанрдагы әсәрләре («Ташлар моңы», «Мондадыр безнең бабайлар», «Кичке азан» җыентыклары) ерак заманнарда яшәгән ата-бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен, алар кичергән тарихи вакыйгаларны, алар җитештергән матди байлыкларны җанлы картиналарда сурәтләп бирәләр. Бу төр әсәрләрнең теле, стиле төрле катлау укучыларга да җиңел аңлаешлы, аларда образлы чагыштыруларны, халыкчан гыйбарәләрне, матур-тәэсирле итеп табигать күренешләрен тасвирлаган урыннарны еш очратасың, кайчакны автор, уй-фикерләрен ныгыту өчен, бик урынлы рәвештә Тукай, Дәрдемәнд һәм башка шагыйрьләрнең иҗат мирасына мөрәҗәгать итә, алардан шигъри юллар китерә.

Киң җәмәгатьчелеккә галим тарихи-сәяси, татар халкының бүгенге мөстәкыйльлек өчен көрәш темаларына багышланган полемик характердагы публицистик мәкаләләре, күренекле кешеләр турында иҗат портретлары һәм истәлек язмалары авторы буларак та билгеле.

Җырчы (Илһам Шакиров). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 78 б. – 5000 д.

Ташлар моңы: археолог язмалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 192 б. – 9000 д.

Мондадыр безнең бабайлар: археолог язмалары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 176 б. – 10000 д.

Кичке азан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 223 б. – 5000

# Эльмира Шарифуллина иҗатында әдәплелек, милли тәрбия һәм хөрмәт мәсьәләләре.

*Гафиятуллина Энже Хабибулла кызы,*
*филология фәннәре кандидаты, татар теле һәм*
*әдәбияты укытучысы, Казан энергетика көллияте.*

Эльмира Шәрифуллинаның исеме көндәлек матбугатта үткән гасырның алтмышынчы елларында күренә башлый. Ул әдәбиятка бик озак килә.

Эльмира Шәрифуллина татар шигъриятендә үз юлын, үз йөзен тапкан тәҗрибәле сүз остасы. Күңелендә йөрткән хис-кичерешләрен ак кәгазьгә күчерү нәтиҗәсендә туган шигырьләре, тормышының аерым мизгелләрен, укытучы булып эшләгәндә туплаган тәҗрибәсен чагылдырган повесть һәм хикәяләре, нәниләрне тәрбияләүдә методик кулланма дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән, шул ук вакытта балаларча самимилек, эчкерсезлек белән сугарылган әкият-хикәятләре хәзерге заманның теләсә-кайсы таләпчән укучысын канәгатьләндерә алырлык. Басылып чыккан китапларының саны һәм тиражы нәкъ менә шул хакта сөйли. Бүгенге көндә Эльмира Шарифуллина – 20 дән артык китап авторы.

Ул сабыйларның күңелләренә туган җирне, табигатьне, үз халкыңны ярату, милли гореф-гадәтләрне саклау һәм хөрмәт итү, якын кешеңә, бигрәк тә Ана кешегә миһербанлы, игелекле булу кебек гуман хисләрне сеңдерергә тырыша.

Татар халыкның борынгыдан килгән йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрен чагылдырган әдәби әсәрләре аша халкымның куңел җәүһәрләрен барлый, үткәнен киләчәк буыннарга җиткерә, киләчәккә ышанычын арттыра, милләтебезне саклауда бер юнәлеш булуын азсызыклый.

Чөнки әдәбият аша гына халыкның бик тирәндә яткан сыйфат – хасиятләрен, үзенчәлеген, милли рухын тоеп, сиземләп була.

Бүген минем кулымда 1970 елда бастырылган “Беренче карлыгачлар” дип аталган яшь шагыйрьләр җыентыгы.

Бу җыентыкта Эльмира Шәрифуллинаның 14 шигыре тәкъдим ителгән. Ул вакытта аңа 23 яшь булган. Минем дә 18, 20 яшь чагыма алып кайта торган матур шигырләре арасыннан бүгенге конкурска “Сызыла да гармун сызыла” шигырынә тукталдык.

Әйе, нәкъ шушы гармунның моңына, җансыз көймә ай яктысында елгадагы дулкын өстендә уйнап торуы күз алдына килеп басты.

Бу әсәрендә аның тыйнак күңеле, әдәплелеге, серле уйлары, халкыбыз моңнарын ярату сыйфатлары сизелеп тора. Аның ни өчен гармун моңына йөрәк бәгырьләре сыкрануын, үзәкләре нигә өзгәләнгәнен укучы аңлый алмый. Чөнки яшәүне – ул берни белән дә тиңли алмаслык бәхет ди. Табигатьнең гаять серле халәте, айның болыт эченә яшеренүе, яшен кабынуына, елгада сукмак күренүе, ялгыз көймәнең хуҗасыз булуы – барда яшәешнең бер мизгеле.

Аның әсәрләрендә милли рух кызыл җеп булып сузыла. Ул үз халкының гореф-гадәтләрен, милли ризыкларын, йорт җиһазларын аерым бер эчке горурлык белән, аларның хәзердә халык күңелендә онытылмыйча саклап килүенә куаныч белән, милли сыйфатларын тирән ачып сурәтли. Монда “Кендек әбекәем”, “Каз өмәсе”, “Карга боткасы”, “Сәке турында”, “Сөлге турында”, “Тормыш яме” кебек шигырьләрен атап үтәргә мөмкин.

Ул рәхәтләнеп безнең белән балачактан исендә калган бәйрәмнәр белән уртаклаша. Сәкенең бүгенге көндә бер өйдәдә булмавы белән борчыла, ә аның шигырьләрендә ул сәке өстәл дә, сандык та, карават та, намаз укый торган мөнбәр дә булып сурәтләнә.

Эльмира Шәрифуллина үз иҗаты белән киләчәк буынга милли бизәкләребезне гореф-гадәтләребезне, гомумән, милли рухыбызны илтеп җиткерүне максат итеп куйган милләтпәрвәр шагыйрә ул.

Аның иҗатын караганда, әниләргә багышлаган шигырь җыентыкларына туктамый мөмкин түгел: “Иң матур әни”, “Яз җыям”, “Елмаегыз, көлегез” җыентыкларында ул үзе тормышның ачысын-төчесен татыган, шатлыкны да,

кайгыны да күргән, ана хисләре һәм бала тәрбияләүне дә кичергән Әни буларак тирән мәгънәле  шигырьләрен язган.

Аның әсәрләрендә очраган образлар – безнең бүгенге тормышыбыз, чынбарлыгыбыз. “Без, балаларны милли рухта тәрбияләп, үзебезнең бәхетле киләчәгебезне әзерлибез, чөнки милли рух – акыл һәм гүзәллек, зәвык һәм әхлак, хезмәт һәм туган җиргә мәхәббәт чарасы ул” – дип кисәтә безне Эльмира Шәрифуллина.

Үземнең чыгышымны Равил Файзуллинның шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син.
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен.
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Шәрифуллина Э. Иң матур әни: Шигырьләр, әкият-хикәятләр. – Казан, 1999. – 40 б.
2. Шәрифуллина Э. Гөлләр елы: Г – Шигырьләр. – Казан, 1988, - 104 б.
3. Шәрифуллина Э. Яңгыр җиле: Шигырьләр. – Казан, 1984. – ы78 б.
4. Шәрифуллина Э. Уйлы еллар: Шигырьләр. – Казан, 2003.- 287 б.
5. “Беренче карлыгачлар”. Яшь шагыйрьләр җыентыгы. – Казан, 1970. – 143 б.

# Галимҗан Ибраһимов иҗатында татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары

*Сөнгатуллина Гөлшат Гыйлметдин кызы*
*Татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче урта гомумбелем мәктәбе муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе*

Г. Ибраһимовның һәр әсәре татар халкының гореф-гадәтләре, традицияләре, ышанулары, йолалары турында мәгълүмат саклый. Аның иҗатында татар халкының сабан туе, өмәләре, ат саклаулар, аулак өйләр, егетләрнең гармун уйнап урам әйләнүләре тасвирлана. Татар халкының сабан туе бәйрәме, аның аерым йолалары әдипнең «Алмачуар» хикәясендә, «Яшь йөрәкләр» романында бәян ителә, «Карак мулла» хикәясендә искә алына. Әлеге әсәрләрдә язучының төп игътибары ат чабышларына бирелгән. Бу әсәрләргә нигезләнеп XIX– XX гасырлар чигендәге сабан туе бәйрәмен күзалларга мөмкинлек туа.

Г. Ибраһимов сабан сабан туе алдыннан була торган әзерлекләрне, сабан туе алды йолаларын да бик җентекләп тасвирлый. Сабан туен бөтен кеше көтеп алса да, көрәшчеләр, чабышкы ат хуҗалары өчен әзерлек эшләрен, атларны чабышка әзерләүне күп алда башлыйлар. Мәсәлән, «Карак мулла» хикәясендә татар бае Сафа һәрвакыт чабышкы атлар тота. Ул сабан туенда ярышта җиңәрлек ат эзли, тай алып сабан туе чабышкысы үстерә. «Яшь йөрәкләр» романында да шушы ук тема алга таба үстерелә. Романның бер герое Җәләш (Җәләлетдин) хәзрәтнең дә бер мавыгуы атлар белән бәйле – «Ул һәрбер сабан туенда, башка атларны икешәр чакрым артта калдырып, гел беренче килерлек булган бер чабышкы тотуны сөя һәм шуның өчен кайда чабышкы булуы өмитле бер тай, бер ат сатылса, ул ала, тәрбияли, шуны чабышкы ясарга хәзерли» [1, б. 248]. Димәк, ат хуҗалары сабан туена әзерлекне берничә ел алдан башлыйлар. «Алмачуар» хикәясендә чабышкы

атны тәрбияләү тулы этабы белән тасвирлана. Колынның тугач та аякlануын күреп, «Шәп мал аякланып туа» [2, б. 517] дигән ышануга нигезләнеп аңа баштан ук зур өметләр баглана. Чабыш аты булырга юралган Алмачуарны эшкә җикмиләр: «Урманга, тауга-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак?» [2, б. 525]. Шул ук вакытта тайны әкренләп сабан туена әзерлек тә башлана. «Менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм» [2, б. 525]. Чабыш атын әзерләүгә җитди якын килгәннәр, чабышкы асраган картлардан да өйрәнгәннәр, алар да тәҗрибәләре белән уртаклашкан. Сабан туе җиткәндә атның рационы да үзгәрә. Аңа печәннең корысын гына бирәләр, бүлеп-бүлеп солы салалар, азлап-азлап апара суы эчерәләр [2, б. 526].

«Яшь йөрәкләр» романында сабан туе иртәсе тасвирлана. Сабан туеның бер бизәге – кунаклар кабул итү. Бу көнне «чит авылдан кунаклар җыела» [1, б. 252]. Сабан туена кунаклар килү традициясе татар халкында хәзергә кадәр дәвам итә. Татар авылларына кунаклар сабан туе вакытын туры китеп кайталар. Сабан туе кеше гомеренең бер еллык этабы тәмамлануын, икенче яңа ел башлануын да күрсәтеп торган вакыт та. Читкә китүчеләр бу бәйрәмдә туган-тумачалары, дуслары, авылдашлары белән очраша. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестендә читкә китеп эшләүчеләрнең дә сабан туена кайтып җитәргә тырышулары турында сүз бара.

Шахтага акча эшләргә киткән Солтан да язгы сабан туена кайтып җитәргә тырыша. Сабан туе алды йолаларының берсе – бүләк җыю. Сабан туе өчен бүләк җыю йоласы бәйрәм буласы көнне яки бер көн алдан үткәрелә: «Авылның барлык егетләре атка менеп, яшь килен төшкән йортлардан сөлге-фәләннәр җыеп йөриләр» [1, б. 248].

Бүләк җыю йоласы хәзерге вакытта да уздырыла. Хәзерге вакытта бүләк җыйганда һәр йорттан бүләк бирергә тырышалар. Шулай да, күп кенә төбәкләрдә яшь килен бүләгенә аерым игътибар бирелә. Кагыйдә буларак, яшь килен сабан туе өчен махсус бүләк – чиккән сөлге әзерли. Кунак кызлардан чиккән кулъяулык алалар. Иң матур, зур чиккән сөлге сабан туенда беренче килгән атның муенына салынган. Башкалары да бүләксез калмаган. «Нәзек,

суырылган, танылмас мәртәбәдә тиргә баткан юртаклар берәм-берәм килә тора, сөлгене ала торалар» [1, б. 254].

Сабан туе көнне сөлге җыю күренеше «Алмачуар» хикәясендә дә урын алган: «Сабан туе көнне егетләр сабан туе бүләге өчен сөлге җыйса, ул көнне балалар өйдән өйгә кереп йомырка җыйганнар. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү, өйдән өйгә йомырка сорарга чыкканнар. Аларга яшелле-кызыллы буяуга буяп әзерләп куйганнар» [2, б. 527]. Татар халкының тагын бер йоласын искә төшерү урынлы булыр. Чабышта иң соңгы килгән ат та бүләксез калмаган, аның өстенә алдан адарынган кешеләр үзләренең сөлгеләрен салган. Бу күренеш «нәзер сөлгесе» дип телгә кергән.

Сабан туйлары һәрвакыт авылга якын, авыл күренеп торган җирдә үткән. Сабан туйларында ир-егетләр белән хатын-кызлар мәйданның ике ягында булган. Хатын-кыз ярышларга катнашмаган, кагыйдә буларак, тамашачы сыйфатында гына бәйрәм караган. «Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үз алдына дулкынланып тора, – болар хатын-кызлар. Икенче якта бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар» [2, б. 527].

Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясендә сабан туеның икенче бизәге – көрәшне дә тасвирлый. Хикәядән сабан туйларының бөтенесе бер төрле булмаганы, зур һәм кечерәкләре булганлыгы аңлашыла: «Бүген сабан туе! Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торган, – бик зурысы, бик шәбе! Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар» [2, б. 525]. Сабан туеның төп ярышлары – көрәш, ат чабышы һәм ир-егетләрнең йөгерү буенча узышы булганлыгы аңлашыла. Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясендә ат чабышын да бәян итә. Әсәрдә чабышта катнашучы малайларның киеме, яулык бәйләве, камчылары, чабыш башланып китү, аның барышы һәм атларның узышуы тасвирлана.

Йомгак ясап әйткәндә, Г. Ибраһимов иҗатында татар халкының күп кенә йолалары турында мәгълүмат сакланып, алар онытыла бара торган

йолаларны, күренешләрне торгызырга да ярдәм итә торган чыганак та булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 1 том. Казан: Татаркнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1957, 528 б.

2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 2 том. Казан: Татаркнигоиздат, Матур әдәбият редакциясе, 1956, 596 б.

# “Эльмира Шәрифуллинаның “Без –Тукайлы!” поэмасы”

*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча 5нче гимназиясе – муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы Газизова Эльмира Илгиз кызы*

Бу эзләнү эшендә минем Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасы буенча туплаган белемнәремне һәм тапкан ачышларымны бәян итәсем килә. Нәкъ менә бу авторның мәгълүм әсәренә тукталуым юкка түгел. Шагыйрә белән очрашу кичәсендә “Бу поэманы язуга нәрсә этәргеч булды?” – дигән соравыма шагыйрәнең җавабын ишетү мине әсәрне тагын да тирәнтен өйрәнүгә этәрде. Бу әсәрне кабат бик кызыксынып укып чыктым һәм үзем өчен яңадан ачтым.

Әзләнү эшен мин Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасы белән беррәттән Р.Харисның “Тукайның мәхәббәт төшләре”н, М.Әгъләмнең “Тукайдан хатлар”ын, Ә.Баянның “Каракош” исемле поэмаларын һәм шагыйрәнең башка темаларга иҗат ителгән “Каюм коесы”, “Мордар”, “Инша”, “Әткәй күңеле” поэмаларын укып чыгудан башладым. Шулай ук шагыйрәнең 40 елдан артык булган иҗат юлында Тукайга багышлап язылган әсәрләрен күзәтеп чыктым. Миндә иң зур тәэсир калдырганы “Без – Тукайлы!” поэмасы булды, чөнки аның үзәгендә милләт улы Тукай белән горурлану тойгысы ята.

Эльмира Шәрифуллинаның иҗатына күп кенә каләмдәшләре үз бәяләрен биргәннәр. Вакытлы матбугатта басылган Госман Садәнең “Каләмендә зәңгәр кичләр”, Әмир Мәхмүдовның “Мәхәббәт шагыйрәсе”, “Нурихан Фәттахның “Татар шигърияте күгендә”, Ләбибә Ихсанованың “Мәхәббәт турында җыр”, Гөлшат Зәйнашеваның “Гөлләр елы”, Мөдәррис Әгъләмнең “Уйлый ла күңелем төрлесен”, Нияз Акмалның “Сөйгән кеше чынлап чибәр була”мәкаләләрен күзәтеп чыкканнан соң, шагыйрәнең иҗатына каләмдәшләре тарафыннан бик дөрес бәя бирелгән, әмма әдәбият галимнәре тарафыннан Эльмира Шәрифуллинаның иҗаты әле аерым алып өйрәнелмәгән дигән нәтиҗәгә килдем. Бары тик Тәлгать Галиуллинның “Әдәбият – хәтер хәзинәсе” дигән хезмәтендә “Тукайлы шигърият” дип исемләнгән Тукай һәм хәзерге татар поэзиясенә күзәтү ясаганда бу поэма үз фикерләрен турында язып үтә. Әдәбият галиме белән тулысынча килешәм. Иҗатлары белән милләтебезгә армый-талмый хезмәт итүче, Тукай кебек даһи шәхесләрне мәңгеләштерүче татар җанлы шагыйрь һәм шагыйрәләребезне белү кирәк. Бу фәнни хезмәтебезнең актуальлеге шуның белән билгеләнә.

Шулардан чыгып, максатым түбәндәгечә билгеләнде:

Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасын өйрәнү аша, шагыйрәнең иҗатында Тукай темасын ачыклау.

Эшемнең максатыннан чыгып төп бурычлар билгеләнде:

1. Эльмира Шәрифуллинаның шәхесе һәм аның шигърияттәге иҗади эшчәнлеге турында мәгълүмат туплау.

2. Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасына хас үзенчәлекләрен өйрәнү.

3. Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасының әһәмиятен билгеләү.

Фәнни хезмәт өч өлештән тора: кереш, төп һәм йомгаклау өлешләре.

Кереш өлештә фәнни-эзләнү эшенең максат һәм бурычлары билгеләнде. Бу тема буенча эшләгән галимнәрнең хезмәтләре, мәкаләләре турында язылды.

Төп өлештә Эльмира Шәрифуллинаның тормыш юлы һәм шигъриятенә күзәтү ясалды. Эльмира Шәрифуллинаның “Без –Тукайлы!” поэмасы – Тукайга багышлап иҗат ителгән әсәрләрнең гүзәл бер үрнәге икәнлеге расланды. Шагыйрәнең “Без –Тукайлы!” поэмасының темасы, идеясе, тел-сурәтләү чаралары турында өйрәнүләр бәян ителде.

Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” әсәре – поэма. Поэма тартмалы композициягә нигезләнгән, ягъни әсәрдә бүлекләр бер-берсенә бәйләнмәгән. Шагыйрә белән очрашып сөйләшкәндә, иң элек поэманың күп кенә бүлекләре аерым шигырь буларак язылганлыгын ачыкладым. Бу аңлашыла да, чөнки поэма – шагыйрәнең бөтен гомере буена сузылган иҗат җимеше. Тукай порталына урнаштырылган видео чыгышыннан аңлашылганча, Эльмира Шәрифуллина Г.Тукай иҗатын гомере буена өйрәнә.

Һәр бүлек башында эпиграф – фикер-хис агышына туры килерлек итеп, Тукай әсәрләреннән алынган.

“Без – Тукайлы!” поэмасы 12 бүлектән тора. Бүлекләр исемләнмәгән, ләкин без үткәргән тикшеренүләрдән күренгәнчә, аларда түбәндәге темалар ачыла:

I бүлектә Кушлавыч белән хозурлану;

II бүлектә Кушлавыч чишмәсе – Тукай чишмәсе;

III бүлектә Кушлавыч – Тукай өчен генә түгел, ә лирик герой өчен дә туган җир;

IV бүлектә шагыйрьнең яшерен сөюе;

V бүлектә этисе Мөхәммәтгариф турында;

VI бүлектә бәгырьләрне кискән ятимлеге;

VII бүлектә дөньяга Тукайны бүләк иткән әнисе Бибимәмдүдәгә рәхмәт әйтү;

VIII бүлектә Арча ягы тудырган бөек шәхесләр;

IX бүлектә Фатих Әмирхан белән дуслыгы;

X бүлектә шагыйрә сүзләре белән әйтсәң:

“Татарымның олуг Мөхәммәте,

Милләтемнең горур акыны!”

XI бүлектә Тукай – Җирдәге, күңелләрдәге яктылык, чисталык үрнәге;

XII бүлектә Тукайлы милләт булуыбыз белән без бәхетле.

Йомгаклау өлешендә сүз Эльмира Шәрифуллинаның “Без – Тукайлы!” поэмасында әйтелгән фикерләренең бөтен татар халкы өчен әһәмиятле булуы турында бара; шагыйрәнең әсәрләрен өйрәнүнең әһәмиятенә басым ясала.

Нәтиҗә: Эльмира Шәрифуллинаның шигъри иҗатын, аерым алганда, “Без – Тукайлы!” поэмасын өйрәнеп, мин түбәндәгеләрне аңладым:

1. Эльмира Шәрифуллинаның иҗаты гаять бай һәм күпкырлы;

2. Эльмира Шәрифуллинаның “Без –Тукайлы!” поэмасы – Тукайга багышлап иҗат ителгән әсәрләрнең гүзәл бер үрнәге;

3. Эльмира Шәрифуллинаның әдәбият дөньясында үзенә генә хас, кабатланмас “Тукае” бар икән.

Шагыйрә Тукай белән горурлануын һәр бүлектә ачык сиздерә. Милләт өчен көрәшүен, туры сүзле булуын кат-кат ассызыклый. Автор чиксез зур горурлык хисләре белән болай дип яза:

Җыры барның җирдә даны булыр,
Бәйрәмнәре булыр мәңгегә.
Без бәхетле, без шагыйрьле халык,
Без— Тукайлы халык мәңгегә!

# Әлфия Ситдыйкова иҗатында туган җир темасы

*Абдуллина Г.Х., китапханәче,*
*Бөгелмә шәһәре 3 нче урта мәктәбе*

Соңгы вакытта татар әдәбиятында хатын-кызларның активлыгы күзгә ташлана. Бу бик тә куанычлы хәл. Әдәбиятыбызны, культурабызны үстерүдә үзләреннән лаеклы өлеш кертүләре бигрәк тә куандыра. Шулар арасында Әлфия Ситдыйкова әһәмиятле урын алып тора.

Әлфия Ситдыйкова... Аның исеме белән беренче тапкыр мин «Мәйдан» журналы битләрендә таныштым. Аның әсәрләрен бик кызыксынып, яратып, күңел биреп укыдым. Һәрбер әсәренең үзенчәлекле, тормышчан, күңелгә ятышлы булуы миндә зур кызыксыну уятты.

Шагыйрәнең иҗатында төп темалар - мәхәббәт, туган авыл, табигать, ил һәм кешеләр язмышы. Әйе, аның шигырьләре тормышчан, гади. Алар уйландыра, күңелнең иң нечкә кылларына кагыла, туң йөрәкләрне дә эретә, кайберләре күздән яшь тә чыгара. Шигырьләрендә күңелендә йөрткән уйларын һәркем йөрәгенә үтеп керерлек, халыкчан итеп кистереп әйтә ул.

Әлфия Ситдыйкова шигъриятен тематик чикләр белән аеру мөмкин түгел. Тик шулай да аның бәрәкәтле шигырь бәйләмнәре үзәгендә өзлексез яңгырый торган берничә олы хис, шуларны сугарган үтәли мотив бар: ул - анага мәхәббәт, туган якка тугрылык, кешеләр, бигрәк тә хатын кызлар язмышы өчен борчылу.

Туган як, туган ил, туган җир категорияләре халык иҗатында һәрвакыт төп урыннарның берсен алып тора. Туган илен, җирен, авылын яратмаган, сагынмаган кеше юктыр бу дөньяда. Бу һәркемгә хас тойгы. Бигрәк тә нечкә күңелле язучы шагыйрьләрдә.

Әлфия Ситдыйкова туган ягының нечкә серләрен ачып бирә:

Кайткан саен, Туган авылкаем,
Каршылыйсын җәеп кочагың.
Саклыйсын син хәтер төпкелендә

Бөтерчектәй җитез, ут чагым.

Туган җир һәм аның кырыс та, юмарт та була белгән табигате... Ул шагыйрәне берөзлексез иҗатка рухландырып, шигърияткә, шигъри җанлы туган халкына якынайтып тора кебек. Шуңа күрә дә шагыйрә күңелен нинди генә хис һәм борчулар биләмәсен, ул, кайтып-кайтып, аңарга мөрәҗәгать итә:

Назлап сыйпый туган якның җиле
Көмеш бәсле йомшак чәчемне.
Сиңа кайткач, күңел канатлана,
Онытам мин хәтта яшемне.
Кайткан саен гүя кабат туам
Һәм яшәрәм язгы гөл сыман.
Хушлашам да, капкаларны ябып
Чыгуга ук сине юксынам.

Әлфия Ситдыйкова өчен туган як табигый һәм рухи чыганакларның берсе:

Әрем исе татлы сагыш булып,
Күңелемә кереп урын ала.
Бер туктамый бәллүр бишегеңдә
Тирбәләм мин - һаман сабый бала.

Туган җир шагыйрә өчен матур сүз яисә хәтирә генә түгел. Аның өчен туган җир – сихри көч тә: «Һавадагы сөт исеннән Күк исереп йолдыз ата», кендек әбиләренең изге догасы да, аналарның таң җиледәй йомшак кулы да, кояш яктысын капларга тырышкан “кара хәбәр” дә, “күңел түреннән шытып чыгып, хәтер каберенә тамган гөлләр” дә, “йөрәк тулы зәңгәр моңнар” да, канатларын кагып, мәңгелеккә таулар ягына очып киткән бөркет” тә...

Туган ил, туган авыл һәрвакыт бер генә була. Беркем дә үзенең туган авылын  башка авыллар белән бутамый һәм бутый да алмый. Чөнки ул – туган авыл, кешенең үзе кебек үк бердәнбер!

Туулар бар җирдә, китүләр бар,
Китми яшәү мөмкин түгелдер.
Туу да бер җирдә, китү дә бер,

Гомерләр дә безнең бердәнбер.

Әлфия Ситдыйкова тормышны ничек бар, шул килеш кабул итә. Һәм йөрәгенә килеп кагылган һәр вакыйганы, һәр күренешне шигъри калыпка салып, әдәби әсәр тудырыга тырыша. Шагыйрә бу эшнең остасы, сүз ярдәмендә мавыктыргыч, мәгүнәле, гыйбрәтле яңа дөнья төзүче зат ул:

Туган ягым! Чишмәң, күзең ачып,
Сәлам бирә челтер тавыш белән.
Сусавымны басып, дәрман алып,
Үрләреңә, тауларыңа менәм.

Әлфия Ситдыйкова иҗатының сере, биеклеге – бер көйгә, бер мотивкарак салынган татар шигъриятенә җылылык өстәүдә, лирика жанрын яңа төсмерләр белән баета алуда. Һәр китабы шигърият сөючеләрнең күңел сердәшенә әйләнә.

Илгә, көнгә, яшәешкә мәхәббәт белән сугарылган шигырьләреннән яктылык, нур бөркелә.

Әлфия Ситдыйкова үзенең бөтен барлыгы, эчке дөньясы белән кешеләрне, бигрәк тә яшь буынны агартырга, аларга дөрес тәрбия бирергә тугандыр.Үзенең кешегә булган игътибарлыгы, ярдәмчеллеге, кыйммәтле әдәби мираска, кеше хәтеренә булган үтә дә җаваплы сакчыллыгы аны чын шагыйрә ясый.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Бәшәр Р. Сандугачлы таңнарга гашыйк // Өмет. – 2003. – № 142.

2.Сафина Н. Каршылык көчен буйсындыр // Ватаным Татарстан. -2008. - 16май

3.Мәйдан журналы.- № 7.- 2017.-10-60б.

# Ике икең ундүрт

*Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы,*
*югары категорияле башлангыч*
*сыйныфлар укытучысы*

## КЕРЕШ

Республикабызда һәр төбәкнең үзенә генә хас, кабатланмас матур урыннары бар. Кайда гына булсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, бормаланып-бормаланып ага торган Ык елгасы, аның тирә-юне, тугайлары, әрәмәлекләре, төрле-төрле балыкларга бай күлләре һәм елгалары булган Мөслимебез үзенә тарта. Җирлегебездә туып, аның бәрәкәтле туфрагыннан, матур табигатеннән көч, иҗатка илһам алган күренекле фән һәм сәнгать эшлеклеләре, шагыйрьләр, язучылар, илдә танылган зур җитәкчеләр Мөслимне данлы итәләр.

Ык буенда, Мөслим ягында туып-үскән, иҗат өчен илһамын шуннан алган якташлырыбыз арасында бик күп язучылар, шагыйрьләр, артистлар бар.

Районыбыздан чыккан күренекле шәхесләр арасында прозаик, драматург , журналист, ТР атказанган мәдәният эшлеклесе, Язучылар союзы члены , Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фоат Садриевның булуы безнең өчен аеруча куаныч. Ул районыбызда нәшер ителүче “Авыл утлары” газетасында хезмәт куеп, үзенең эчтәлекле мәкаләләре , иҗаты белән район халкын аң-белемле итү , агарту эшенә багышлаган. Бик күпләргә иҗат юлына басарга этәргеч бирүче остаз.

Үземнең фәнни эшебезне без шушы олы шәхескә багышладым. Хезмәтемнең максаты: Фоат Садриевның балалар өчен язылган хикәяләрендә күтәрелгән проблемаларны ачыклау.

**Максаттан чыгып, түбәндәге бурычлар билгеләнде:**

1) Ф.Садриев турында материал туплау .

2) Язучының иҗаты белән тирәнтен танышу.

3) Балалар өчен язылган әсәрләрендә проблеманы табу.

4) Язучы турында замандашлары фикерен белү.

**Төп эшемдә өйрәнү объекты** – Ф.Садриевның тормыш юлы, иҗади эшчәнлеге. Предметы – әдәби уку фәне.

**Фәнни эшнең актуальлеге:** Башлангыч сыйныфларда сыйныфтан тыш уку дәресләрендә һәм әдәби чараларда кулланыла.

**Фәнни эшемдә өлешчә эзләнү, тикшеренү, чагыштыру, анализ кебек метод-алымнар файдаландым.**

## II.Төп өлеш.

### 1.1Ф.Садриев бөтен гомерен авыл белән бәйләгән әдип.

Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев Мөслим районы Олы Чакмак авылында туган. Үз авылларында җидееллык, аннан күрше Шуган авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң колхозда эшли, хуҗалык кибетендә сатучы, авыл китапханәсендә мөдир була. Соңыннан Сарман, Мөслим районы газеталарында хезмәткәр,бүлек мөдире булып эшли. Гомерен авыл белән бәйли, аның төрле тармакларында тырыш хезмәт куя.Шуңа күрә аның әсәрләрендә төп геройлар- авыл кешеләре, авыл балалары.

Без класстан тыш уку дәресләрендә аның балалар өчен язылган хикәяләрен укып чыктык. Хикәяләрнең үзәгендә үзебез кебек малай-кызларны күрдек, аларда үзебезнең дусларыбызны таптык. Нәкъ безнең балалар кебек алар да шаян, бераз тәртипсез дә, хәрәкәтчән авыл балалары.

Ф.Садриев иҗатын өйрәнгәндә аның гаять күләмле хезмәтен күреп соклandык. Ике дистәгә якын сәхнә әсәре, хикәя, повестьлары, романнары бар . Шул хезмәтләре өчен Ф.Садриев зур бүләкләргә лаек булган. Бигрәк тә иң олы бүләк- Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булуы укучыларда зур горурлык хисе уятты. Укучыларга аның турында сөйләгәндә “Әле авыл җирендә иҗат итеп, Тукай премиясе алган язучы юк. Фоат абыегыз- беренче!”- дигән сүзләрне ишеткәч, алар сөенеп, туган җиребез өчен шатланып , горурланып тыңладылар.

## III. Балалар өчен язылган әсәрләрендә проблеманы табу.

Без класстан тыш уку дәресендә Ф.Садриевның **“Ике икең -ундүрт”** дигән китабы белән таныштык. Китапның исеме шунда ук безне үзенә җәлеп итте: “Ни өчен икең ундүрт була?”, “Ничек ундүрт саны чыга?” Без шушы сорауга җавап бирер өчен фәнни-тикшерү эшен башлап җибәрдек.

Һәркем белә: ике икең- дүрт. Ә нигә Ф.Садриевта ундүрт? Әйдәгез, хикәягә күз салыйк. Хикәядә 1 сыйныф укучысы Азат турында сөйләнә. Ул математика дәресендә укытучының соравына җавап бирергә тиеш була. Сорауга җавап бирә алмагач, укытучы аңа мисал китерә: “Менә синең чәйни торган ике сагызың бар, әниең тагын икене бирде. Барысы ничә була?” Азат карап-карап торганнан соң “Ундүрт”,- дип җавап бирә. Азатның җавабы дөрес түгел дип санарга була, ләкин монда уйланырлык нәрсә бар.....ул дөресен әйтә. Чыннан да аның ике сагызы була, әнисе тагын икене бирә, Мәскәүдәге апасыннан посылка белән ун сагыз килә. Җавап ничә? Әлбәттә, ундүрт! Азат мәсьәләне дөрес чиште, әмма тапкырлауны аңламаган әле. Укытучы апасы аңлатып биргәч кенә, ул икене икегә тапкырлагач, дүрт саны килеп чыкканын белгән. Без Азатның зирәк, бераз игътибарсызрак ягын белеп киттек.

Шулай ук бу китапта безне күп төрле сорауларга җавап бирә торган хикәяләр , әкиятләр кызыксындырды. “**Тургай ни дип җырлый?”, “Бал корты ник чага?”**. Чыннан да, бу сорауларга төрлечә җавап бирергә була. Ә менә Ф.Садриевта ул башкачарак яңгырый, тургайлар туган җирнең ничек кадерле, газиз икәне турында сагынып җырласалар, ә бал кортлары кешеләрнең явызлыгына чыдый алмыйча чага башлаулары турында языла.

**“Белемле әби”** хикәясендә автор табигатькә сак караш проблемасын күтәрә. Автор авыр чорлар үткән әби-бабайларыбызның үсемлекләргә, табигатькә тирән хөрмәт белән, сакчыл карауларын ассызыклап үтә.

Әлфия алабута урынына әрем җыеп кайткач, әбисе аның хатасын аңлата, әремне чыгарып түкми .“Ярар, борчылма, кызым, -диде әбисе. - Әремне суга салып кайнатырбыз да агачларга сибәрбез. Корткыч бөҗәкләрне үтерә ул”,- дип аңлата әбисе.

Бу хикәядә автор тагын бер проблема күтәрә. Мәктәпләрдә тирән белем алмасалар да, югары уку йортларын тәмамламасалар да, безнең әбиләребез табигатьнең иң тирән серләрен беләләр икән. Безгә эле алардан бик күп нәрсәләр өйрәнергә кирәк икән дигән фикергә килдек.

**“Юкка көттеләр”** хикәясен дә без бик яратып укыдык. Безгә гади авыл кешеләренең, телебезнең матурлыгын тоеп, аның тәмен белеп сөйләүләре ошады. Бу хикәядәге малайлар кебек әле үзебезнең дә сөйләмебезнең бик үк камил булмавын аңладык. Нурҗиһан әбинең авызыннан тере саескан очканын көтеп торган малайлар кебек, үзебезнең дә оятка калуыбыз бар икән. Автор шуңа күрә туган телебезнең барлык матурлыгын күрсәтеп, сүзнең тәмен белеп сөйләргә кирәклекне проблема итеп күтәргән дип уйлыйбыз.

Гомумән, “Ике икең- ундүрт” китабында язучы авыл тормышын үзенчәлекле буяуларда чагылдыра. Туган җиргә, хезмәткә мәхәббәт, дуслык, батырлык хисләре тәрбияләү- җыентыкның төп идея эчтәлеген билгели.

## IV.Ф.Садриев турында иҗатташлары

Эзләнү барышында безнең күңелебездә Фоат абыйны башка җирләрдә беләләр микән дигән сорау туды. Китаплар актара торгач, дәрәҗәле әдипләребезнең аның турында бик матур фикерләрен укыдык.

“Мөслим ягы кайсы ягы белән үзенчәлекле дип саныйсыз?” дигән сорауга Роберт Миңнуллин “Шушы җирлектә яшәп иҗат итүче күренекле язучылары Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов белән, эшчән, тырыш халкы, матур табигате белән үзенчәлекле”, дип җавап биргән.

*Ф. Әмәк: “Без Мөслим төбәгендә туып – үскән яшь буын язучыларга Фоат ага Садриев, аеруча якын, аны икеләнмичә остаз дип атыйбыз” , дигән.*

*Ә Туфан Миңнуллин: “Бик шәп язучы бит син, Фоат дус! Зур язучы! Оста, ләкин синең зурлыгыңны әдәби тәнкыйть бәяләп үк бетерми сыман.” “Фоат Садриев дигән олы язучы бар”,- дип үзенең бик югары бәясен биргән.*

*М.Әгъләмов: “Фоат Садриев – татарның Шолоховы ул” , дип Фоат абыйга бик дөрес бәя биргән.*

## V. Йомгаклау .

Ф. Садриев әсәрләрендә гаделсезлек, дулкынландыргыч вакыйгалар гына тасвирланмый. Ул әнә шул кыенлыкларны оныттырырлык, ихлас елмаерлык юмористик, шаян хикәяләре белән дә сөендерә белә. Якташыбыз— юморга бай автор. Аның әсәрләрен укысаң, яшәргә көч, рухи азык табарсың. Кемнең кем икәнен аңларга, кемнең кемлегенә карап аралашырга өйрәнерсең, дәрес алырсың. Фикереңне гади генә, аңлаешлы һәм үтемле итеп җиткерәсең килсә, Фоат Садриевка мөрәҗәгать ит. Аның чагыштырулары, җөмлә төзелеше, сүз сайланышы, фикер агышы һәркемне өйрәтерлек, сабак алырлык.

Шуңа күрә без әле киләчәктә укучылар белән Фоат абыйның иҗатын тагын да тирәнрәк өйрәнеп, эзләнүләрне дәвам итәрбез дип уйлыйбыз.

## VI.Әдәбият исемлеге :

1.Ә.Әхмәтгалиев “Мөслим төбәге” . Тарихи сәхифәләр.- “Яр Чаллы типографиясе” дәүләт унитар предприятиесе, 2003-126б.

2. Татарская электронная библиотека. http://kitap.net.ru/sadriev.php

3.Союз писателей Республики Татарстан http://www.sptatar.ru/index.php/component/virtuemart/chleny-sp-rt/s/sadriev-foat-detail?Itemid=0

4.Ф.Садриев “Ике икең -ундүрт”: хикәяләр, экиятләр- Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988- 12б.

5.Әхсән Шәрипов “Яшәү көче табарсың” мәкаләсе, “Авыл утлары” газетасы №245, 2011 ел.

# Язмышларга буйсынмас Чулпан

*Дилэрэ Ханнан кызы Гыйниятуллина,*
*Балтач районы МБГБУ “Балтач гимназиясе”*
*нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

Бәхет үзе килде миңа,
Кулыма каләм алгач,
Йөрәк кылларын чыңлатып,
Сандугач моңы салгач.

Әлеге юлларны укыганда бу шигырьне бик бәхетле кеше язгандыр дип уйлыйсың. Әмма язмыш сынавына дучар булган 16 яшьлек кыз шигыре бу...

Чулпан Габделганиева 1977 елның апрель аенда шигъри Балтач төбәгендә дөньяга килә. Тик аны бер бәхетсезлек сагалый: ул йөри алмый. Йолдыз исемен йөрткән кыз бирешергә уйламый. Ул 1983 нче елда Норма урта мәктәбенә укырга керә һәм укытучыларның ярдәме белән мәктәпне тәмамлый. Аның алга таба максаты- яшәргә, көрәшергә. Укыган китаплары да шуңа өнди . Н. Островский, Ф. Яруллин да, язмыш сынауларын горур үтеп, тормыш төбендә калмаган, язучы булган. Аның бит әле күзләре күрә, куллары сау- сәламәт!

Әнә шулай әкрен генә язмыш белән көрәшкә чыга кыз. 16 яшендә аның “Йолдыз бүләк итәр идем” дигән беренче шигыре туа. Озак та үтми Чулпан Габделганиева үзенең иҗат җимешләрен район газетасы “Хезмәт”кә , аннан “”Яшь ленинчы”га җибәрә, аларда басыла башлый. Үзен олы юлга чыгаручы итеп ул Госман абый Садәне саный. Ул иң беренчеләрдән булып, Чулпанның шигырьләрен һәм аның турында язманы “Яшь ленинчы” газетасында чыгара. Республикабызның күп кенә газета-журналларында да аның шигырьләрен бастыралар. Кешеләргә, тормышка гашыйк Чулпан ялындырып тормый, һәммәсе бәлән дә уртак тел таба, тулы канлы тормыш белән яши башлый.

Бәхет үзе килде миңа,
Иң авыр чакларымда,
Сызланып янган күңелнең

Өмет канатларында, - дип яза ул " Бәхет үзе килде" шигырендә. Әмма бәхет бирәүгә дә үзе, җиңел генә килми. Тормыш кыенлыкларына сыгылып төшмәгән Чулпанның бу шигырен сокланып укыйсың. Йөрәгендәге матур хисләрне шигырьгә салучы, дөньяда яшәүнең матурлыгын, кадерен таза-сау кешеләрдән күбрәк белүен күреп, уйга каласың.

Яшь шагыйрә өчен иң бәхетле ел-2003 нче елдыр. Бу елны аның, ниһаятъ, беренче карлыгачы, беренче шигырь китабы- "Йолдызлар бүләк итәм" җыентыгы дөнья күрә. Дөнья малына, байлыкка табынмаган, пакъ күңелле кыз өчен күп кирәкми:

Яралы күңелнең хисләре

Бик нечкә кыллардан тезелә.

Бер нәни шатлыктан көч алса,

Бер нәни сагыштан өзелә.

Бер дә тик утырырга яратмаган Чулпан спорт белән "җенләнеп" китә. Ул Биектау, Казан, Лениногорск, Чаллы кебек шәһәрләрдә дә ярышып, җиңүләр яулый, спорт мастерлыгына кандидат исеме ала. Ә 2005 елда Мәскәүдә инвалидларның Бөтенроссия шашка-шахмат турнирына барып житә.Тырышлыгының нәтиҗәсе дә куанычлы: ул беренче унлыкка керә Һәм бронза медальгә лаек була. Шулай итеп, Чулпан дигән йолдыз чын-чынлап йолдыз булып балкый башлый. Бу –аның түземлеге, тырышлыгы нәтиҗәсе.

2006 елда "Бәхет үзе килде миңа" дигән икенче шигырь җыентыгы да дөнья күрә. Үз алдына зур максат куйган кыз шигърият үренә җай гына атлый да атлый. Аның тормышка гашыйк булуына сокланып бетә алмыйсың.Ул шигырьләре белән үзе дә сиздерми генә тормышка мәхәббәт уята.

Беркем әйтә алмый син бәхетсез диеп,

Күзләремә туры карап.

Бәхетемнән ташый җырлар,

Йөрәгемнән чыга ургып.

Таза-сау кешеләрэшли алмаганны булдыра Чулпан. Бу сыйфатлар аңа әнисеннән дә күчкәндер. Гөлнур апа берүзе алты бала тәрбияләгән олы йөрәкле ана. Шушы сөекле әнисенә Чулпан бик күп шигырьләр бүләк итә. Аның иң зур хыялы- әнисенә багышланган китап бүләк итү. Ниһаять, бу теләге чынга аша: әнисенә атап язылган 36 шигыре тупланган өченче китабы да 2007 нче елда “Әниемә бүләк” исеме астында дөнья күрде.

Туган авыл, туган төбәк, олы җанлы кешеләр, яшьлек, мәхәббәт һәм һәр тарафта матурлык күрергә, шуны шигъриятендә күрсәтергә тырышкан шигьри җанлы Чулпан үз укучыларын тапты.  Аларга бүләк итеп, тагын бер җыентык-“Мәхәббәтнең төсен эзлим” дигәнен чыгарды.

Әле кайчан гына кешеләргә йолдыз бүләк итәргә хыялланган Чулпан, инде теләгенә ирешкән дип әйтеп була. Меңәрләгән  йолдызлар арасында гади генә, тыйнак кына Чулпан йолдыз булып балкырлык эшләр башкарган. Шигырьләре аша, үзенең яшәү рәвеше, кылган гамәлләре белән башкаларга җылылык, матурлык, өмет өләшә. Тормыш юлында, язмыш кочагында калганнарга, йолдыздай балкып, үрнәк, юл күрсәтә.

Бүгенге көндә 1 группа инвалид, 4 китап авторы Чулпан  Габделганиева үзенең туган Балтач төбәген, аның кешеләрен барыбыздан да ныграк ярата. Чөнки ул тормышның кадерен бездән күбрәк белә. Аның шундый көчле рухлы булуына сокланасың. Әйе, кеше көчле булырга тиеш. Фәнис Яруллин әйткәнчә: “Көчле рухлылар гына, түземнәр генә бәхеткә лаек”. Янәшәбездәге шундый көчле рухлы кешеләрне без белергә, хөрмәт итәргә тиеш. Юк-бар авырлыкка ыңгырашып йөрүчеләр дә аннан көч, үзенә гыйбрәт алсын иде. Чулпан Габделганиева безне шуңа өнди:

Күк йөзеңне сагышларга
Язмыш үтсә уратып,
Авыр хисләргә бирелми,
Яшик әле елмаеп.

# Эльмира Шарифуллина– Моң иясе.

*Биктаһирова Ләйсән Габбас кызы,*

*Алиева Суфия Фатхулла кызы*

*Яшел Үзән механика көллиятенең*

*татар теле укытучылары*

Әлеге эшнең өйрәнү объекты булып шагыйрә Эльмира Шарифуллинаның күпкырлы иҗаты тора.

Бу теманың актуальлеге, хәзерге заман яшьләрендә татар әдәбиятенә мәхәббәт уятуда, милли-төбәк компоненты кысаларында әлеге шагыйрәнең иҗаты белән таныштыруда.

Бу теманы өйрәнү дәверендә үз алдыбызга түбәндәге максатлар куйдык:

- шагыйрәнең тормыш юлы белән танышырга;
- анын әсәрләрен укып анализларга ;
- шигырьләренең төп темасын ачыкларга.

Шушы максатлардан чыгып безнең алга түбәндәге бурыч куела: язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән тирәнрәк танышу өчен Яшел Үзән шәһәренең төбәкне өйрәнү китапханәсенә бару.

Жир йөзендә гаҗәеп сагышлы, гаҗәеп сабыр, гузәл, үзәк эзгеч бер Моң яши. Ул Моңның исеме Эльмира. Ул Моң, әлбәттә шигырь канатларында тирбәлә, жир буйлап тарала. Әкрен генә күңел түрләренә үтеп керә, җанны тетрәтә, керфекләргә энҗе яшь тамчылары элә.

Эльмира Шәрифуллинаның иҗатында без нәкъ хатын-кызларга гына хас тыйнак күңел, сизгер моң, серле уйчанлык белән очрашабыз. Анының шигырьләрендә – ана хисләре, дуслык тойгылары, балалар һәм ата-бабалар язмышы, Илебезнең киләчәге, дөнья иминлеге өчен борчылу ята.

Эльмира Шәрифуллинага хас төп сыйфатларның берсе – ул шигырьләрендә табигать һәм кеше халәтендә булган уртаклыкны күрә ала, моны шигырь юлларында аңлаешлы, оста итеп чагылдыра белә.

Эльмира иҗатына хас тагын бер төп сыйфат – халык авыз иҗатын тирәннән белү, әйтәсе фикерен җиңел, аңлаешлы тел белән укучыга җиткерә белү! Аның шигырьләрен укыганда, баш ватып утырасы юк, барысы да үз урынында, кирәкмәгән артык сүзләр юк сыман.

Хатын-кыз, әни, дәү әни буларак, аның шигырьләре һәрвакыт тәрбиягә илтә. Моннан байтак еллар элек ук карга боткасы, күрше хакы турында язганда, бәлки, сәер, хәттә көлке тоелгандыр. Бүген дә балаларга тәрбия бирүнең төп чыганагын гореф-гадәт, йола-кануннарыбызда, халык педагогикасында күрә.

Шагыйрәнең иҗатында аерым тармак булып аерылып торган балалар дөньясы зур үсеш алган. Зурлар шигъриятеннән китмәсә дә, аны элгергән балалар шагыйре дип әйтергә мөмкин. Аның шигырьләре балаларга дәрес тәрбия бирүдә, туган якка, туган телгә хөрмәт, мәхәббәт уятуда зур урын алып торалар.

Гомумән, татар хатын-кызларыбызның иҗаты күңелгә күбрәк тәэсир итә.  Эльмира Шәрифуллинаның шигырьләрендәге, поэмаларындагы хис, фикер үрелешләре калфакларыбыздагы, түбәтәйләребездәге, суккан сөлгеләребездәге нәфислек чигелешләреннән килеп чыккандыр кебек.

Файдаланган әдәбият:

1. Гаффар Ә. “Моң иясе” // Мәгърифәт. – 1997. 14 июнь.

2. Зыятдинова Ф. “Кемгә серем сыяр, йә Аллам” Эльмира Шәрифуллина... //Татар иле. – 2002. – 22 май.

3. Мәхмүдов Ә. “Мәхәббәт шагыйрәсе”// Мирас. – 2007. - №6.

4. Шәрифуллина Э. Сөюемнән мин бер чибәр идем...// Казан. “Рухият” – 2005.

# Харрас Әюпов иҗатында яшәү фәлсәфәсе

Мөслим районы Вәрәшбаш төп гомуми белем бирү
мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Яхина Ләйсән Равил кызы

Соңгы елларда татар поэзиясендә фәлсәфи характердагы әсәрләр шактый язылды. Бигрәк тә яшәү фәлсәфәсе, яшәеш, кешенең дөньядагы роле, урыны турындагы темалар киңәя бара. Әлеге төрдәге поэзиягә без Р.Фәйзуллин, Х.Әюпов, Н.Гамбәр, Л.Янсуар кебек шагыйрьләрне кертә алабыз. Кешенең бу дөньяда башкарган гамәлләрен аңлату позициясеннән яшәеш хакында уйланулары белән Харрас Әюпов иҗаты игътибарны ныграк җәлеп итә.

Харрас Әюп- шигъряттә нәтиҗәле эшләгән, поэзиядә үз сукмагын, үз укучысын тапкан әдип. Аның шигырьләрен укыгач яшисе килә башлый, дөньяда матур гамәлләр кылып яшәүнең бөеклеген аңлыйсың. Шагыйрь күңеле галәм кебек чиксез, шул ук вакытта үтә конкрет һәм рәсем кебек сурәтле дә, фәлсәфи дә. Аның шигырьләрен укыганда үзең өчен таныш булган нәрсәләрдән яңа дөнья, яңа хакыйкатьләр ачасың, яшәргә көч аласың. Беренче карашка үтә дә гади тоелган шигъри юлларда маңгайга бәрелеп әйтелмәгән олы фәлсәфә ята.

Әлеге хезмәтебездә без Харрас Әюпов иҗатында яшәү фәлсәфәсен күзәтергә алындык һәм кайбер шигырьләрен авторның Кеше, аның яшәү мәгънәсен ача алуы ягыннан анализладык һәм нәтиҗәләр чыгардык:

1. Харрас Әюповның шигырьләре кешенең газап, сагыш, курку халәтендә бу дөньяда яшәү рәвешен, әхлакый кануннар җимерелгән бер чорда Кеше буларак яшәргә омтылуын да ачарга тырышудан гыйбәрәт.

2. Х.Әюп әдәбиятка килеп, лирик дулкында иҗат иткән шагыйрь. Халыкчан якты моң, эчкерсез гади интонацияләр, үзенчәлекле шигъри образлар, сыгылмалы йөгерек тел, фәлсәфи гомумиләштерүләр аның шигырьләренең төп үзенчәлеген билгели.

3. Харрас Әюповның шигырь һәм поэмаларында буыннар бердәмлеге, җирдә кеше язмышы, аның күңел матурлыгы турындагы уйлануларны үз эченә алган, халыкчанлык белән сугарылган мотивлар өстенлек итә.

Харрас Әюпов шигырьләрен укучылар әле күп еллар дәвамында яратып укырлар, яшәү, тормышыбыз турындагы уйлануларына Х.Әюп шигырьләрендә җавап табарлар. Аның иҗаты киләчәк буыннар өчен дә чын ачыш булачак, чөнки шагыйрь күтәргән проблемалар ул мәңгелек.

**Әдәбият**


1. Әюпов Х. Таң суы. Казан, 1987.
2. Әюпов Х. Йөз яктысы. Казан, 2005.
3. Әюпов Х. Сабыр савытлары. Казан, 1992.
4. Бакиров М. Күкрәгеңдә көең исән булсын // Мәдәни җомга. 2005.
5. Әсәрләр: 7 томда. 1 т. Шигырьләр, тәрҗемәләр / кереш сүз авт. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 575 б.
6. Поварисов С. Ташка язылган мәхәббәт // Мәйдан. 2006. № 6.
7. Сафин Ф. Шигъри балкыш // Мәйдан. 2008. № 12.
8. Шәмсутова А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш. Казан, 2010.

# Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән

*Вәлитова Ә.Н.,татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Бөгелмә шәһәре 3нче урта мәктәбе*

Минем фәнни эшем тирән лирик, халык күңеленә үтеп кергән иң яхшы шигырьләр авторы, күренекле татар шагыйрәсе Эльмира Шәрифуллина турында булыр.

Әйе, тормышта шундый вакыйгалар була бит: алар, кинәт кузгалган давыл кебек, күңел капкаларын каерып ачып керәләр дә барлык дөньяны актарып-туздырып ташлыйлар. Эльмира ханымның китабын кулга алып укый башлагач та мин шундыйрак бер рухи сискәнү, хәтта, әйтергә мөмкин, тетрәнү кичергән идем.

Татар әдәбиятын, гомумән, татар шигъриятен мин Эльмира ханым Шәрифуллинадан башка күз алдына да китерә алмыйм. Нинди бииһая зур иҗат: тирән фәлсәфи, төпле фикерле, киң мәгънәле шигырьләр йә булмаса маңгайга туры итеп бәрә, чын хакыйкатьне ачып сала торган төрттерүле әсәрләр. Алар берара ягымлы һәм якты, берара усал һәм ачы... Көлдерә дә, елата да Эльмира ханымның әсәрләре. Лирикасы җанны иркәли, күңелне күтәрә, юмор-сатирасы җанга көрлек өсти, көч бирә һәм...тәрбияли.

Э. Шәрифуллина үзенең шигырьләре белән көндәлек матбугатка 60нчы елларның урталарыннан катнаша башлый. Ул шулай ук проза жанрында да эшли – яшьләр тормышына багышланган очерклар һәм балалар өчен хикәяләр яза.

Эльмира Шәрифуллина – бүгенге көндә, кайчандыр сәхнәгә чыгып, өлкән буын шагыйрь һәм язучылар каршында имтихан тоткан оялчан кыз түгел, ә татар шигъриятендә үз юлын, үз йөзен тапкан тәҗрибәле сүз остасы. Күңелендә йөрткән хис-кичерешләрен ак кәгазьгә күчерү нәтиҗәсендә туган шигырьләре, тормышының аерым мизгелләрен, укытучы булып эшләгәндә туплаган тәҗрибәсен чагылдырган повесть һәм хикәяләре, нәниләрне тәрбияләүдә методик кулланма дәрәҗәсенә җиткереп эшләнгән, шул ук вакытта балаларча самимилек, эчкерсезлек белән сугарылган әкият-

хикәятләре хәзерге заманның теләсә-кайсы таләпчән укучысын канәгатьләндерә алырлык.

Фәнни эшемнең максаты шуннан гыйбарәт: шагыйрәнең тормышы һәм иҗаты белән тирәнрәк танышу, шигъриятенең идея-тематик структурасын, сәнгатьчә үзенчәлеген, поэзиясенең асылын ачу, төп фәлсәфәсен билгеләү.

Бурычлары:

- Эльмира Шәрифуллина иҗатында милли эстетиканың чагылышы.
- җәмгыятькә һәм халкыңа хезмәт итәргә әзер булу.

Э. Шәрифуллина иҗат эшчәнлегенең башыннан ук ике юнәлештә — лирик поэзиядә һәм балалар әдәбиятында актив эшләүче шагыйрьләрдән. Моңа соңгы елларда проза һәм драматургия дә килеп кушылды. Лирикада ул — үз шәхси биографиясе, тормыш тәҗрибәсе җирлегендә туган уй-хисләрне, күңел тирбәлешләрен нечкәләп тасвирлауны алга сөргән, өлкәнрәк каләмдәше шагыйрь Зөлфәт сүзләре белән әйткәндә, «хатын-кызларга гына хас тыйнак күңел, сизгер моң, серле уйчанлык» белән өртелгән хисле шигърият тарафдары. Бу сыйфатлар шагыйрәнең “Гөлләр елы” , “Зәңгәр эңгер”, “Таң чыгы” исемле чираттагы җыентыкларында урын алган лирик шигырьләрендә дә ачык күренә. Ул шулай ук, сурәтләнгән тормыш күренешләре төрлесе төрле булса да, бүгенге заман сулышы белән сугарылган, лирик-публицистик аһәңле “Тәмуг кисәве”, “Шагыйрь чишмәсе”, “Без — Тукайлы”, “Каюм коесы” исемле поэмалар авторы буларак та укучыларга билгеле.

Минем фәнни эшемдә Эльмира Шәрифуллинаның төп иҗат юнәлеше – поэзиясе һәм шигъри тел белән язылган чәчмә әсәрләре тикшерелде.

Һәр шигырь китабы зур кызыксыну белән көтеп алынган бу шагыйрь иҗатының олы мәгънәсе кешегә, аның хезмәтенә, акылына дан җырлауда һәм кеше бәхете өчен көрәшүдә, кешеләр өчен шатлык һәм матурлык раслауда. Шушы сыйфаты өчен генә дә бөек шагыйрьне, әлбәттә, милләтпәрвәр дип санарга нигез бар, дип уйлыйм.

Милли рух Э. Шәрифуллина иҗатында да кызыл җеп булып сузыла. Бер генә түгел, ә берничә. Беренчесе – милли гореф-гадәтләр. Э. Шәрифуллина әсәрләрендә милли рухны бирүче икенче җеп – татар мохитын тасвирлаучы йорт җиһазлары. Өченче төркемне – милли ризыклар тәшкил итә.

Дүртенче кызыл җеп – татар халкының атаклы зыялылары, милләт сакчылары. Андыйларның булуы, үзләренең эш-гамәлләре белән татар халкының җирдә яшәве турында дөньяга белгертеп торулары белән Э Шәрифуллина чын күңелдән горурлана. “Шагыйрь чишмәсе” поэмасы әнә шундый әсәрләрнең берсе.

Гомумән, теге яки бу дәрәҗәдә шәҗәрә тамыры белән авылга бәйләнмәгән, җиргә мөнәсәбәте булмаган татар шагыйрен табу кыен. Берәүләр туган җире-авылын-яшел бишек, берәүләр-алтын бишек, диләр. Һәркем үзенчә хаклы. Эпитетларны һәркем үзенчә сайлый. Сүзнең төбе, мәгънәсе шунда: авыл чыннан да күпләребез өчен рухи бишек. Кыскасы, Эльмира Шәрифуллина үз иҗаты белән киләчәк буынга милли бизәкләребезне, гореф-гадәтләребезне, гомумән, милли рухыбызны илтеп җиткерүне максат итеп куйган милләтпәрвәр шагыйрә ул.

Минем фикеремчә, Э.Шәрифуллина - чын мәгънәсендә милләтпәрвәр, үз халкының якты киләчәге өчен үткен каләме ярдәмендә армый-талмый көрәшеп яшәгән тынгысыз шагыйрә . Без хаклы рәвештә аның белән горурланабыз.

Чыннан да кызык сораулар күңелдә туа. Эльмира Шәрифуллина нинди шәхес соң ул? Ул - көчле, бирешмәүчән, туры, тапкыр, җор сүзле, гадел, сабыр, түзем, тәнкыйди, эзлекле, тирән фикерле, юмор-сатирага ия, көлә белүче, укымышлы, бик күп уңышларга ирешкән шәхес. Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән шул.

### Кулланылган әдәбият исемлеге


1. Ихсанова Л. Мәхәббәт турында җыр // “Мәйдан”, №5, 2007.— 83-84 б.
2. Даутов Р. Н. Балачак әдипләре // Икенче китап. – Казан, “Раннур” нәшрияты, 2004 – 286 б.

3. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. – Казан, Тат. кит. нәшр., 1986. – 639 б.
4. Зәйнашева Г. Гөлләр елы // “Мәйдан”, №5, 2007.— 85-86 б.

# Р.Рахман иҗатында фразеологик әйтелмәләр кулланылышы

*Төхфәтуллина Ә.Г.*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең*

Рифә Рахман – әдәби детальләр, троплар остасы, аның шигърияте шулай ук сюжет элементларына бай. Шагыйрә осталыгы хис-кичерешләрне үзенә генә хас формада, үзенчәлекле сурәтләү чаралары аша бирүендә аеруча ачык күренә. Фразеология – Р.Рахман иҗатында төп тел-сурәт чараларыннан берсе. Аннан оста файдалана белү – шагыйрә иҗатының уңышлы һәм отышлы ягы. Шагыйрәнең стилен, әдәби әсәрнең телен өйрәнгәндә әдип кулланган фразеологизмнарны, әйтем һәм мәкальләрне тикшерү зур әһәмияткә ия, чөнки алардан башка шигырь поэтик яңгырашлы була алмый.

Фразеология - әдәби әсәрдә, шул исәптән шигърияттә дә төп тел-сурәт чараларыннан берсе [2, 97 б.]. Алар ярдәмендә автор әдәби әсәр телен образлырак, аһәңлерәк итә, аңа үзенчәлекле яңгыраш кертә. Мәсәлән, ул *“Затлы уй”* һәм *“Сынап карап, маңгаема сырлама сыр”* шигырьләрендә үзенең фәлсәфи фикерләрен халык телендә еш кулланылучы фразеологик әйтелмәләр (*баш авыраю, сыр сырлау, авыр уй, ташка үлчим*) аша ачып сала. Сөйгәненең эш-гамәлләр турында кыска һәм үтемле итеп язу өчен кулланылган үз табышы да кызыклы *(тәнеңне җуй, сын сынландыру*).

Кайчак автор, төрле күренешләрне, шәхси күңел халәтләрен дә фразеологик әйтелмәләр аша биреп, җанлы сурәт тудыра:

*Бу төнемдә, димен, тагын мин ялгызым.*
*<u>Күңелем кайтты</u> дусларымннан, бәйрәмнәрдән. (“Белсә”)*

Халыкта юкка чыгару, бетерү мәгънәсен бирү өчен *тамырына балта чабу* фразеологик әйтелмәсе яши. Шагыйрә әлеге гыйбарәне, мәхәббәт һәм

хыянәт хисләренә нисбәтле ачып, хис-кичерешләрен тыгын да үтемлерәк һәм тәэсирлерәк итеп яктырткан:

*Сөюемнең тамырын чапты балтаң.*

*Ник алмадың тартып кына аннан? (“Сөюемнең тамырын чапты балтаң”)*

Исеме үк фразеологик әйтелмә белән бирелгән “Җан өрү” (мәгънәсе – тереклек бирү, яшәргә мөмкинлек бирү [1, 344 б.] шигырендә дә автор, халык гыйбарәләрен үзенеке белән бәйләп, сәнгать әсәре иҗат итә алган:

*Кулыма төшкән кар бөртеге булсаң,*

*Елата да алам, җылы өреп.*

*Елата да алам бит мин юкса,*

*Кемдер тибеп китсә эзләремә.*

*Кысаларда торган сурәт кебек*

*Үтмә инде минем үзәгемә. (“Җан өрү”)*

Рифә Рахман, лирик героеның сөйгәне белән аерылышу газапларын образлы итеп бирү өчен дә, төрле эчтәлектәге фразеологик әйтелмәләр кулланып, образлы сурәт ясый:

*Күзләреңнең төсе качар идемени,*

*Синсез яшәү миңа рәхәт түгел дисәм?(“Бохарада гына түгел”)*

*Җан әрнесә, тозлы сулар эчәм.*

*Күмсен димен шуның әчесен.*

*Тоссыз җырлар җырлыйм кайчагында*

*Кайгыларсыз ничек яшисе? (“Җан әрнесә”)*

*Миңа бары җан җылыңны калдыр. (“Үтенеч”)*

“Хыянәт” шигырендә исә бик нык интектерү, җәфалау, газаплау мәгънәсендә кулланылучы *үзәккә үтү* гыйбарәсе [1, 337 б.], иң элек *күзгә үтте,* дип кабатланып, бу гамәлнең авырлыгына һәм газаплы булуына тагын бер кат ишарә ясый.

“Хәйләкәр”, “Син күчкәндә”, “Күтәр аяк очларында...”, “Бер йотым төш” шигырьләрендә дә халык гыйбарәләре (*рәте башы китте, җан чыгу, күзе*

*төпкә бату, йокы качу, зар елау*), автор табышы белән янәшә килеп, үз эчтәлеген һәм мәгънәсен тагын да киңәйткән.

Алдагы шигырьдә исә халкыбызның *чир китәр, гадәт китмәс* әйтелмәсе лирик геройның хис-кичерешләрен ачу чарасына әверелгән, автор аны үз уйларына бәйле рәвештә үзгәртеп, беренчедән, тафтологиядән коткарса, икенчедән, аның эчтәлеген тагын да мөһимрәк яктан ачып, мәгънәсен тагын да киңәйткән:

*Син <u>– гадәтем минем. Чирләр китте:</u>*

*<u>Сөю үтте. Гадәт – гомерлек</u>. ("Син-гадәтем")*

Шагыйрәнең сүзләргә булган талымчанлыгы *"Мәхәббәт йөземе", "Белмисеңдер", "Фонтаннардан су сибәм", "Кипкән чәчәк"* шигырьләрендә дә чагыла. Аларда да шагыйрә фразеологик әйтелмәләрнең үз холкына туры килгәннәрен сайлый.

Гомумән, Рифә Рахман иҗатында урын алган фразеологик әйтелмәләрнең һәрберсе ниндидер максат белән, эчтәлеккә ятышлы итеп кулланылган. Шагыйрә гаҗәеп осталык белән аларның үз урыннарын табып, шигырьнең эчтәлегенә һәм ритм-рифма таләбенә яраштырып тасвирлый. Әгәр хис-кичерешләре әзер сурәтләргә генә сыешмый икән, фразеологик әйтелмәләрне үзе дә уйлап чыгара, яисә аларның мәгънәсен үзгәртеп куллана.

Кулланылган әдәбият

1. Исәнбәт, Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1989.

2. Курбатов, Х.Р. Сүз сәнгате: Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

3. Рахман, Р. Коела йолдыз: Шигырьләр. – Казан: ГАРТ, 2002. – 152 б.

4. Рахман, Р. Сиңа!. – Казан: Мәгариф, 2003. – 160 б.

**Безнең адрес:**
**423700,Татарстан Республикасы,**
**Минзәлә шәһәре, М.Җәлил урамы, 18нче йорт**
**Телефоннар: (8-5555) 3-21-36, Факс: (8-5555) 3-21-36**
**Электрон почта: menzpk@mail.ru**
**Сайт: https://edu.tatar.ru/menzelinsk/page882427.htm**
**Лицензия серии 16 Л 01 №0003110,**
**Регистрационный № 7217 от 18.09.2015г**
**Аккредитация серии 16 А01 № 0000113,**
**рег. № 3663 от 18.07.2016г**
**Без Сезне көтәбез! Рәхим итегез!**